ФГОС

Р. З. Хайдарова, Г. И. Ибрагимова, Г. М. Ахметзянова

# ТАТАР ТЕЛЕ



9 класс

издательство
«Татармультфильм»


Теркә
Со
Тезүче теркәгечләр
Сочинительные союзы
Җыючы
Собирательные
һәм
да/дә
та/тә
янә
ни ... ни
бер ... бер һ.б.
Каршы куючы
Противительные
ләкин
ә
тик
әмма
исә һ.б.



гечләр
юзы
Ияртүче теркәгечләр
Подчинительные союзы
Бүлүче
Разделительные
я
яки
яисә
әле
әллә һ.б.
чөнки
әгәр
гүя
ягъни
ки
гәрчә һ.б.

Р. З. Хайдарова, Г. И. Ибрагимова, Г. М. Әхмәтҗанова

# ТАТАР ТЕЛЕ

# 9

## ТУГЫЗЫНЧЫ СЫЙНЫФ

ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(ТАТАР ТЕЛЕН БАШЛАП ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)

ДӘРЕСЛЕК Е. И. ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ
НИГЕЗЛӘНӘ

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2025

Р. З. Хайдарова, Г. И. Ибрагимова, Г. М. Ахметзянова

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

# 9

## ДЕВЯТЫЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ
ОСНОВНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
(ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ, НЕ ВЛАДЕЮЩИХ
ТАТАРСКИМ ЯЗЫКОМ)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ
ТЕХНОЛОГИИ Е. И. ПАССОВА

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2025

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я72
Х18

## Условные обозначения

Начало урока

Запомни!

Вспомни!

Произноси правильно!

Работа в парах

Работа в группах

Творческая работа

Инсценирование

Ситуативные упражнения

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 9 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р.З.Хайдарова, Г.И.Ибрагимова, Г.М.Ахметзянова. — Казань: Татармультфильм, 2025. — 136 с.: ил.
ISBN 978-5-906508-07-02.

**ISBN 978-5-906508-07-02**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я72**

© Хайдарова Р.З., Ибрагимова Г.И., Ахметзянова Г.М., 2025
© Издательство «Татармультфильм», 2025
Все права защищены

# ТАТАРСТАН ИКЪТИСАДЫ



Мин яратам сине, Татарстан,
Ал таңнарың өчен яратам,
Күк күкрәп, яшен яшьнәп яуган
Яңгырларың өчен яратам.
Мин яратам сине, Татарстан,
Горур халкың өчен яратам,
Җан эреткән әнкәм телең өчен,
Татар телең өчен яратам.
Мин яратам Әлмәт, Яр Чаллыны,
Киң күңелле Казан каласын.
Илем бакчасында, Татарстан,
Ал канәфер булып янарсың.

Р. Рәкыйпов

# 1–3 нче дәресләр

1. Татарстан Республикасы турында укыгыз.

Без Татарстан Республикасында яшибез. Татарстан Республикасы Россия Федерациясе составына керә. Республикабыз калын урманнарга, мул сулы елгаларга, киң болыннарга бай. Габдулла Тукай аның табигате турында болай язган:

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.
Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк,
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк...

Татарстан Россиянең җиде субъекты белән чиктәш һәм тыгыз бәйләнештә яши: Киров, Самара, Ульяновск өлкәләре, Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия, Чувашия республикалары. Аның мәйданы Бельгия, Швейцария, Шри-Ланка кебек илләрнекеннән зуррак.

Татарстан — күпмилләтле республика. Гасырлар дәвамында республика территориясендә төрле халык, төрле дин вәкилләре бер-берсен хөрмәт итеп яши. 2002 елгы Бөтенроссия халык санын алу нәтиҗәләре буенча, Татарстанда 115 халык вәкиле теркәлгән, ә бүген — 170 тән артык исәпләнә. Республика милләтара һәм конфессияара дуслык ягыннан үрнәк төбәк булып тора.

**чиктәш** — граничащий, пограничный
**тыгыз бәйләнештә** — в тесном контакте
**төрле дин вәкилләре** — представители разных религий
**тату** — дружно
**халык санын алу** — перепись населения
**теркәлгән** — зарегистрировано
**милләтара һәм конфессияара** — межнациональный и межконфессиональный

2. 1 нче күнегү эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

3. Татарстан һәм Россиянең символикасы турында бер-берегезгә сөйләгез. Иң яхшы сөйләүчене билгеләгез.






4. Төркемнәрдә Татарстанда халыклар дуслыгы турында фикер алышыгыз, диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

5. Дөрес тәрҗемәне билгеләгез.

| | | |
|---|---|---|
| Агыйдел | ? | Вятка |
| Идел | | Волга |
| Ык | | Белая |
| Нократ | | Ик |

6. Мәгълуматны укыгыз һәм бер-берегезгә сөйләгез.



Татарстан табигате турында күбрәк белегез

Татарстан буйлап 4 зур елга ага: Идел, Кама, Агыйдел, Нократ. Ә Татарстанда иң озын елга — Кама. Ул Татарстан территориясе буйлап 380 километр ага. Ык елгасының гомуми озынлыгы — 436 километр. Шуның 200 километрга якын өлеше Татарстан территориясеннән ага.

7. Картаны өйрәнегез һәм, Татарстан территориясе, чикләре, шәһәрләре турында диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез!



**8.** Сүзләрнең логик парларын табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| күпмилләтле | | тау |
| туган | | урман |
| калын | | кыш |
| эссе | ? | теле |
| салкын | | табигать |
| бай | | җир |
| дәүләт | | республика |
| биек | | җәй |

**9.** Сообщите другу о том, что:

— Татарстан — республика в составе Российской Федерации;
— Татарстан имеет собственную символику;
— в Татарстане развита машиностроительная, лёгкая, химическая и пищевая промышленность.

**10.** Җөмләләрне дәвам итегез. Сораулар куеп, үзара сөйләшегез.

Татарстанның башкаласы — ... .
Татар халкының милли бәйрәме — ... .
Татарстанның иң зур байлыгы — ... .
Татарстанның иң озын елгасы — ... .
Татарстанның иң зур шәһәрләре — ... .

**11.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәп языгыз, үзара сөйләшегез.

1. — ... ?
— Татарстанның табигате искиткеч бай, матур.
— ... ?
— Анда һава бик эссе дә, бик салкын да түгел. Тукайча әйткәндә, урта һава.
— ... ?
— Әйе, безнең урманда күптөрле җиләк-җимешләр үсә: балан, миләш, бөрлегән, каен җиләге, җир җиләге.
— Ә быел җәй син кайда булдың?
— ... .

2. — Альбина, Татарстан Республикасы нинди республикалар белән чиктәш?
— ... .
— Ә Башкортстан Республикасының территориясе зурмы?
— Әйе, Башкортстан Республикасының мәйданы да искиткеч зур.

— Ә Татарстанныкыннан зурракмы?
— ... .

3. — Альберт, Татарстан гимнының авторы кем?
— ... .
— Ә син Россия гимнын беләсеңме?
— Әйе. Аның сүзләрен ... , музыкасын ... язган.
— Беренче куплетын сөйләп күрсәт әле.

4. — Татарстанда нинди милләт вәкилләре яши?
— ... .
— Татарстанда милләтара һәм конфессияара татулык нәрсәдә күренә?
— ... .

**12.** Сез Татарстан Республикасы белән горурлана аласызмы? Төркемнәрдә фикер алышыгыз, чыгыш ясарга әзерләнегез.

## 4–6 нчы дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Татарстанның икътисади (экономик) үсешенә нинди бәя бирерсез?

Татарстан — Россиянең икътисади (экономик) яктан иң нык үскән төбәкләренең берсе. Республика Россия Федерациясенең эре индустриаль районының үзәгендә, илнең көнчыгыш һәм көнбатышын, төньяк һәм көньягын тоташтыручы мөһим магистральләр кисешкән урында урнашкан.



Татарстанда машина, химия, азык-төлек сәнәгате, җиңел сәнәгать үскән. Казан вертолёт заводы, С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе, Казан синтетик

каучук заводы, «Казан Оргсинтез», «Түбән Кама Нефтехим», «Аммоний», «Нәфис», «Мелита» һ. б. предприятиеләренең продукцияләре бөтен дөньяга билгеле.

«КАМАЗ»да чыгарылган йөк машиналары Европа, Азия, Африка, Латин Америкасы илләренә сатыла. Озак еллар Дакар раллиенда Семён Якубов җитәкчелегендә «КАМАЗ-мастер» командасы беренчелекне бирмәде. «КАМАЗ-мастер» командасы — Россиядә бердәнбер завод командасы. Ул бөтендөнья чемпионатларында 19 тапкыр призлы урыннар яулады. Команда составына кергән Владимир Чагин, Фирдәвес Кәбиров, Илгизәр Мәрдиев исемнәре бөтен дөньяга танылган. Sportbox.ru Интернет порталы уздырган тавыш бирүдә «2010 нчы ел гыйнвар аеның иң яхшы спортчысы» исеменә Владимир Чагин лаек булды.

Вакытлы матбугаттан

**машина төзелеше** — машиностроение
**җиңел сәнәгать** — лёгкая промышленность
**химия сәнәгате** — химическая промышленность
**азык-төлек сәнәгате** — пищевая промышленность
**төбәк** — регион
**дөньяга танылган** — всемирно известный

**2.** Тексттагы җөмләләрне кулланып, эчтәлеккә план төзегез.

**3.** Тексттагы һәр абзацның эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

**4.** Кайда нинди продукция эшләнә?



Казан вертолёт заводында — ... .
«Казан Оргсинтез» предприятиесендә — ... .
«Мелита»да — ... .
«Аммоний»да — ... .
«КАМАЗ»да — ... .
Менделеевск шәһәрендәге химия заводында — ...
«Түбән Кама Шин» заводында — ... .



Татарстан икътисады





5. Җөмләләрне киңәйтеп языгыз.

1. Йөк машиналары сатыла.
2. «КАМАЗ-мастер» командасы бирми.

6. Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез.

1. — ... ?
— Әйе, мин матур тун алдым.
— ... ?
— «Мелита» мех фабрикасында.
— Ул фабрикада тагын нәрсәләр эшләнә?
— ... .

2. — Син Дакар раллиен карадыңмы? Ул соңгы тапкыр кайда үтте?
— ... .
— ... ?
— Әйе, Татарстан экипажлары беренче урыннарны алдылар.
— Алар кемнәр?
— ... .

## 7–8 нче дәресләр

1. Текстны укыгыз. Татарстанның икътисади үсешенә нинди яңа технологияләр кертелә?

Татарстанның икътисады елдан-ел көчлерәк үсеш ала, шуңа күрә республика Россия төбәкләре арасында икътисади яктан аеруча тотрыклы дип санала.

Республиканың иң үскән икътисади юнәлешләрен түбәндәгеләр тәшкил итә:

нефть чыгару, синтетик каучук, шиннар, полиэтилен һәм нефтьне эшкәртү продуктларын җитештерү;

авыр йөк машиналары, вертолётлар, самолётлар һәм авиадвигательләр, компрессорлар һәм нефть-газ кую җиһазлары, елга һәм диңгез суднолары, җиңел автомобильләр җитештерү.

Татарстан Республикасында технопарклар челтәре актив үстерелә. «Идея» инновация-җитештерү технопаркы» ябык акционерлык җәмгыяте, «Мастер» КИП индустриаль мәйданчыгы, IT-парк, «Химград» технополисы уңышлы эшләп килә.

Татарстанда 2030 елга кадәр республиканы фәнни-техник яктан үстерү буенча дәүләт программасы расланды. Программаның төп стратегик максатлары 2030 елга Татарстан Республикасының яңа икътисади

тармакларын формалаштыру һәм үстерү өчен фәнни-технологик нигез, инновацион үсеш өчен көндәшлеккә сәләтле фәнни-белем бирү мохите булдыру, фән һәм технологияләр өлкәсендә талантларны табу һәм үстерү өчен шартлар тудыру дип билгеләнгән. Шулай ук интеллектуаль продуктлар базарын, фән һәм технологияләр өлкәсендә нәтиҗәле идарә итү системасын формалаштыру, Татарстанның фәнни-технологик үсеше буенча фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләрен популярлаштыруга ярдәм итә торган конгресс-күргәзмә чараларын үткәрү бурычлары да куела.

**мохит** — среда
**төбәк** — регион
**тотрыклы** — устойчивый
**җитештерү профиле** — производственный профиль
**җитештерү** — производство
**чаралар** — мера, мероприятия

**2.** Республиканың икътисади юнәлешен күрсәткән җөмләләрне табып укыгыз.

**3.** Сорауларга җавап табып, үзара сөйләшегез.

1) «Нефть-газ химиясе комплексы» төшенчәсен ничек аңлыйсыз?

2) Машина төзелеше тармагының зур предприятиеләрендә нәрсәләр җитештерелә?

3) Авыр йөк машиналары, вертолётлар, самолётлар һәм авиадвигательләр, компрессорлар һәм нефть-газ кую җиһазлары, елга һәм диңгез суднолары, җиңел автомобильләр Татарстанда кайда җитештерелә?

4) Татарстанның икътисади үсеше буенча 2030 елга кадәр нинди дәүләт программасы расланган?

**4.** 2030 елга кадәр республиканы фәнни-техник яктан үстерү буенча дәүләт программасының стратегик максатлары ничек дип билгеләнгән? Дәфтәрегезгә һәр максатны аерып языгыз, тәрҗемә итегез. Төркемнәрдә бер-берегезгә сөйләгез.

**5.** Тәрҗемә итегез.

1) В экономике Татарстана добывается около 7% нефти и производится более 31% грузовых автомобилей, 42% синтетического каучука, 52% полиэтилена и около 34% автомобильных шин от соответствующих объёмов выпуска, наблюдаемых в целом по стране.

2) В регионе хорошо развито сельское хозяйство, пищевые предприятия поставляют продукцию (пищевая соль, кондитерские, хлебобулочные изделия, мясо птицы) в районы республики и в соседние субъекты Российской Федерации.

**6.** Татарстанда нинди технопарклар челтәре актив эшли? Интернеттан алар турында материаллар туплап, кыскача гына белешмә языгыз.

**7.** Рәсемнәрдә нинди маркалы машиналар күрсәтелгән? Алар турында сез нәрсәләр сөйли аласыз?










**8.** Татарстанның икътисади үсеше турында Интернет аша мәгълүмат туплагыз, сөйләргә өйрәнегез.




**9.** Сообщите другу о том, что:

— вы живёте в Республике Татарстан;
— Республика Татарстан входит в состав Российской Федерации;
— в Республике Татарстан развиты машиностроение, сельское хозяйство.

# 9–11 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**




2. Җөмләләрнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләгез.

1. Минем бик кызыклы китабым бар. 2. Китапны иң кадерле урында саклаганнар. 3. Китапның битен бөкләмә. 4. Ул тугызынчы сыйныфта укый. 5. Балалар китап күргәзмәләре оештыралар. 6. Бу дөньяда китаптан да яхшырак юлдаш юк. 7. Татарстанда нефть чыгару 1940 нчы елда башлана. 8. Түбән Камада нефть эшкәртү заводы эшли.

Татарстан нефте турында күбрәк белегез



3. Җөмләләрне укыгыз, җөмлә кисәкләре буенча тикшерегез.

1. Татарстан җирләре нефтькә бай. 2. Нефтьче — авыр һәм мактаулы һөнәр. 3. Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Бөгелмә җирләрендә нефть

аеруча күп табыла. 4. Татарстанда чыгарылган нефть чит илләргә дә җибәрелә. 5. Татарстанда нефть эшкәртү предприятиеләрендә мазут, бензин, дизель ягулыклары җитештерелә.

4. Түбәндәге сүзтезмәләрне транскрипция билгеләре белән языгыз. Алар белән җөмләләр төзегез.

Кара алтын, табигый байлык, нефть чыгару үзәге, башка төбәкләр, нефть эшкәртү.

5. Текстны укыгыз, җөмлә кисәкләрен билгеләгез.

### Татарстан — «кара алтын» республикасы




Татарстанның иң зур табигый байлыгы — нефть. Илебездә нефть сәнәгате тарихы 1864 нче елда башлана. Беренче нефть фонтаны Кудако елгасы (Кубань елгасының кушылдыгы) үзәнендә 1866 нчы елда күтәрелә. Республикабызда нефть чыгару 1940 нчы елларда ук башланып китә. Нефть беренче мәртәбә Шөгер, Ромашкино тирәләрендә чыгарыла. Ромашкино ятмасы — Россиядә нефть чыга торган урыннарның иң зурларыннан берсе. Бүген Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә, Алабуга, Баулы, Лениногорск шәһәрләре, Җәлил, Карабаш эшчеләр посёлоклары нефть чыгару үзәкләре булып тора. Татарстан хәзерге көндә 3 миллиард тоннадан артык нефть чыгаруга иреште. Нефть чыгаруның суммар күрсәткече буенча Татарстан дөньяда 10 нчы урында тора.

Татарстанда чыгарылган нефтьнең күп өлеше Россиянең башка төбәкләренә һәм чит илләргә җибәрелә. Түбән Камада нефть эшкәртү предприятиесе эшли. Анда нефтьтән мазут, бензин һәм дизель ягулыклары җитештерелә. Татарстанны чын мәгънәсендә «кара алтын» республикасы дип йөртәләр.

**елга үзәнендә** — в устье реки **күрсәткеч** — показатель
**нефть чыга торган урын** — месторождение нефти

6. Бу раслауларның кайсы дөрес?

1. Татарстанның иң зур байлыгы — газ.
   Татарстанның иң зур байлыгы — нефть.

2. Татарстанда нефть беренче мәртәбә Азнакай якларында чыгарыла. Татарстанда нефть беренче мәртәбә Әлмәт якларында чыгарыла.
3. Татарстан бүген 3 миллиард тоннадан артык нефть чыгарды. Татарстан бүген 2 миллиард тоннадан артык нефть чыгарды.

**7.** Җөмләләрне киңәйтеп языгыз. Һәр яңа җөмләгә сораулар куегыз.

1. Нефть чыгару башланып китә.
2. Татарстан ирешге.
3. Түбән Камада эшли.

**8.** Җөмләләргә тиешле җөмлә кисәкләрен өстәп языгыз. Җөмләләргә өсораулар куегыз.

1. 1940 нчы елда Татарстанда ... . 2. ... 3 млрд тоннадан артык нефть ... . 3. ... чит илләргә ... . 4. Түбән Камада нефтьтән мазут ... .

**9.** Җөмләләрдән ия белән хәбәрне табыгыз.

— Татарстанның зур табигый байлыгы — нефть.
— Беренче нефть чыганаклары — Тимәш, Ромашкино, Баулы.
— Татарстанда нефть эшкәртү сәнәгате үскән.
— Татарстанда чыгарылган нефтьнең күп өлеше чит илләргә китә.
— Татарстан авылларына газ кертелгән.
— Әлмәт — нефтьчеләр шәһәре.

**10.** Текст эчтәлеге буенча диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**11.** Тәрҗемә итегез. Җөмләләрнең ия, хәбәрен билгеләгез.

На территории республики открыто 127 нефтяных месторождений, ведётся обширная добыча известняка, глины, строительного песка и горючих сланцев. Химическая промышленность представлена заводами по производству пластика, нефтеполимерной смолы, каучука, лакокрасочных материалов.

**12.** Сез беләсезме?

Татарстанның нефть тарихы Лениногорск нефть музеенда тупланган. Монда 1941 нче елның беренче «кара алтын» фонтаныннан алып бүгенге катлаулы технологияләргә кадәр нефть тарихын өйрәнергә була. Шулай ук Шөгердәге беренче скважина урынында ачык һавада да музей бар.



**13.** 12 нче күнегү эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

# ТАТАРСТАН СӘНГАТЕ

## 12–14 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз.

**Татарстан — уникаль мәдәни-тарихи мираска ия республика. Күп кенә күренекле мәдәният эшлеклеләренең тормышы республикабыз белән бәйле: җырчы Фёдор Шаляпин, язучылар Лев Толстой, Сергей Аксаков һәм Максим Горький, Василий Аксёнов; шагыйрьләр Евгений Боратынский, Гавриил Державин, Марина Цветаева һәм Никита Заболоцкий, рәссамнар Иван Шишкин һәм Николай Фешин, музыкантлар Олег Лундстрем һәм Михаил Плетнёв.**









**Татар милли сәнгате бүген дөньякүләм югарылыкка күтәрелде. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының Франция, Дания, Швейцария, Германия, Бельгия, Голландия, Австриядәге гастрольләре; симфоник оркестрның Японидә, Франциядә, Зур театрда, Мария (Мариинский) театрында концертлары; Камал театрының Шанхайда, Будапештта, Хельсинкида гастрольләре; Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең — Франциядә, дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең Италиядә чыгышлары Россиянең, Татарстанның данын югары күтәрә.**



Татарстанның аерым горурлыгы — Казан Халыкара мөселман киносы фестивале. Ул беренче көннәреннән үк төрле мәдәният һәм конфессия вәкилләре арасында конструктив диалог өчен мәйданчык, күпмилләтле республикабызның визит карточкасы булды. Фестиваль Татарстан башкаласында 2005 елдан бирле «Мәдәниятләр диалогы аша диалог культурасына» девизы белән үткәрелә. Анда төп максат — Россия һәм чит илләр кинематографистларының тәҗрибә уртаклашуы аша иҗади казанышларны күрсәтү. Фестиваль фильмнары кешеләрне рухи-әхлакый кыйммәтләрне сакларга, тынычлыкка һәм гаделлеккә чакыра.

**2.** Татарстанда нинди зур сәнгать оешмалары бар? Алар кайларда чыгышлар ясаганнар? Тексттан аерып языгыз, тәрҗемә итегез.

**3.** Текстка план төзегез. План пунктлары буенча текстның эчтәлеген төркемнәрдә бер-берегезгә сөйләгез.

**4.** Татарстанда яшәгән күренекле мәдәният эшлеклеләренең кайсы сезгә күбрәк таныш. Аның турында сөйләргә әзерләнегез.

**5.** «Мәдәниятләр диалогы аша диалог культурасына» дигән фикерне ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә чыгышка әзерләнегез.

**6.** Татарстан мәдәнияте чит илләргә нәрсә белән танылды? Тексттан җаваплар табыгыз, бер-берегезгә сөйләгез.

**7.** Тәрҗемә итегез.

Широкую известность получили международные фестивали: оперный им. Ф.И. Шаляпина, классического балета им. Р. Нуриева, современной музыки «Европа — Азия», театральный фестиваль тюркских народов «Науруз», открытый республиканский телевизионный молодёжный фестиваль эстрадного искусства «Созвездие-Йолдызлык».

**8.** Текстны укыгыз. Татарстан Республикасы нинди тарихи мираска ия?

Татарстан Республикасы гаять зур тарихи мираска ия. ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән тарихи истәлекләрнең өчесе Татарстан территориясендә урнашкан: Казан Кремле, Свияжск утрау-шәһәрендәге Успение соборы һәм монастыре, Болгар архитектура-тарихи комплексы.

Казан Кремлен шәһәрнең үзәге дип атыйлар. Биредә тарихи архитектура истәлекләре: Сөембикә манарасы, Благовещение соборы, Кол Шәриф мәчете, Спас манарасы һәм башка һәйкәлләр бар.



Болгар шәһәре Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласы булган. Болгар комплексы 2014 елда ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде. Болгарның изге урыннарын, матур мәчетне һәм дөньядагы иң зур басма Коръәнне күрү өчен, Болгарга 50 меңгә кадәр кунак килә.

Свияжск утрау-шәһәре Зөя елгасы эчендәге биек калкулыкта урнашкан. Аңа Явыз Иван тарафыннан 1551 нче елда нигез салына. Бүген ул ачык һавадагы музей булып тора.





**9.** Текст эчтәлегенә план төзегез. План буенча үзара сөйләшегез.

**10.** Казан Кремленең нинди тарихи истәлекләре бар? Алар турында Интернет аша кыскача белешмә туплагыз, сөйләргә өйрәнегез.

**11.** Тәрҗемә итегез.

После Москвы и Санкт-Петербурга Татарстан стал третьим регионом в стране, обладающим памятниками культуры мирового значения. Казанский Кремль был включён в список ЮНЕСКО в 2000 году.

**12.** Ә сез беләсезме? Мәгълүматны бер-берегезгә сөйләп карагыз.

**Казан — туристлар шәһәре**

Туристлык олимпына Казан 2005 нче елда, Татарстан башкаласы үзенең меңьеллыгын бәйрәм иткәндә күтәрелә башлый. Юбилей елында шәһәргә 500 мең кунак килә. Универсиада елында Казан 1,5 млн кунак кабул итә. Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты уздырылган елда — 2,1 млн, 2016 нчы елда — 2,5 млн, ә футбол буенча дөнья чемпионаты уздырылган елда Татарстан башкаласы 3 млн турист кабул итә. 2030 нчы елга Казан 5 миллион туристны каршы алырга әзерләнә.

Казан Кремле, Бауман урамы, «Казан» гаилә үзәге, Кремль яр буе һәм Кабан күле яр буе, «Ривьера» аквапаркы һәм башка истәлекле урыннарда туристларны бик еш очратырга була.

## 15–16 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Кушма җөмлә**
Сложное предложение

Предложения, состоящие из нескольких простых предложений, называются сложными.

Ике яки икедән артык гади җөмләдән торган җөмлә **кушма җөмлә** (сложное предложение) дип атала.

Сложносочинёнными называются предложения, в которых простые связываются друг с другом интонацией и сочинительными союзами.

Гади җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә **тезмә кушма җөмлә** (сложносочинённое предложение) дип атала.

В сложноподчинённом предложении придаточное предложение подчиняется главному при помощи подчинительных союзов.

Гади җөмләләре үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә **иярченле кушма җөмлә** (сложноподчинённое предложение) дип атала.



**2.** Беренче татар китаплары турында белешмәне укыгыз. Эчтәлек буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез. Тексттагы җөмләләрнең төрләрен билгеләгез.



Татар телендәге беренче китап гарәп хәрефләре белән языла һәм 1612 нче елда Лейпциг шәһәрендә басыла.

XVIII гасырның 20 нче елларында Пётр I Персия походына әзерләнә, походта татарлар да катнашырга тиеш була. Походка әзерләнү уңаеннан, Пётр I «Манифест» яза, һәм ул 1722 нче елда татар телендә аерым китап итеп бастырыла. Ул — Россиядә чыккан беренче татар китабы.

**3.** Җөмләләрдән ия белән хәбәрне табыгыз.

1. Татар халкы укымышлы булган, шуңа күрә китапка һәрвакыт хөрмәт белән караган. 2. Беренче китапханә «Шәрык китапханәсе» дип атала. 3. Татар телендәге беренче китап гарәп хәрефләре белән языла һәм 1612 нче елда Лейпциг шәһәрендә басыла.

**4.** Төшеп калган репликаларны өстәп, диалогны язып бетерегез, үзара сөйләшегез.

— ... ?
— Ул 1612 нче елда Лейпциг шәһәрендә басыла.
— ... ?
— 1722 нче елда.
— ... ?
— Гарәп хәрефләре белән языла.

**5.** Гади һәм кушма җөмләләрне кулланып, 2 нче күнегүдәге текстның эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**6.** Гади җөмләләрдән кушма җөмләләр төзеп языгыз.

1. Китап — белем чыганагы. 2. Китап иң кадерле урында сакланган.

**7.** Җөмләләрне дәвам итеп, кушма җөмләләр төзегез.

1. Китапханәдә кычкырып сөйләшергә ярамый, ... . 2. Өйдә китап иң кадерле урында сакланган, ... . 3. Мин китапханәгә бардым, ... . 4. Китапханә ябык, ... . 5. Хәзер Интернет аша да укырга була, ләкин ... .

8. Поинтересуйтесь у библиотекаря, есть ли в библиотеке:

— исторические книги;
— книги на татарском языке;
— книги, напечатанные арабским шрифтом;
— серия «Жизнь замечательных людей».

9. Как скажете в следующих ситуациях общения? Напишите в тетрадь.

— Сообщите, что первые книги были сделаны из глины.
— Пригласите товарища сходить с тобой в библиотеку.
— Предложите другу почитать книгу о Казани.
— Спросите друга, нет ли у него дома книги о Казани.
— Сообщите, что самая большая библиотека Татарстана находится в Казани.

10. Үзегез яратып укыган китап турында сөйләргә әзерләнеп, төркемнәрдә бер-берегезгә сөйләгез.

## 17 нче дәрес

1. Тәрҗемә итегез.

Үрнәк: народный артист Республики Татарстан — Татарстан Республикасының халык артисты

1) Татарский государственный академический театр — ...
Государственная премия имени Габдуллы Тукая — ...
Казанское музыкальное училище — ...

2) известный художник Харис Якупов — ...
великий поэт Габдулла Тукай — ...
знаменитый композитор Салих Сайдашев — ...

3) рус милләте — ...
рус милләтеннән — ...
музыка — ...
татар музыкасы — ...
татар халык көе — ...
татар халык көйләре — ...

татар милләте — ...
татар милләтеннән — ...
сәнгать — ...
музыка сәнгате — ...
рус халык көе — ...
рус халык көйләре — ...

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез. Кем нәрсә эшли?

Җырчы … .
Композитор … .
Шагыйрь … .
Язучы … .
Скрипкачы … .

Рәссам … .
Режиссёр … .
Артист … .
Балетмейстер … .
Продюсер … .

**3.** Сүзләрне, сүзтезмәләрне тәрҗемә итегез. Дөрес укырга өйрәнегез, сүзләр белән гади җөмләләр төзегез.

Җырчы, атаклы, сәнгать, сынлы сәнгать, музыка сәнгате, көй, нигез салучы, милли, халык, сәхнә әсәре, тамашачылар, горурлык, горурлана, танылган, таныла, ихтирам казана, данлыклы, шәхес, рәссам.

**4.** Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзегез, аларның баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләгез.

1) Александр Ключарёв, иҗат иткән, рус, ләкин, татар, милләтеннән, ул, көйләрен.

2) Нигез салучы, профессиональ, Салих Сәйдәшев, музыкасына, татар, композитор.

**5.** Тәрҗемәне дәвам итегез. Исемнәрнең кушымчаларын билгеләгез. Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзегез.

1) Казанская консерватория — Казан консерваториясе
Московская консерватория — …
Казанская филармония — …
театральное училище — …
музыкальное училище — …

2) в татарском театре — татар театрында
в русском театре — …
в школе искусств — …
в спортивном зале — …

**6.** Как скажете о том, что вы были:

— в театре Г. Камала;
— в музее С. Сайдашева;
— в школе искусств?

7. Спросите у друга:

— знает ли он Казань;
— какие исторические места в Казани он знает;
— был ли он в Казанском Кремле;
— был ли он в музее С. Сайдашева;
— был ли он в музее Г. Тукая.

## 18–20 нче дәресләр

1. Текстны укыгыз.

**Сәнгать дөньясында**




Татар музыка сәнгатенә нигез салучылар дип Салих Сәйдәшев, Александр Ключарёв, Җәүдәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Мансур Мозаффаров, Нәҗип Җиһановларны атыйбыз. 1925 нче елда беренче татар операсы — «Сания», 1930 нчы елда икенче опера — «Эшче» языла. Авторлары — Солтан Габәши, Газиз Әлмөхәммәдов, Василий Виноградов. 1930 нчы елларда Нәҗип Җиһанов — «Алтынчәч», «Җәлил», Мансур Мозаффаров «Галиябану» операларын иҗат итәләр. 1939 нчы елда Казанда Татар опера һәм балет театры ачыла. Бу театр хәзер Муса Җәлил исемен йөртә.

Татар музыка сәнгате үсешенә Заһидулла Яруллин зур өлеш кертә. Заһидулла Яруллин — беренче кыллы оркестр төзегән татар музыканты, «Тукай маршы» авторы. Аның улы Фәрит Яруллин — татар милли балетына нигез салучы. Ул — «Шүрәле» балеты авторы. Композитор Рөстәм Яхин — беренче татар фортепиано концерты, Татарстан Дәүләт гимны авторы. Ул үз әсәрләрен фортепианода оста башкаручы буларак та киң танылды.

Сара Садыйкова, Луиза Батыр-Болгари, Резеда Ахиярова, Зиннур Гыйбадуллин, Фасил Әхмәтов, Әнвәр Бакиров һәм башка композиторлар халык яратып җырлый торган җырлар иҗат иттеләр. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева, Зәйнәп Фәрхетдинова, Зөфәр Билалов, Римма Ибраһимова, Венера Ганиева — татар халкының яраткан җырчылары. Остазларының эшен

яшь җырчыларыбыз Гүзәл Уразова, Илдар Хәкимов, Илназ Минвәлиев, Мөнир Рахмаев, Иркә, Илнар Сәйфиев, «Эссе», «Казан егетләре», «Зө-Ләй-Лә» һәм башка төркемнәр дәвам итә.

Татар сынлы сәнгатенә Бакый Урманче, Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Илдар Зарипов, Виктор Кудельюн, Садри Ахун, Рада Нигъмәтуллина кебек танылган осталарыбыз зур өлеш кертте.

Бакый Урманче — татар сынлы сәнгатенә нигез салучы. Аның иҗаты күпкырлы: ул сыннар да, портретлар да, пейзажлар да иҗат иткән. Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Нәҗип Җиһанов, Нәкый Исәнбәт, Фатих Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗанинең скульптур портретлары — чын сәнгать әсәрләре.

Харис Якупов — СССРның халык рәссамы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Вакытлы матбугаттан

**нигез салучы** — основоположник
**кыллы** — струнный
**киң танылды** — стал широко известен
**йөртә** — носит
**остаз** — наставник
**оста** — мастер

**2.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табыгыз.

1. Беренче татар балеты.
2. Беренче татар операсы.
3. Татар опера һәм балет театры ачылу.
4. Салих Сәйдәшевнең иҗаты.

«Җәлил» операсы турында мәгълүмат

**3.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.

1. Заһидулла Яруллин — ... авторы.
2. Фәрит Яруллин — беренче татар ... .
3. Җәүдәт Фәйзи — ... .
4. Харис Якупов — ... .
5. Бакый Урманче — ... .

**4.** Тәрҗемә итегез. Җөмләләрнең ия белән хәбәрен табыгыз. Исегезгә төшерегез: ия белән хәбәр арасына кайчан сызык куела? Җөмләләргә сораулар куеп, үзара сөйләшегез.

Султан Габаши — автор первых татарских опер «Сания» и «Эшче».
Фарид Яруллин — автор первого татарского балета.
Салих Сайдашев — основоположник татарского профессионального музыкального искусства.
Назиб Жиганов — основатель Казанской консерватории.
Сара Садыкова — автор многих татарских лирических песен.
Рустем Яхин — автор первого татарского фортепианного концерта.
Мунира Булатова — известная оперная певица.

5. Как скажете о том, что:

— первая татарская опера называлась «Сания»;

— в 1930 году была написана опера «Эшче»;

— Загидулла Яруллин внёс большой вклад в развитие татарской национальной музыки;

— Салих Сайдашев, Александр Ключарёв, Фарид Яруллин, Мансур Музаффаров, Назиб Жиганов являются основоположниками татарской национальной музыкальной культуры;

— Харис Якупов — народный художник СССР;

— Фарид Яруллин — автор балета «Шурале»?

6. Текcттагы сәнгать вәкилләрен таблицага языгыз.

| Композиторлар | Җырчылар | Рәссамнар |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

7. Текстка план төзегез. Текст эчтәлеген бер-берегезгә сөйләргә әзерләнегез.

8. Җөмләләрне укыгыз һәм җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез. Җөмлә төрләрен билгеләгез.





1. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында һәр елны Ф. Шаляпин исемендәге опера сәнгате һәм Р. Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивальләре үткәрелә.





2. Сара Садыйкова өч йөздән артык җыр, ике комедиягә музыка, романслар, вальслар иҗат итә, ул безгә лирик җырлар авторы буларак та якын.

9. Посоветуйте другу:

— прослушать песни Сары Садыковой;

— прочитать книгу о знаменитом композиторе;

— посетить выставку картин художников;

— сходить в книжный магазин и купить сборник стихов Габдуллы Тукая;

— посетить Национальный музей Республики Татарстан;

— сходить на концерт молодых исполнителей;

— посмотреть балет в театре имени Мусы Джалиля.

**10.** Сообщите другу о том, что:

— скоро в ваш город с новой программой приедут Гузель Уразова и Ильдар Хакимов;

— в концерте примут участие много молодых талантливых певцов;

— вам нравятся песни в исполнении группы «Эссе».

**11.** Диалогны тулыландырыгыз, сөйләргә өйрәнегез.

— Оля, әйдә иртәгә концертка барабыз.

— Минем театрга барасым килә.

— Әйдә инде концертка барыйк. Яшь җырчылар килә.

— Кемнәр килә?

— ... .

— Яхшы. Мин барырга риза. Миңа да билет ал, зинһар.

**12.** Как скажете о том, что:

— автором первого татарского балета «Шурале» является Фарид Яруллин;

— автором балета «Су анасы» является Анвар Бакиров;

— в Казани ежегодно проводится Международный фестиваль оперного искусства имени Фёдора Шаляпина;

— в Казани проводится Международный фестиваль классического балета имени Рудольфа Нуриева;

— в 1937 году была открыта Татарская филармония;

— в 1939 году был открыт Татарский театр оперы и балета;

— в 1958 году была учреждена премия имени Габдуллы Тукая?

**13.** 12 нче күнегү эчтәлеге буенча сораулар төзегез, үзара сөйләшегез.

14. Афишаларга карап, диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.










## 21–23 нче дәресләр

1. **Исегезгә төшерегез!**

**Теркәгечләр**
Союзы

**Тезүче** (сочинительные) һәм **ияртүче** (подчинительные) теркәгечләр була.

**Тезүче теркәгечләр:**

1) җыючы (собирательные): һәм, да-дә, та-тә, янә, ни һ.б.
2) каршы куючы (противительные): ләкин, ә, тик, әмма һ.б.
3) бүлүче (разделительные): я, яки, яисә, әле, әллә һ.б.

**Ияртүче теркәгечләр:**

чөнки, әгәр, гүя, ягъни, ки, гәрчә һ.б.

2. Җөмләләрне укыгыз. Теркәгечләрне табып, төркемчәләрен билгеләгез.

1. А. Ключарёв — рус милләтеннән, ә үзе татар көйләре язган. 2. Бүген концертта А. Ключарёв һәм С. Сәйдәшев көйләренә язылган җырлар яңгыраячак. 3. Без бүген я Г. Камал театрына, я опера һәм балет театрына барабыз. 4. Пәрдә ачылгач, сихри музыка яңгырады, гүя ул безне әкият иленә алып кереп китте.

**3.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. А. Ключарёв — рус милләтеннән, ләкин ... .
2. Артистлар сәхнәгә күтәрелде, һәм тамашачылар ... .
3. Без бүген театрга барырга уйладык, әмма ... .
4. Спектакль күп еллар элек булган вакыйгалар турында булса да, ... .

**4.** Бу сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

Сәнгать, сихерле, моң, сәүдә, хисапчы, тәрбияли, ямь, гармун, күршеләр, аралаша, уңышлар.

**5.** Тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

җырлар — ...
татар җырлары — ...
сихри музыка — ...
татар музыкасы — ...
көй — ...
моңлы көй — ...
халык көе — ...
татар халык көйләре — ...

җырчылар — ...
сәхнә — ...
күренекле композитор — ...
күренекле рус композиторы — ...
милли көй — ...
рус көе — ...
рус халык көе — ...
рус халык көйләре — ...

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез.

— Салих Сәйдәшев — күренекле татар композиторы.
— Фёдор Шаляпин — ... .
— Людвиг ван Бетховен — ... .

**7.** Тәрҗемәне дәвам итегез, исемнәрнең кушымчаларын билгеләгез, җөмләләр төзегез.

1. в Казанской консерватории — Казан консерваториясендә
   в Московской консерватории — ...
   в Казанской филармонии — ...
   в театральном училище — ...
   в музыкальном училище — ...

2. в Камаловском театре — Камал театрында
   в Качаловском театре — ...
   в школе искусств — ...
   в спортивном зале — ...

**8.** Композитор Александр Ключарёв турында укыгыз.



Александр Ключарёв — татар музыка сәнгатендә күренекле шәхес. Ул — Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. А. Ключарёв рус милләтеннән, ләкин ул татар композиторы буларак танылган.

А. Ключарёвның әтисе Сергей Данилович зур сәүдә йортында хисапчы булып эшләгән, ә әнисе Надежда Семёновна өйдә балалар тәрбияләгән.

Ключарёвларның өендә балалар өчен һәрвакыт газета-журналлар була, музыка яңгырап тора. Гаилә башлыгының балаларын зыялы итеп үстерәсе килә: ул граммофон сатып ала, популяр җырчылар Ф. Шаляпин, А. Нежданова язмаларын алып кайта. Бергәләп кинотеатрга бару, табигатьтә ял итү, балык тоту, көймәдә йөрүләр гаиләдә матур гадәткә керә. Күп тә үтми, өйдә музыка уен кораллары — гитара, мандолина, балалайка, гармун барлыкка килә. Надежда Семёновна үзе дә гармун уйный.

Сашаның музыкаль сәләте бик иртә ачыла. Биш яшендә инде ул ишеткән көйләрен гармунда чыгара башлый. Малайның гармунны күтәрергә көче җитми, шуңа күрә ул аны урындыкка куеп уйный. Гимназиядә укый башлагач, скрипкада, пианинода уйнарга өйрәнә.

Ключарёвларның күршеләрендә Гали исемле татар кешесе яши. Ул татар-башкорт җырларын көйләп йөри, шуңа күрә татар моңы Саша күңелендә балачактан урын ала.



Александр музыка училищесын тәмамлый һәм театр училищесында эшли башлый. Шул вакытта ул татар студентлары белән аралаша һәм алар белән гастрольләргә йөри. Ул татар телен, татар музыкасын, татарларның милли гореф-гадәтләрен өйрәнә.

Мәскәү консерваториясендә укыганда, ул Муса Җәлил, Сара Садыйкова, Заһид Хәбибуллин һәм башка татар композиторлары белән аралашып яши, татар музыкасын өйрәнә. Шулай итеп, рус егете Александр Ключарёв татар композиторы булып китә. Ул татар халык көйләренә эшкәртмәләр (импровизацияләр) иҗат итә, инструменталь музыка яза. Аның өлкәннәр һәм балалар өчен лирик җырлары, симфоник, опера һәм балет әсәрләре бар.

**хисапчы** — счетовод
**кадер** — здесь: цена
**моң** — мелодия, напев
**җыр көйләп йөри** — напевает песни
**язма** — здесь: музыкальные записи
**көч җитми** — не хватает сил
**гореф-гадәтләр** — обычаи, традиции

**9.** Тексттан тезмә һәм кушма җөмләләрне табыгыз.

**10.** План пунктларын текст эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз. Тексттан планга туры килгән өлешләрне табып, диалоглар төзегез, бер-берегез белән сөйләшегез.

1. Сашаның татар моңы белән танышуы.
2. Ключарёвлар гаиләсендәге традицияләр.
3. Александрның әти-әнисе.
4. Мәскәү консерваториясендә уку чоры.
5. А. Ключарёв иҗаты.

«Яз жыры», А. Ключарёв музыкасы

**11.** Тәрҗемә итегез.

1. Александр Ключарёв — видный представитель татарского музыкального искусства.
2. Он по национальности русский.
3. Александр начинает играть на гармони в пять лет.
4. Он написал лирические песни и для взрослых, и для детей.

**12.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. А. Ключарёв татар музыка сәнгатендә ... .
2. А. Ключарёв — рус ... .
3. А. Ключарёвның әтисе ... .
4. Сашаның гармунны күтәрергә ... .
5. Ключарёвларның күршеләрендә Гали исемле ... .
6. Саша күңелендә татар моңы кечкенәдән үк ... .
7. Мәскәү консерваториясендә ул Сара Садыйкова, Муса Җәлил, Заһид Хәбибуллин белән ... .

**13.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп языгыз, җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

1. Александр Ключарёвның әти... — сәүдә йорт... хисапчы, ә әнисе өй... балалар тәрбияли.
2. Аның гармун күтәрергә көче җитми, шуңа күрә ул гармун... урындык... куеп уйный.
3. Гимназия... укый башла..., скрипка..., пианино... уйнарга өйрән... .
4. А. Ключарёв татар халык көйләре... эшкәртә, лирик җыр... яза.
5. Рус егет... А. Ключарёв татар композитор... әйләнә.

**14.** Схема буенча диалог төзегез.

— сорау
— җавап
— гаҗәпләнү, өстәмә сорау
— аңлату
— сорау
— җавап, тәкъдим

Тема: А. Ключарёв иҗаты.

**15.** Сез бу җөмләне ничек аңлыйсыз? Фикерегезне текст эчтәлеге белән раслагыз.

Гаилә башлыгының балаларын зыялы итеп үстерәсе килә.

**16.** **Исегезгә төшерегез!**

**Сорау алмашлыклары**
Вопросительные местоимения

Вопросительные местоимения **«ни өчен?»**, **«нигә?»**, **«ник?»** все переводятся как вопрос «почему?».

С. Сәйдәшев ни өчен татар музыкасына нигез салучы булып санала?

— Нигә кичә килмәдең?
— Кичә эшем күп иде.
— Ник миңа хәбәр итмәдең?
— Телефоным эшләмәде.

**17.** Сорауларга җавап бирегез.

1. А. Ключарёвны ни өчен татар халкы аеруча хөрмәт итә?
2. Ул нинди әсәрләр иҗат итә?
3. Аның нинди мактаулы исемнәре бар?

**18.** Текст эчтәлеге буенча план төзегез. А. Ключарёв турында бер-берегезгә сөйләгез.

# 24–27 нче дәресләр

**1.** Сүзтезмәләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез.

Рәсем сәнгате, табигатьне күзәтү, беренче әсәрләре, тормыш мәктәбе, сугыш вакытында, атаклы картинасы.

**2.** Тәрҗемәне дәвам итегез.

халык рәссамы — народный художник
Казан сәнгать училищесы — ...
Бөек Ватан сугышы — ...
авыр тормыш мәктәбе — ...
графика өлкәсе — ...
китап графикасы — ...
татар халык иҗаты әсәрләре — ...

**3.** Бирелгән сүзләргә үрнәк буенча сыйфатлар өстәп языгыз.

Үрнәк: тормыш — авыр тормыш.

Күргәзмә, рәсем, сугыш, портрет, картина, рәссам, әсәр.

Сыйфатлар: атаклы, зур, яхшы, билгеле, дәһшәтле, матур, танылган.

**4.** Тәрҗемә итегез.

Известный художник Харис Якупов. Великий поэт Габдулла Тукай. Знаменитый композитор Салих Сайдашев.

**5.** Бирелгән саннарны сүзләр белән языгыз.

3, 58, 10, 50, 80, 800, 500, 1358, 10 358.

**6.** Танылган рәссам Харис Якупов турында укыгыз.



Харис Габдрахман улы Якупов 1919 нчы елда Казанда туа. Рәсем сәнгатенә гашыйк Харис тормышны, табигатьне күзәтә һәм үзенең беренче әсәрләрен иҗат итә башлый. Мәктәптә укыганда ук сынлы сәнгать студиясенә йөри, күргәзмәләрдә катнаша, рәсемнәрен газеталарда бастыра. Ул 1940 нчы елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый.

Бөек Ватан сугышы Харис Якупов өчен чыныгу һәм тормыш мәктәбе була. Әлбәттә, ул чорда рәсемнәрне дә күбрәк сугыш темасына ясый.

Харис Якупов — портрет һәм пейзажлар остасы. Ул — Габдулла Тукай, Шәриф Камал һәм башка күренекле шәхесләрнең портретларын яза. Аның «Иделдә эссе көн», «Кабан күле», «Хөкем алдыннан» дигән картиналары күпләргә таныш.

Харис Якупов китап графикасы өлкәсендә дә күп эшли. Ул Ш. Камал, М. Гафури, Л. Ихсановаларның әсәрләренә, татар халык иҗаты әсәрләренә иллюстрацияләр ясый.

Харис Якупов — СССРның халык рәссамы, РСФСРның И. Е. Репин һәм Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.

**хөкем алдыннан** — перед казнью
**гашыйк** — влюблённый

Харис Якупов, «Ана портреты»

**7.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табыгыз.

1. Харис Якуповның мәктәп еллары.
2. Харис Якупов Бөек Ватан сугышында катнашкан.
3. Харис Якупов иҗаты.
4. Харис Якуповның мактаулы исемнәре.

! **8. Исегездә калдырыгыз!**

**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре**
Однородные члены предложения

Җөмләдә сүзләр бер генә сүзгә ияреп килсә, бер үк сорауга җавап бирсә, алар **тиңдәш кисәкләр** (однородные члены) дип атала.

Тиңдәш кисәкләр **санау интонациясе** (интонацией перечисления) белән әйтелсә, алар арасында өтер (запятая) куела: Х. Якупов — портретлар, пейзажлар остасы.

Тиңдәш кисәкләр **каршы кую интонациясе** (интонация противопоставления) белән әйтелсә, сызык (тире) куела: М. Җәлил әсирлеккә эләгә — илен сатмый.

Тиңдәш кисәкләр шулай ук **теркәгечләр** (союзы) белән дә бәйләнергә мөмкин: Туристлар иң күп йөри торган урыннар булып Казан Кремле һәм Бауман урамы санала. Х. Якупов күргәзмәләрдә дә катнаша, рәсемнәрен газеталарда да бастыра.

**9.** Җөмләләрне текст эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Ул 1940 нчы елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый.

2. Харис Якупов — портрет һәм пейзажлар остасы.

3. Харис Якупов — СССРның халык рәссамы, РСФСРның — И. Е. Репин һәм Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.

4. Бөек Ватан сугышы Харис Якупов өчен чынығу һәм тормыш мәктәбе була.

5. Харис Якупов китап графикасы өлкәсендә дә күп эшли.

6. Харис Габдрахман улы Якупов 1919 нчы елда Казанда туа. Мәктәптә укыганда ук сынлы сәнгать студиясенә йөри, күргәзмәләрдә катнаша, рәсемнәрен газеталарда бастыра.

**10.** Нокталар урынына «ул» зат алмашлыгын тиешле килешләрдә куеп языгыз.

1. ... 1919 нчы елда Казанда туа.
2. ... рәсемнәрен газеталарда бастыра.
3. ... Казан сәнгать училищесына алалар.
4. Бөек Ватан сугышы ... өчен чынығу һәм тормыш мәктәбе була.
5. ... — портрет һәм пейзажлар остасы.
6. ... мактаулы исемнәр бирелә.

**11.** Харис Якупов турындагы тексттан тиңдәш кисәкле җөмләләрне аерып языгыз.

**12.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Харис Якупов мәктәптә укыганда ук күргәзмәләрдә катнаша, чөнки ... .

2. Ул рәсем сәнгатенә гашыйк була, шуңа күрә ... .

3. Бөек Ватан сугышы Харис Якупов өчен ... .

4. Харис Якупов — портрет һәм ... .

5. Харис Якупов китап графикасы өлкәсендә дә күп эшли, ул ... .

**13.** Җөмләләргә сораулар куегыз, җөмлә кисәкләрен атагыз.

1. Мәктәптә укыганда ук Харис Якупов сынлы сәнгать студиясенә йөри, күргәзмәләрдә катнаша, рәсемнәрен газеталарда бастыра. 2. Бөек Ватан сугышы Харис Якупов өчен чынығу һәм тормыш мәктәбе була, ул чорда рәсемнәрне дә күбрәк сугыш темасына ясый.

**14.** Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасын карагыз. Сорауларга җавап бирегез.



1. Картинада нинди вакыйга чагылыш тапкан?
2. Картинада алгы планда кем сурәтләнгән?
3. Автор Муса Җәлилнең кыюлыгын ничек күрсәтеп биргән?

**15.** Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча кечкенә инша языгыз.

**16.** 6 нчы күнегүдәге текстның 1 нче абзацыннан тиңдәш кисәкле җөмләләрне табыгыз. Нинди җөмлә кисәкләре тиңдәшләнеп килә?

**17.** Схема буенча диалог төзегез.

— сорау
— җавап
— гаҗәпләнү
— сорау
— җавап

Тема: Х. Якупов иҗаты.

**18.** Пригласите друга:

— на встречу с известным художником;
— на выставку картин;
— на юбилейный вечер знаменитого художника.

# 28–30 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә **тезмә кушма җөмлә** дип атала. Тезмә кушма җөмләләрне **теркәгечле** һәм **теркәгечсез** җөмләләргә бүләләр.

Тезмә кушма җөмләләр тезүле теркәгечләр ярдәмендә бәйләнәләр.

Мәсәлән:

1. (1) Антракт тәмамлланде, һәм (2) без урыннарга кереп утырдык.

[1], һәм [2]

2. (1) Көчле музыка яңгырады да, (2) тамаша башланды.

[1] да, [2]

3. (1) София Гобәйдуллина камера музыкасы остасы булып танылa, (2) ә тамашачылар аны кинофильмнарга музыка язган композитор буларак та беләләр.

[1], ә [2]

4. (1) София Гобәйдуллина Татарстанда белем ала, (2) ләкин ул танылган әсәрләрен чит илдә иҗат итә.

[1], ләкин [2]

5. (1) София Гобәйдуллина Татарстанда белем ала, (2) әмма ул атаклы композитор буларак чит илдә танылa.

[1], әмма [2]

6. (1) Без бүген я театрга барабыз, (2) я сыйныф җитәкчесе безне концертка алып бара.

я [1], я [2]

7. (1) Мин кирәкле материалларны Интернеттан эзлим, (2) яисә әнием китапханәдән китап алып кайта.

[1], яисә [2]

Тезмә кушма җөмләләр **санау** (тезү) һәм **каршы кую** интонациясе аша да бәйләнеп киләләр. Антоним сүзләр каршы кую интонациясен барлыкка китерәләр.

М ә с ә л ә н:

Тизү интонациясе

1. (1) Кыңгырау шалтырады, (2) тамаша башланды.

Каршы кую интонациясе

2. (1) Эшләгән мул булган, (2) эшләмәгән хур булган.

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез, тезмә кушма җөмләләр төзегез.

1. Мин талантлы музыкантлар белән аралаштым, … . 2. Кечкенәдән үк Салих Сәйдәшевнең моңнарын тыңлап үстем, … . 3. Зур музыкант булса да, … . 4. Талантлы композитор симфоник әсәрләр иҗат итә, … . 5. 70 нче елларга ул камера музыкасы остасы булып таныла, … .

**3.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

Әгъза, халык, нәсел, сәнгать, тәхет, белемле, талантлы, җитәкче, тыйнак, остаз, аралаштым, ирештем, гаеплиләр, сынау, сынмый, гаҗәп.

**4.** **Исегездә калдырыгыз!**

**таң калдыру** — изумлять

**5.** Исемнәрдән сыйфатлар ясагыз, алар белән җөмләләр төзегез.

Талант, кешелек, бәхет, белем, сәләт, зат, моң.

**6.** Сүзләрнең логик парларын табыгыз.

| | ? | |
|---|---|---|
| чит | | композитор |
| атаклы | | шары |
| таң | | кеше |
| Җир | | музыкасы |
| симфоник | | ил |
| иҗат | | әсәр |
| тыйнак | | кала |
| камера | | шәхес |
| талантлы | | кешесе |

**7.** Текстны укыгыз. София Гобәйдуллина турында сездә нинди фикерләр туды?

## Якташыбыз София Гобәйдуллина



Россиядән Швеция Короле сәнгать академиясе әгъзасы булган ике генә кеше бар: Пётр Чайковский һәм София Гобәйдуллина.

Үзенең зур уңышларын София бик тыйнак кына аңлата: «Остазларым нинди иде бит! — ди ул. — Кечкенәдән үк Салих Сәйдәшевнең моңнарын тыңлап үстем, Нәҗип Гаязович Җиһановтан композиция дәресләре алдым. 23 яшемдә Казан консерваториясен тәмамладым һәм Мәскәү консерваториясендә, аспирантурада белемемне күтәрдем. Талантлы композиторлар, музыкантлар белән аралаштым... Иоганн Себастьян Бах музыкасын, Шостакович симфонияләрен тыңлау бәхетенә ирештем...»

София Гобәйдуллинаның әсәрләре 50 нче еллар ахырында ук чит илләрдә, шулай ук Германиядә дә инде билгеле була. 70 нче елларга ул камера музыкасы остасы булып танылa. София Гобәйдуллинаны тамашачылар кинофильмнарга музыка язган композитор буларак та беләләр. «Маугли», «Балаган», «Чучело», «Вертикаль» фильмнарына музыканы ул иҗат иткән. Шул ук вакытта ул симфоник оркестр өчен әсәрләр иҗат итә. Атаклы скрипкачы Кремер София Гобәйдуллинаның әсәрләре белән бөтен Җир шарын әйләнә. Нью-Йорк, Бостон, Париж, Берлин, Франкфурт-на-Майне, Мюнхен, Лондон, Варшава тамашачыларын таң калдыра. Аның музыкасын һәр җирдә аягүрә басып сәламлиләр.



София Гобәйдуллина 2025 нче елда вафат булды.

Вакытлы матбугаттан

**тыйнак** — скромный
**аягүрә** — стоя
**остаз** — наставник
**әгъза** — член
**билгеле була** — было известно

**8.** Тексттан тезмә кушма җөмләләрне табыгыз.

**9.** Бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне хикәядән табып укыгыз.

1. София Гобәйдуллинаның музыка өлкәсендә дөньякүләм уңышлары.
2. Талантлы композиторның остазлары.

**10.** Планга нинди пунктлар өстәр идегез?

1. София Гобәйдуллинаның остазлары.
2. Аның белем алуы.
3. София Гобәйдуллина — дөньякүләм танылган композитор.
4. ...

**11.** Нокталар урынына төшеп калган репликаларны өстәгез, диалог буенча сөйләшергә өйрәнегез.

— ... ?
— София Гобәйдуллина Татарстанда туган.
— Ә кайда укыган? — ... .

**12.** Сорауларга җавап бирегез.

1. София Гобәйдуллина нинди юнәлештә иҗат итә?
2. Аның әсәрләре кайсы илләрдә яңгырый?
3. София үзенең остазлары дип кемнәрне саный?
4. София Гобәйдуллинаның дөньякүләм танылган талантын раслаучы нинди фактлар әйтә аласыз?

**13.** Җөмләне тәгалләгез. Сезнең бу фильмнарны караганыгыз бармы?

София Гобәйдуллина «Маугли», «Балаган», «Чучело», «Вертикаль» ... .

## 31–33 нче дәресләр

**1.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы? Дәфтәрегезгә транскрипция билгеләре белән языгыз, тәрҗемәләрен табыгыз.

Мәдәни, дәртле, моңлы, нурлы, сәнгать, үзәк, гасыр, тамашачы, тамаша, оештыручы, талантлы.

**2.** Сүзләрнең логик парларын табыгыз.

1) ?

| | |
|---|---|
| тамаша | итеЛә |
| игълан | килә |
| исемен | итә |
| барлыкка | йөртә |
| дәвам | күрсәтә |

2) мәдәни, моңлы, тәҗрибәле, талантлы, яшь — ? — тамашачы, шәхес, артист, үзәк, көй

3) баш, театр, опера, яшьләр, шәһәр, татар — ? — сәнгате, теле, халкы, режиссёр, театры, артисты

**3.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп, җөмләләрне тәгәлләгез. Җөмләләргә сораулар куегыз.

1. Мин театр... хөрмәт итәм. 2. Син театр... барасыңмы? 3. Алар яңа гына театр... кайттылар. 4. Театр... бик яхшы спектакль бара. 5. Мин театр... бик еш йөрим. 6. Бу театр... исемен беләсеңме?

**4.** Тәрҗемә итегез.

1) опера һәм балет театры — ...

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры — ...

2) драма һәм комедия театры — ...

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры — ...

3) татарский театр — ...

Татарский государственный Академический театр — ...

Татарский государственный Академический театр имени Галиасгара Камала — ...

4) русский театр — ...

Большой русский драматический театр — ...

Большой русский драматический театр имени Василия Качалова — ...

**5.** Текстны укыгыз.

## Татар театры

Казан — мәдәни үзәк. Габдулла Тукай әйткәнчә, Казан дәртле дә, моңлы да, нурлы да.

Казанда җиде профессиональ театр эшли: М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт Академия опера һәм балет театры, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, В. Качалов исемендәге Казан рус зур академия драма театры, Казан дәүләт яшь тамашачы театры, Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры, Татар дәүләт «Әкият» курчак театры. Театрларга шәһәр халкы гына түгел, башка төбәкләрдән дә тамашачылар бик теләп килә.



Татар театр сәнгате XX гасыр башында барлыкка килә. 1906 нчы елның 22 нче декабре — татар театры туган көн. Ул көнне Казанда беренче мәртәбә рәсми рәвештә татарча театр күрсәтелә. Бу тамашаны оештыручыларның берсе атаклы татар драматургы Галиәсгар Камал була. Аны хаклы рәвештә татарның Островские дип йөртәләр. Ул — беренче татар тамашаларын оештыручы гына түгел, аларны язучы һәм уйнаучы да. Бүген халык яратып йөри торган иң зур театр Галиәсгар Камал исемен йөртә.



Марсель Сәлимҗанов

Театрның горурлыгы — аның артистлары: Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Гөлсем Исәнгулова, Наил Дунаев, Алсу Гайнуллина, Илдар Хәйруллин, Илсөя Төхфәтуллина, Искәндәр Хәйруллин, Илдус Габдрахманов, Люция Хәмитова һәм башкалар.

Озак еллар буе театрның баш режиссёры булып профессор, Татарстанның Г. Тукай һәм Россиянең К. Станиславский исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Марсель Сәлимҗанов эшләде. Бүген аның эшен Фәрит Бикчәнтәев дәвам итә.

**рәсми** — официально
**тамаша** — представление
**хаклы рәвештә** — по праву

**6.** Җөмләләрне текстта бирелгән тәртиптә урнаштырыгыз.

1. Аны татарның Островские дип йөртәләр.
2. Театр Галиәсгар Камал исемен йөртә.
3. 1906 нчы елның 22 нче декабре — татар театры туган көн.



Г. Камал театры артистлары белән танышыгыз

**7.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Казанда нинди театрлар бар?
2. Татар театрына кайчан нигез салына?
3. Татар дәүләт Академия театры ни өчен Галиәсгар Камал исемен йөртә?
4. Нинди татар спектакльләрен беләсез?

**8.** Диалогны укыгыз, сөйләшергә өйрәнегез.

— Алсу, әйдә иртәгә театрга барабыз.
— Ә нинди театрга?
— Минем Камал театрына да, Тинчурин театрына да барасым килә. Ә синең?
— Галиәсгар Камал театрында нинди спектакль бара икән?
— Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы.
— Минем аны караганым бар.
— Ошадымы?
— Искиткеч. Ләкин бүген башка спектакльгә барыйк.
— Мин риза.

**9.** Составьте предложения по следующим ситуациям:

1. Вы хотели пригласить друга в Татарский государственный Академический театр имени Галиасгара Камала. Убедите его посмотреть спектакль «Первое представление» («Беренче театр»).

2. Позвоните в кассу театра и спросите:
— какое представление идёт в театре;
— во сколько начинается представление;
— есть ли билеты;
— сколько стоят билеты.

3. Попросите оставить вам билеты, сообщите, сколько вас человек и когда вы пойдёте.

**10.** «Театр кассасында» темасына түбәндәге схема буенча диалог языгыз.

— вопрос
— встречный вопрос
— ответ
— согласие

**11.** «Татар театрының үткәне, бүгенгесе» темасы буенча төркемнәрдә сөйләшегез.

**12.** Текстны укыгыз.

## Күренекле драматург



Татар театры тарихында тирән эз калдырган атаклы шәхесләр бар. Алар арасында үзенең иҗтимагый һәм әхлакый проблемаларга бай булган драматургиясе белән Туфан Миңнуллин аерым урын алып тора.

Туфан Миңнуллин пьесалары илебез сәхнәләрендә иң күп уйнала. Ул иҗат иткән «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Әниләр һәм бәбиләр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Мулла» һәм башка әсәрләрне тамашачылар бик яратып карыйлар.





«Әлдермештән Әлмәндәр»

**13.** Күренекле драматург Туфан Миңнуллин турында материаллар туплагыз, чыгышка әзерләнегез.

**14.** **Исегездә калдырыгыз!**

**3 нче зат берлек һәм күплек сандагы боерык фигыльләрнең барлык-юклык формасы**

Глаголы повелительного наклонения 3-го лица единственного и множественного числа в утвердительной и отрицательной форме

| **Фигыльләр** | **Берлек санда** | | **Күплек санда** | |
|---|---|---|---|---|
| | **барлыкта** | **юклыкта** | **барлыкта** | **юклыкта** |
| бар | бар-сы́н | ба́р-**ма**-сын | бар-сын-на́р | ба́р-**ма**-сын-нар |
| кил | кил-се́н | ки́л-**мә**-сен | кил-сен-нә́р | ки́л-**мә**-сен-нәр |
| … | … | … | … | … |

**15.** Тәрҗемә итегез:

— пусть он сходит на просмотр фильма;
— пусть они пойдут смотреть спектакль «Сүнгән йолдызлар»;
— пусть они не разговаривают во время просмотра кинофильма;
— пусть дети купят билет по Пушкинской карте;
— пусть родители придут на постановку спектакля «Әниләр һәм бәбиләр».

## 34–35 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Сложноподчинённое предложение**
Иярченле кушма җөмлә

Сложноподчинённое предложение **(иярченле кушма җөмлә)** — это вид сложного **(кушма)** предложения, в составе которого одно простое предложение **(гади җөмлә)** по смыслу и интонации подчинено другому. Зависимое предложение называют придаточным **(иярчен җөмлә)**, независимое — главным **(баш җөмлә)**.

Части сложноподчинённого предложения связываются союзами **(чөнки, әгәр, ягъни, гүя)**; относительными словами **(шул, шуңа күрә, алайса, шуңа карамастан)**; аффиксами в составе сказуемого **(-гач/-гәч, -кач/-кәч, -ганчы/-гәнче)**.

Барысы да тынып калдылар, чөнки кыз җырлый башлады.
Кыз җырлый башлагач, барысы да тынып калдылар.

**2.** Җөмләләрне укыгыз, тәрҗемә итегез. Аларда гади җөмләләр нинди чаралар ярдәмендә бәйләнгән?

1. Яңгыр явып торды, шуңа карамастан укучылар барысы да концертка ашыкты.
2. Алар бик шатландылар, чөнки яраткан театр артистлары уйнаячак.
3. Укучылар беләләр: уку үзең өчен кирәк.

**3.** Җөмләләрне дәвам итегез, тезмә һәм иярченле кушма җөмләләр төзегез.

1. Кемдер эстрада җырларын ярата, мин … .

2. Яшь җырчылар күп булса да, ... .

3. Шәһәргә танылган төркем килсә, ... .

4. Мин ... җырлавын яратам, ә ... .

5. Миңа җырчы ... ошый, ләкин ... .

**4.** Диалогны укыгыз, партадашыгыз белән сөйләшергә өйрәнегез.

— Алсу, әйдә концертка барыйк әле. Җыр тыңлыйсым килә.

— Минем дә күптән концертка барасым килә.

— Нинди концертка барабыз?

— «Җиде йолдыз»ның финал концерты була. Бәлки, без шул концертка барырбыз?

— Кайда була?

— «Пирамида»да.

— Ә кемнәр катнаша икән?

— Айдар Галимов, Фирдүс Тямаев, Илназ Бах, Ләйсән Гимаева, Гүзәл Уразова, Фәрит Таишев, ләкин Салават Фәтхетдинов катнашмый икән.



— Димәк, «Пирамида»га барабыз.

— Әйе, мин шулай уйлыйм.

— Ничәдә очрашабыз?

— Җиденче яртыда.

**5.** Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзегез.

Музыка сәнгате, музыкаль сәлам, музыка уен коралы, музыка мәктәбе, музыка язу, музыка тыңлау.

**6.** Тәрҗемә итегез.

1. Одни любят классическую музыку, другие предпочитают народные мелодии.

2. Молодёжь интересуется джазовой музыкой.

7. Бирелгән сүзләрдән яңа сүзләр ясагыз, җөмләләр төзегез.

Скрипка, курай, гармун, баян, җыр, бию.

8. Нокталар урынына төшеп калган репликаларны өстәп, диалоглар языгыз, дусларыгыз белән сөйләшеп карагыз.

— Син нинди музыка коралларын беләсең?
— ... .
— ... ?
— Юк, мин гармунда уйный белмим, ләкин уйнаганны тыңларга яратам.
— Ә син нинди атаклы гармунчы, баянчыларны беләсең?
— ... .

9. Спросите у друга:

— какую музыку он любит слушать;
— какую музыку любят его родители;
— любит ли он сам петь песни;
— играет ли он на каком-нибудь музыкальном инструменте;
— каких татарских певцов и какие музыкальные группы он знает.

10. Расскажите друг другу о том:

— какая музыкальная группа вам нравится;
— какую музыку вы обычно слушаете.

## 36–39 нчы дәресләр

1. Убедите друга сходить на концерт и познакомиться с популярными татарскими певцами.

2. Скажите другу о том, что:

— классическая музыка успокаивает нервную систему;
— от громкой музыки быстро устаёт голова.

**3.** Сез сәнгать кешеләрен беләсезме? Аларның исем һәм фамилияләрен таблицага урнаштырыгыз.

| Композиторлар | Җырчылар | Рәссамнар | Артистлар |
|---|---|---|---|
| ... | ... | ... | ... |


Луиза Батыр-Болгари


Рөстәм Яхин


Мансур Мозаффаров


Илһам Шакиров


Вера Минкина


Шәүкәт Биктимеров


Бакый Урманче


Хәйдәр Бигичев


Резеда Ахиярова


Эрот Зарипов


Әлфия Авзалова


Нәҗип Җиһанов


Зилә Сөнгатуллина


Илдар Зарипов


Люция Хәмитова


Салават Фәтхетдинов


Нәҗибә Ихсанова


Равил Шәрәфиев

**4.** Посоветуйте другу:

— сходить на концерт Салавата Фатхетдинова;

— посетить выставку картин художников нашей республики;

— сходить в библиотеку и взять сборник стихов Роберта Миннуллина;

— посетить музей Габдуллы Тукая;

— послушать музыку Сары Садыковой;

— сходить в театр имени Мусы Джалиля;

— посмотреть балет «Ромео и Джульетта».

**5.** Әйтик, сезнең мәктәптә күренекле җырчы Филүс Каһиров белән очрашу булачак, ди. Шул очрашу кичәсенең афишасын ясагыз.

**6.** Текстны укыгыз. Эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

### Бриллиантка тиң яңа театр бинасы



Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасы Казанның Һади Такташ урамында, Кабан күле буенда урнашкан. Бинаның 1500 тамашачы сыйдырышлы дүрт залы бар. Бриллиантка тиң яңа театр бинасын ачу тантанасы 2025 нче елда узды.

**Фойега** аяк басуга, аның искиткеч бизәлешенә игътибар итәсең. Татарстанның халык рәссамы, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Наилә Кумысникова, залны бизәгәндә, хатын-кызларның бизәнү әйберләре, Кабан күле турындагы легендалар белән илһамланып, милли орнаментлар тудырган. Махсус яктырткычлар әлеге рәсемнәрнең тәэсир көчен тагын да баета.

**Көнчыгыш зал** уртасында — түгәрәк сәхнә. Зур тәрәзәләрдән Кабан күле, шәһәр манзарасы күренә. Әлеге зал 242 урынга исәпләнгән.

**Универсаль залда** телешоулар, төрле чаралар уздырырга, видеороликлар, хәтта кино төшерергә мөмкинлекләр тудырылган.

**Төп зал** 766 тамашачыга исәпләнгән, ике балкон, өч дәрәҗәдәге фойедан торган тантаналы үзәк зал.

Татарстанда гына түгел, илебездә тиңе булмаган бу затлы бина ерактан ук балкып, үзенә тартып тора.

**7.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез.

— Казанда иң танылган татар театры Галиәсгар Камал исемен йөртә. Ә син Галиәсгар Камал турында беләсеңме?

— ... .

— Галиәсгар Камал театры яңа бинага күчте. Синең анда булганың бармы?

— ... .

— Без сыйныф укучылары белән анда барырга җыенабыз.

**8.** Диалог эчтәлеге буенча сөйләшергә өйрәнегез.

— Диана, сиңа Равил Шәрәфиевнең уйнавы ошыймы?
— Ул искиткеч артист. Ул миңа бик ошый.
— Ул сиңа ни өчен ошый?
— Ул шаян, үзе юмор остасы.

— Ә миңа Нәҗибә Ихсанова уйнавы бик ошый иде. Ул — сәләтле, оста артист.

— Мин дә аның иҗатын бик ярата идем.

— Ә сиңа яшь артистлардан кемнәр ошый?

— Эмиль Талипов, Гөлчәчәк Гайфетдинованың уйнавын яратам.

**9.** Татарстанда чыга торган газета-журнал исемнәрен исегездә калдырыгыз. Сез аларның кайсылары белән таныш?

«Ялкын», «Чаян», «Шәһри Казан», «Казан утлары», «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Сабантуй», «Татарстан», «Казан», «Мәйдан», «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп», «Идел», «Ирек мәйданы», «Көмеш кыңгырау».




**10.** Диалогны дәвам итегез, сөйләшергә өйрәнегез.

— Наил, сез быел газета-журналлар аласызмы?

— Быел бик аз язылдык. Ләкин «Казан утлары», «Ялкын» журналларын ел саен алабыз. Ә сез?

— Без күбрәк газеталар алабыз. «Аргументы и факты», «ЗОЖ».

— Ә татарча газеталар аласызмы соң?

— Әйе, минем әтием Владислав татарча яхшы белә. Ул ел саен «Ватаным Татарстан» газетасын ала.

— Ә син татарча газеталар укыйсыңмы?

— … .

## 40–42 нче дәресләр

**1.** **Исегезгә төшерегез!**

**-лык/-лек, -чы/-че, -таш/-тәш, -даш/-дәш** кушымчалары — исем ясагыч кушымчалар. Бу кушымчалар ярдәмендә яңа мәгънәле сүзләр ясала: юл+чы, тәрбия+че.

Чагыштырыгыз: юл — дорога, юлчы — путник; тәрбия — воспитание, тәрбияче — воспитатель.

**2.** Бирелгән сүзләрдән һөнәр исемнәрен ясагыз.

Юл, урман, трактор, нефть, тәрбия, тарих, эш, тел.

**3.** Скажите, что:

— он не судья, а прокурор;
— он не врач, а медсестра;
— он не воспитатель, а учитель;
— он не лётчик, а инженер;
— он не слесарь, а сантехник.

**4.** Җөмләләрне укыгыз, исемнәрне табыгыз. Алар нинди ысул белән ясалган?

1. Каюм Насыйри — тарихчы, тәрҗемәче, телче, зур галим.
2. Укытучы һөнәре — һәрвакыт мактаулы һөнәр.
3. Алексей Мересьев атаклы очучы булган.
4. Бүген сатучы һөнәренә таләпләр зур.

**5.** Сорауларга җавап бирегез.

| | | |
|---|---|---|
| Игеннәрне кем үстерә? | ? | балыкчы |
| Бакчаларда җиләк-җимешне кем үстерә? | | укытучы |
| Балаларны кем укыта? | | эшче |
| Заводта кем эшли? | | игенче |
| Диңгездә, елгада балыкны кем тота? | | бакчачы |

**6. Исегезгә төшерегез!**

Если вы хотите сказать о том, кто кем работает, то нужно использовать послеложное слово (бәйлек сүз) «булып», например:

Әни укытучы **булып** эшли. — Мама работает учительницей.

Әти электрик **булып** эшли. — Папа работает электриком.

**7.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез, дәфтәрегезгә языгыз.

1. Папа работает инженером.
2. Дедушка работает журналистом.
3. Сестра работает продавцом.

**8.** Диалогка җавап репликаларын өстәп, дәфтәрегезгә языгыз.

— Олег, синең әтиең кем булып эшли?
— ... .
— Ә ул кайда эшли?
— ... .

**9.** Как скажете о том, что:

— ваш брат работает юристом (врачом, нефтяником);
— ваша сестра работает учителем (швеёй, продавцом);
— ваша мама работает поваром (парикмахером, воспитателем);
— ваш папа работает строителем (руководителем, электриком)?

**10.** Диалогларга җавап репликаларын өстәгез, үзара сөйләшегез.

1. — Алсу, синең әниең кем булып эшли?
— ... .
— Син әниеңә булышасыңмы?
— ... .
— Ничек булышасың?
— ... .

2. — Костя, беләсеңме, минем һәм синең әтиең бер заводта эшлиләр?
— Әйе, беләм. Безнең әниләр дә таныш.
— Ә синең әниең кайда эшли?
— ... .

3. — Коля, синең әтиең инженер булып эшлиме?
— ... . ... ?
— Әйе, минем әтием төзүче булып эшли. Ә әни кибеттә сатучы булып эшли.

**11.** Ике гади җөмләдән кушма җөмләләр төзегез.

1. Мин юрист һөнәрен сайлыйм. Минем абыем да юрист булып эшли.
2. Нинди һөнәр сайларга белмим. Бик күп яңа һөнәрләр барлыкка килде.
3. Миңа банкта эшләү ошый. Математиканы начар беләм.
4. Һөнәрләр бик күп. Кеше үзенә ошаган һөнәрне сайларга тиеш.

**12.** Диалогларны дәвам итегез.

1\. — Айдар, 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, син кая барасың?
— Мин уйлыйм әле, Саша.
— Әйдә бергә техникумга укырга керәбез.
— Нинди техникумга?
— Автомеханика техникумына.
— Анда нинди белгечлекләр бар?
— ... .

2\. — Надя, синең әниең кайда эшли?
— Вертолёт заводында.
— Ә кем булып эшли?
— Баш бухгалтер булып.
— Әтиең дә шул заводта эшлиме?
— Юк, ул — очучы. Казан — Мәскәү юнәлешендә оча.
— Ә сиңа нинди һөнәр ошый?
— ... .

**13. Исегезгә төшерегез!**

Глаголы желания (теләк фигыль) указывают на желательное или нежелательное отношение говорящего к выполнению действий. Они бывают только в 1 лице единственного или множественного числа. Глаголы желания могут иметь положительную и отрицательную форму: *барыйм әле* — *бармыйм әле* (ед. число), *барыйк әле* — *бармыйк әле* (мн. число).

Глаголы желания могут быть выражены конструкцией *буласым килә* — *буласым килми.*

Например: Минем программист буласым килә.
Безнең пешекче буласыбыз килми.

**14.** Скажите другу, что:

— хотите работать библиотекарем, потому что вы любите книги;

— вам нравится профессия электрика, так как она почётная;

— пойдёте учиться на агронома, потому что эта профессия престижная.

## 43–44 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемәне истә калдырыгыз.

**Кирәкле һөнәр** — нужная профессия; **эшче** — рабочий; **эшче һөнәрләре** — рабочие профессии; **пешекче** — повар; **сатучы** — продавец; **тегүче** — швея; **төзүче** — строитель; **очучы** — лётчик; **машина йөртүче** — водитель; **яхшы белгеч** — хороший специалист; **инженер булып эшли** — работает инженером; **заводта эшли** — работает на заводе; **һөнәр сайлау** — выбор профессии; **9 нчы сыйныфтан соң** — после 9-го класса; **колледжга укырга керү** — поступление в колледж; **укуны дәвам итү** — продолжать учёбу.

**2.** «Ялкын» журналына Ләйлә исемле кыз язган хат белән танышыгыз. Сез аның белән килешәсезме? Төркемнәрдә фикерләшегез.

Җир йөзендә нинди генә һөнәрләр юк: укытучы, табиб, эшче, сатучы, официант, юрист, бухгалтер, очучы һәм башкалар. Хәзер яңа һөнәрләр барлыкка килде: брокер, эшмәкәр, банкир, секретарь-референт, менеджер...







Һөнәр сайлау — бик җаваплы эш, шуңа күрә мин бу турыда күп уйлыйм. Минем әти-әниләрнең дә һөнәре начар түгел. Әнием балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Ул балаларны ярата. Аңа эше бик ошый. Әтием — инженер. Ул Кама политехника институтын тәмамлаган. Хәзер ул «КАМАЗ»да эшли. Ул үз эшен ярата.

Һөнәрләрнең барысы да яхшы. Ләкин һәр кеше үзе яраткан һөнәрне сайлый.

3. Ләйлә нинди яңа һөнәрләр турында әйтә? Төркемнәрдә аңлатмалы сүзлекләр белән эшләгез, Интернет челтәреннән материал табып, бу һөнәрләр турында сөйләргә әзерләнегез.

4. Ләйләнең хатыннан «Һөнәрләрнең барысы да яхшы. Ләкин һәр кеше үзе яраткан һөнәрне сайлый» дигән җөмләләрне ничек аңлыйсыз? Төркемнәргә бүленеп, үзара сөйләшегез.

5. Диалогларга тиешле репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез.

1. — Миңа табиб һөнәре ошый. Ә сиңа нинди һөнәрләр ошый?
— ... .
— Ни өчен?
— ... .
— Син нинди һөнәр сайлар идең?
— ... .
— Ул һөнәрне алу өчен кайсы уку йортында укырга кирәк?
— ... .
— Бу уку йорты кайсы шәһәрдә урнашкан?
— ... .

2. — Миңа пешекче һөнәре ошый.
— Ә сиңа ни өчен бу һөнәр ошый?
— ... .
— Син шулай дип уйлыйсыңмы?
— ..., чөнки ... .
— Чыннан да, бу яхшы һөнәр, минем дә пешекче буласым килә.
— Ни өчен?
— ... .

3. — Син нинди һөнәр сайлар идең?
— ... . Ә син?
— Мин очучы булыр идем.
— Ул һөнәр нигә ошый?
— ... .

— Синеңчә, тагын нинди һөнәрләр мактаулы?
— ... .

4. — Синең апаң, абыең бармы?
— Әйе, апам бар, абыем юк, ә энем бар.
— Апаң ничә яшьтә?
— ... .
— Ул кайда яши, кайда эшли?
— Апам Түбән Кама шәһәрендә яши. Түбән Камада зур кибеттә сатучы булып эшли.

**6.** Интернет челтәре аша үзегез яши торган урында нинди урта махсус белем бирү уку йортлары (среднеспециальные учебные заведения) барлыгы турында мәгълүмат туплагыз. Анда нинди белгечлекләр әзерләнә? Дәфтәрегезгә языгыз.

**7.** Яраткан һөнәрегез турында сөйләргә өйрәнегез.

**8.** Тәрҗемә итегез.

В Татарстане востребованными профессиями оказались слесари, фрезеровщики на станках с числовым программным управлением (ЧПУ), парикмахеры, повара и кондитеры, медработники со специальностью «лечебное дело», специалисты по разработке и эксплуатации нефтяных и газовых месторождений.

**9.** Тәрҗемә итегез.

Татарстан — көчле фән һәм мәгариф потенциалы булган төбәк. Мәгариф өлкәсендә 170 000 кеше хезмәт итә. Урта белем алу мәҗбүри һәм бушлай. Гомумән, Татарстанда 2434 белем бирү учреждениесе бар, якынча 600 000 укучы белем ала.

Иң популяр уку йортлары:

- Казан (Идел буе) федераль университеты;
- А. Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты (КАИ);
- Казан илкүләм тикшеренү технология университеты (КХТИ);
- Казан дәүләт медицина университеты;
- Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты;
- Казан дәүләт аграр университеты;
- Казан дәүләт мәдәният институты;
- Казан дәүләт энергетика университеты.

## 45–46 нчы дәресләр

1. **Исегезгә төшерегез!**

**Исем фигыль**
Имя действия

Имя действия — это часть речи, которая одновременно обладает признаками и глагола (обозначает процесс или действие, имеет отрицательную форму), и имени существительного (склоняется по числам, падежам и принадлежности). Отвечает на вопрос **«нишләү?»** и образуется от основы глагола при помощи аффикса **-у/-ү**: кай**ту** (возвращение), кит**ү** (уход). Например: Һөнәр сайлау — җаваплы эш. Дөрес тукланмау организмга зыян китерә.

2. Бирелгән фигыльләрне исем фигыль формасына куегыз һәм тәрҗемә итегез.

Сайлый, эшли, бара, уйлый, шатлык китерә, ошый, булдыра алам, җавап бирә, арый.

3. Җөмләләрне укыгыз, тәрҗемә итегез, сыйфат фигыльләрне билгеләгез.

1. Институт тәмамлаган яшьләр үз һөнәре буенча эшләми. 2. Мәктәпне тәмамлаганда, яраткан һөнәрең турында уйлау кирәк. 3. Яратмаган һөнәр — гомерең буена озата барачак канәгатьсезлек хисе. 4. Сайлаячак һөнәре турында кешегә барысын да белү мөһим.

4. Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез.

Һөнәр, яшьләр, сайлый, килешә, теләгән, уңышлы, шатлык, ошый, уйлый, эшмәкәр.

5. Текстны укыгыз, төркемнәрдә һөнәр сайлау турында сөйләшегез.

### Һөнәр сайлау — җаваплы эш

Республиканың яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча элеккеге министры Марат Бариев болай дигән иде: «Яшьләр бит һөнәр сайламый, ә уку йортын сайлый. Техникум, лицей, вуз бетергән күп кенә яшьләр үз һөнәрләре буенча эшләми. Безгә шулкадәр юрист, психолог, икътисадчы кирәк түгел, инженерлар, технологлар, төзүчеләр, токарьлар кирәк. Шуңа күрә мәктәпне бетергәндә, укырга кая барасыңны түгел, ә яраткан һөнәрең турында уйларга кирәктер».

Бу фикер белән килешәсезме?

Чыннан да, һөнәр сайлау — киләчәгеңне планлаштыру дигән сүз. Күңелеңә ятмаган һөнәр — гомереңбуена озата барачак канәгатьсезлек хисе, тиз ару, эшеңнән шатлык тапмау инде ул.

Иң элек үзеңә нинди һөнәр кирәклеген ачыкла.

Түбәндәге өч сорауга җавап эзлә:

— Миңа нинди һөнәр ошый? Мин нәрсә эшләргә яратам?

— Булдыра аламмы?

— Ул һөнәргә ихтыяҗ бармы?

Әгәр шушы өч сорауга төгәл җавап бирәсең икән, сайлаган һөнәрең уңышлы булачак дигән сүз.



**киләчәк** — будущее
**ихтыяҗ** — потребность
**канәгатьсезлек** — недовольство
**төгәл** — точно

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Яшьләр һөнәр сайламый, … .
2. Техникум, югары уку йортын бетергәч, … .
3. Мәктәпне бетергәндә, … .
4. Һөнәр сайлау — … .
5. Өч сорауга җавап бирсәң, … .

**7.** Спросите у друга о том:

— готов ли он к выбору профессии;
— что он знает о своей будущей профессии;
— где он хочет обучаться выбранной профессии;
— чего он ждёт от своей профессии;
— как он готовится к выбору профессии.

**8.** Диалогларга тиешле репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез.

1. — Коля, синең абыең кайда эшли?
— Ул заводта токарь булып эшли.
— Ул 11 нче сыйныфны тәмамладымы?
— Юк, … .
— Кайсы уку йортын тәмамлады?
— … .
— Анда уку авырмы?
— … .

2. — Оля, син ничек уйлыйсың, хәзер нинди һөнәрләргә ихтыяҗ зур?

— Бүген эшче һөнәрләренә ихтыяҗ зур.

— Әйе шул, бар кеше дә юрист яки икътисадчы булса, йортларны кем салыр, ипине кем пешерер?

— Мин дә шулай уйлыйм, ... .

— Мин техникумга укырга керәм. Ә син?

— ... .

— ... ?

— ... .

**9.** Посоветуйте другу узнать:

— побольше о выбранной профессии;
— востребована ли выбранная им профессия;
— где можно получить образование по данной профессии.

**10.** **Исегездә калдырыгыз!**

Чтобы сказать, что вы хотите стать кем-то, употребите следующие конструкции:

— **«название профессии + булырга телим».**

Например: Мин спортчы булырга телим. Мин шахматчы булырга телим.

— **«минем + название профессии + буласым килә».**

Например: Минем спортчы буласым килә. Минем шахматчы буласым килә.

**11.** Текстта бирелгән өч сорауга җавап языгыз, бер-берегезгә сөйләп карагыз.

## 47–48 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Кайсы һөнәрләргә ихтыяҗ зур?



Ел саен хезмәт базарында якынча 35 мең эшче кадр җитешмәве турында хәбәр ителә. Аеруча азык-төлек сәнәгате һәм җиңел сәнәгать, көнкүрештә кулланыла торган электр җиһазларын төзәтү,





автотранспорт өлкәсендә эшче кадрлар, табиблар һәм укытучылар җитми. Шулай ук халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсенә караган һөнәрләргә хезмәт базарында ихтыяҗ артканнанарта бара. Пешекче, тегүче, парикмахер, кунакханәдә хезмәт күрсәтү (сервис), җәмәгать туклануы предприятиеләрендә хезмәт күрсәтүне оештыру, бакча, парклар һәм ландшафт төзелеше өлкәсендә белгечләр кирәк.

Егетләр электр һәм газ ярдәмендә эретеп ябыштыручы, автомеханик, автотранспорт йөртүче, электромонтёр, махсус программа белән идарә ителә торган станок операторы һөнәрен сайласалар, эш урыны табуда кыенлык кичермәячәкләр.





**2.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Хезмәт базарында эшче көчләр җитешми, чөнки ... .
2. Мин электромонтёр булырга телим, шуңа күрә ... .
3. Махсус программа белән идарә ителә торган станок операторы һөнәрен сайлаганнар ... .
4. Кемнең парикмахер буласы килә, ... .
5. Кайсы уку йортында бюджет урыннары бар, ... .

**3.** Как скажете о том, что:

— электромонтёр — хорошая профессия;
— хотите пойти учиться на повара;
— на рынке труда не хватает рабочих профессий;
— страна нуждается в рабочих;
— профессия газоэлектросварщика — прибыльная профессия?

**4.** Фикерне дәвам итеп, сөйләргә өйрәнегез.

1. Шундый һөнәр бар: ... .
2. Кайсы кеше күңелен биреп эшли, ... .
3. Мин укыйсы уку йортында ... .

**5.** Спросите у друга:



— знает ли он, какие профессии на сегодняшний день востребованы;

— где можно получить профессию электросварщика в нашем городе (районе);

— медсестра — это престижная профессия;

— чем занимается ландшафтный дизайнер.



**6.** Диалогларга репликалар куегыз, үзара сөйләшегез.

1. — Мин җәй көне эшкә урнашырга уйлыйм.
— ... ?
— Яшелләндерү, урамнардагы һәм парктагы чәчәк түтәлләренә су сибү буенча эшләргә телим. Әйдә минем белән.
— ... .
— ... ?
— Мин, авылга кайтып, әбием белән бабама булышам.

2. — Мин җәй көне эшкә урнашырга уйлыйм. Ә син?
— ... .
— Әйдә бергә эшлибез.
— Әйдә. Ләкин безне эшкә алырлармы икән?
— ... .
— Аның өчен кая барырга кирәк?
— ... .

**7. Исегездә калдырыгыз!**

**Урын һәм охшату-чагыштыру рәвешләре**
Наречия места и сравнения-уподобления

**ерак** — далеко
**якын** — близко
**яшьләрчә** — по-молодежному
**заманча** — современно
**батырларча** — героически

**8.** Тәрҗемә итегез.

1. Уку өчен ерак барасы да түгел — якын гына урнашкан Махсус икътисади зонада төрле һөнәрләргә өйрәтәләр. 2. Икътисади зонада уку

корпуслары заманча техника белән җиһазландырылган. 3. Корпусларның бизәлеше дә заман рухына туры килә. 4. Икътисади зонада бик күп эшчеләр тырыш хезмәт куеп эшли.

**9.** Төркемнәрдә фикерләшегез. Сез бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз?

— Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
— Эшләгән табар — ташка кадак кагар.

**10.** Көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсенә караган һөнәрләр турында сөйләргә өйрәнегез.

## 49 нчы дәрес

**1.** Гариф Ахуновның «Хәзинә» әсәреннән өзекне укыгыз. Анда сүз нинди профессия кешеләре турында бара?

Арслан, эшкә керү турында сөйләшергә теләп, парторг Корбанов кабинетына барып керде.

Корбанов нәрсәдер яза иде. «Мөмкинме?» дигән тавышка башын күтәреп карады. «Мөмкин», — диде, тагын язуын дәвам итте. Язып бетергәннән соң гына, Арсланга карады.



— Ни йомыш, энекәш?
— Утырырга мөмкинме?
Корбанов елмаеп куйды һәм җитди итеп сорады:
— Я, әйтегез соравыгызны?
— Бораулаучы буласым килә, иптәш Корбанов.
— Һөнәрегез?
— Слесарь.
— Стажыгыз?
— Сугыш беткәннән бирле.
— Сугышта булдыңмыни?
— Партизан-снайпер.

— Оho! — Корбанов Арсланга ихтирам белән карады. — Ни өчен туры миңа кердең? Директорга яки кадрлар бүлегенә кермәдең?

— Миңа тиз кирәк, — диде Арслан һәм урындыктан торды.

— Ярый, бездә бораулаучы урыны бар, кирәкле документларны әзерләгез.

**ни йомыш?** — по какому делу?
**бораулаучы** — бурильщик

**2.** Бу җөмләләр хикәя эчтәлегенә туры киләме?

1. Әсәрдә сүз партизаннар турында бара.
2. Әсәрдә вакыйгалар сугыш вакытында бара.
3. Әсәрдә сүз нефтьчеләр турында бара.
4. Арслан слесарь булып эшләргә тели.
5. Арслан бораулаучы булып эшләргә тели.

**3.** Түбәндәге бәяләр әсәрдәге кайсы геройга туры килә?

— Олы яшьтә, кешеләргә игътибарлы, күпне күргән җитәкче, һәр нәрсәне уйлап эшли, эшчеләрен хөрмәт итә.

— Сугышта катнашкан, слесарь, партизан-снайпер, хезмәт ярата, тик утыра алмый, вакытны юкка әрәм итми, сәламәт ир-егет.

**4.** 3 нче күнегүдәге сүзләрне кулланып, әсәрдәге геройларга характеристика бирегез.



**5.** Әйтик, сез эшкә урнашырга килдегез. Сезнең белән эшкә алучы арасында нинди сөйләшү булыр? Эш урыннары:

а) мәктәп;
ә) банк;
б) завод;
в) ресторан.

6. Исегезгә төшерегез, Татарстанда «кара алтын» кайларда табыла?

## 50–51 нче дәресләр

1. **Исегездә калдырыгыз!**

**Иярчен шарт җөмлә**
Сложноподчинённые предложения с придаточными условия

Придаточные условия (иярчен шарт җөмлә) служат для выражения условия выполнения действия в главном предложении и присоединяются к главному предложению союзом **«если»- (әгәр)** и глагольными аффиксами **-са, -сә.**

Н а п р и м е р: Әгәр эшне дөрес сайласа, ул үз хезмәтен яратачак. Тырышып эшләсәң, нәтиҗәгә ирешерсең.

2. Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Әгәр мин заводка эшкә керсәм, ... . 2. Әгәр мин табиб булсам, ... . 3. Кинәт җил чыкса, ... . 4. Безнең шәһәргә Сергей Лазарев килсә, ... . 5. Мин Казанга барсам, ... .

3. Р. Вәлиева шигырен укыгыз. Гомәр нинди һөнәр сайлаган?

**Гомәр һәм һөнәр**

Укудан туйды Гомәр,
Сайламак булды һөнәр.
Уйлый ул: «Ә кем буласы,
Нинди эшкә тотынасы?

Әгәр заводка керсәм?
Бик күп һөнәрләр белсәм?
Эшче... Почётта, түрдә,
Начар булмастыр бер дә...

Тик...
Завод шаулап, гөжләп торыр,
Цехы тулы халык булыр.
Станоклар көн-төн гүләр,
Ул тавыштан башың түнәр.
Шунда эшләсенме Гомәр?
Китче, җүләр!





Ярый.
Ә очучы булсам?
Зәңгәр болытларга кунсам?
Күктә йөрсәм коштай очып?
Шук җилләр белән узышып?!

Ләкин...
Самолёт ватылса...
Җилдә канатлары сынса?
Биектән мәтәлеп төшсәң?!
Куркыныч бар шул бу эштә...





Менә әгәр шофёр булсам?
Шәп бер «Волга»га утырсам?
Элдерт кенә, әйдә, давай!
Ярый торган эш бит, малай!



Тик...
Һаман юл күзәтәсе,
Ватылып китсә, төзәтәсе...

Әй!
Әллә төзүче булыйммы?
Йорт салырга тотыныймммы?
Ә җил чыкса? Яңгыр яуса?
Салып беткәч, йортың ауса?!
Өстеңә ишелеп төшсә?
Кирпече түбәңне тишсә?!»

Малай киерелде, сузылды,
Бүртенде, йөзе бозылды:
«Юк, эш миңа кулай түгел,
Берсенә дә тартмый күңел.

Иң яхшысы — өйдә тору,
Әниеңнең улы булу,
Әтиеңнең улы булу,
Эшләмичә тик утыру.

Утырасың гел тынычта,
Борчу да юк,
Куркыныч та...»

Шулай итеп, безнең Гомәр
Сайламакчы шундый һөнәр,
Бар малайлар гыйбрәт алмак
Исеме булыр — Әрәмтамак!

Р. Вәлиева

**сайламак булды** (сайларга булды) — решил выбрать
**эшкә тотынырга** — браться за дело
**начар булмастыр** — здесь: было бы неплохо
**гөжләп тора** — гудит
**һөнәрләр турында** — о профессиях
**ватылса** — если разобьётся
**мәтәлеп төшсәң** — если упадёшь
**куркыныч** — здесь: опасность
**ауса** — если упадёт
**тишсә** — если продырявит
**кулай эш** — удобная работа
**әрәмтамак** — тунеядец

**4. Тәрҗемәне исегездә калдырыгыз!**

**баш түнү** — одуреть
**гыйбрәт алу** — извлечь урок
**элдертү** — быстро шагать, мчаться, нестись

**5.** Һәрбер һөнәрнең авыр яклары була. Гомәр аларны ничек күз алдына китерә? Шулар турында хикәядән табып укыгыз.

1. Эшче һөнәре.
2. Очучы һөнәре.
3. Шофёр һөнәре.
4. Төзүче һөнәре.

**6.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Гомәр һөнәр сайлау турында нинди фикергә килә?
2. Гомәр кебек кешеләрне кем дип атыйлар?
3. Һөнәр сайлау турында сезнең фикерләрегез нинди?

**7.** Автор ни өчен малайларга: «Гомәрдән гыйбрәт алыгыз», — ди? Төркемнәрдә фикерләшегез.

**8.** Бу мәкальләрне сез ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

— Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.
— Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.

**9.** Төркемнәрдә сөйләшегез. Темалар:

— Минем электромонтёр буласым килә (килми), чөнки … .
— Минем банкир буласым килә (килми), чөнки … .
— Минем төзүче буласым килә (килми), чөнки … .
— Минем сатучы буласым килә (килми), чөнки … .
— Минем табиб буласым килә (килми), чөнки … .

**10.** «Минем булачак һөнәрем» темасына инша языгыз.



# 52–54 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Иярчен вакыт җөмлә**

Сложноподчинённые предложения с придаточным времени

Придаточные времени отвечают на вопросы **«когда?»**, **«как долго?»**, **«с каких пор?»**, **«до каких пор?»** и указывают на время протекания действия в главном предложении, присоединяются с помощью деепричастия на **-гач/-гәч, -кач/-кәч, -ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче, -ганда/-гәндә, -канда/-кәндә.**

Например: Яңгыр яугач, агачлар яшәреп китте. Җәй җиткәч, мин эшкә урнашам.

**2.** Җөмләләрне укыгыз, гади һәм кушма җөмләләрне күрсәтегез.

1. Кич белән без урамга йөрергә чыгабыз. 2. Җәй житү белән, мин эшкә урнашам. 3. Үскәч, без хәрби кешеләр булырга, илебезне сакларга хыялланабыз. 4. Эшкә киткәнче, өй эшләреңне эшләп бетер. 5. Еллар үткәч, балалар төрле якларга таралалар. 6. 9 нчы сыйныфны бетергәнче, мин һөнәрләр турында бөтенләй уйламадым.

**3. Исегезгә төшерегез!**

| Слово, оканчивающееся на букву: | Примеры |
|---|---|
| гласного или звонкого согласного звука | аша-**гач**, ал-**гач**<br>күрә-**гәч**, бир-**гәч** |
| глухого согласного звука | ат-**кач**, кайт-**кач**<br>кит-**кәч**, чиш-**кәч** |

Отрицательная форма образуется с помощью аффикса **-ма/-мә;**

Например:

уйла-**гач** — подумав; уйла-**ма-гач** — не подумав

эшлә-**гәч** — сделав; эшлә-**мә-гәч** — не сделав

**4.** Җөмләләрне укыгыз, баш һәм иярчен җөмләләрне билгеләгез.

1. 16 яшькә җиткәч, эшкә керергә ярый.
2. 15 яшькә җиткәч, җиңел эшкә керергә ярый.

3. Әти эштән кайткач, без барыбыз да кичке ашны ашарга утырдык.
4. Техникумны тәмамлагач, мин институтка укырга керәм.

**5.** Как скажете о том, что:

— сегодня нужны рабочие профессии;
— появились новые профессии;
— профессия программиста очень востребована?
— У меня брат работает риелтором.
— Я интересуюсь профессией аудитора.

**6.** Диалогны үзара сөйләшегез.

— Альбина, нинди яңа һөнәрләр бар?
— Аудитор, мерчендайзер, имиджмейкер, риелтор, маркетолог, аналитик.
— Син бу һөнәрләр турында кайдан беләсең?
— Кичә класс сәгатендә яңа һөнәрләр турында сөйләштек.
— Ә син киләчәктә кем булырга телисең?
— ... .

**7.** Тиешле бәйләүче чараларны кулланып, иярченле кушма җөмләләр төзегез.

1. Ул мәкаләне укыды. Мин яңа хәбәр ишеттем. 2. Әнисен хөрмәт итә. Бала бәхетле була. 3. Күңел биреп эшли. Эшләр уңышлы була. 4. Опека рөхсәт бирде. Мин эшкә урнаштым. 5. Көнгә 5 сәгать эшләде. Кызлар өйгә кайтып китте. 6. Бала күңеле далада була. Һәркем яхшы белә.

**8.** Текстны укыгыз. Сез нинди яңа мәгълүмат алдыгыз, шул турыда иптәшләрегезгә әйтегез.

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексында каралганча, 16 яше тулганнар белән генә хезмәт килешүе төзелә ала. Кайбер очракларда закон 15, 14 һәм аннан да кечерәк яшьтәгеләр белән дә мондый килешүләрне төзергә рөхсәт итә. Әйтик, 15 яше тулганнар укудан буш вакытта артык зур физик көч таләп итмәгән эшкә урнаша ала. Ләкин бу хезмәт төре уен бизнесы, төнге клублар эшчәнлеге, вахталы эш, спиртлы эчемлекләр һәм тәмәке җитештерү, аларны сату белән бәйле булмаска тиеш. 14 яшьлекләргә эшкә урнашу өчен, әти-әнисенең, опека органнарының рөхсәте кирәк. Башкарачак хезмәтләре уку процессына комачауламаска һәм сәламәтлеккә зыян китермәскә тиеш. Эшкә алганда, олылардан аермалы буларак, балигъ булмаган балалар өчен сынау срогы куелмый.

Һичшиксез үтәлергә тиешле шартларның берсе — үсмер медицина тикшерүе узарга тиеш.

Атналык эш вакыты 16 яшьтән кечерәкләр өчен — 26 сәгатьтән (көнгә 5 сәгать), 16 дан 18 гә кадәр булганнарга 35 сәгатьтән (көнгә 7 сәгать) артмаска тиеш.

Эшләүче үсмерләр дә, башкалар кебек үк, ел саен түләүле ял алырга хокуклы. Аның озынлыгы 31 көн итеп билгеләнгән.



**9.** Тексттан түбәндәге эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз.

1. Яшүсмерләрнең эшкә урнаша алу вакыты.
2. Яшүсмерләргә рөхсәт ителгән хезмәт төрләре.
3. Атналык эш вакыты.

**10.** Текст эчтәлеге буенча план төзегез. Текст эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**11.** Как вы скажете о том, что:

— подросткам можно работать с 14 лет;
— нужно пройти медицинский осмотр;
— отдел опеки должен дать разрешение;
— у работающего подростка есть отпуск — 31 календарный день?

**12.** Посоветуйте другу (подруге):

— сходить в центр занятости;
— написать заявление об устройстве на работу;
— устроиться на работу в центр озеленения;
— пройти медосмотр до 5 июня;
— не устраиваться в ночной клуб;
— не работать больше 5 часов;

— прочитать законы о труде;
— купить сборник статей.

**13.** Диалогның төшеп калган репликаларын куегыз.

— Дима, мин кичә эшкә юллама алдым.
— ... ?
— Яшьләр үзәгенә вахтёр булып эшләргә.
— ... ?
— Көнгә 5 сәгать эшләргә. Әйдә бергәләп эшлик.
— Ярый, мин уйлап карармын.

**14.** Сез эшкә урнашырга килдегез, ләкин сезне эшкә алмыйлар. Үзегезнең хокукларыгыз турында әйтеп, бу эшкә лаеклы булуыгызны дәлилләгез.

## 55–57 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Хикәя фигыль**
Глагол изъявительного наклонения

| Хәзерге заман **-а/-ә-** **-ый/-и** | Үткән заман | | Киләчәк заман | |
|---|---|---|---|---|
| | билгеле **-ды/-де-** **-ты/-те** | билгесез **-ган/-гән-** **-кан/-кән** | билгеле **-ачак/-әчәк-** **-ячак/-ячәк** | билгесез **-ыр/-ер-** **-ар/-әр, -р** |
| бар-а | бар-ды | бар-ган | бар-ачак | бар-ыр |
| кил-ә | кил-де | кил-гән | кил-әчәк | кер-ер |
| жырл(а)-ый | кайт-ты | кайт-кан | жырла-ячак | яз-ар |
| сөйл(ә)-и | кит-те | кит-кән | сөйлә-ячәк | кит-те |
| | | | | түз-әр |
| | | | | жырла-р |

**2.** Бирелгән фигыльләрне 1 нче күнегүдәге таблицада күрсәтелгән заман формаларына куегыз, җөмләләр төзегез.

Мактый, яклый, ярата, эшли, сайлый, соңга кал, дәвам ит.

**3.** Бирелгән фигыльләрне үрнәктәгечә үзгәртегез, тәрҗемә итегез.

Ү р н ә к: бар — барды — барган — барачак — барыр.
Укы, бел, бул, ал, сал, яса, сөйлә, бир, көрәш, өйрән, тор.

**4.** Җөмләләрдән ия белән хәбәрне табыгыз, тыныш билгеләрен аңлатыгыз.

1. Сез — иң гүзәл кеше. 2. Сез — иң сабыр кеше. 3. Сез — бик ярдәмчел кеше. 4. Ул — бик тырыш кеше. 5. Аня — җаваплы хезмәткәр. 6. Александр — тыйнак егет.

**5.** Диалогны укып, үзара сөйләшегез.

— Настя, син кем булырга уйлыйсың?

— Уйлап бетермәдем әле. Әти юрист булырсың, ди. Әни табиб булырсың, ди. Мин үзем кем булачакмын — белмим әле. Ә син кем булырга телисең?

— Мин киләчәгемне инде ачык беләм: мин архитектор булачакмын.

**6.** Ф. Яруллинның «Иң гүзәл кеше икәнсез» шигырен укыгыз. Шигырьдә сүз нинди һөнәр иясе турында бара?

**Иң гүзәл кеше икәнсез**

Килгән чакта башка авырлык,
Җитми калса көч я сабырлык,
Сиздермичә ярдәм иткәнсез —
Сез иң күркәм кеше икәнсез.

Балаларның теле — кыңгырау,
Гел чыңгылдый, ява мең сорау.
Барысына да җавап биргәнсез —
Сез иң гүзәл кеше икәнсез.

Укып чыгып, дөнья тануны,
Бәхетебезне эзләп табуны
Зур ышаныч белән көткәнсез —
Сез иң сабыр кеше икәнсез.




Җырны тыңла

Мактагансыз тиеш урында,
Яклагансыз тиеш урында,
Безнең өчен сез тир түккәнсез —
Сез иң гүзәл кеше икәнсез.

Ф. Яруллин

**сабырлык** — терпение, выдержка
**сиздермичә** — незаметно, украдкой
**күркәм** — красивый
**чыңгылдый** — звенит
**яклагансыз** — защищали
**тир түккәнсез** — проливали пот

**7.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

[а°wы̆рлы́ķ], [са°бы̆рлы́ķ], [йәрдә́м], [йа°wа́], [җа°wа́п], [дөнйа́], [кэшә́], [йа°ķлаға́нсы̆с], [ķы̆ңғы̆ ра́°w], [чы̆ңғы̆лды́й].

**8.** Шигырьдәге инверсия күренешле җөмләләрне уңай тәртиптә үзгәртеп языгыз.

**9.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

1. Укытучы эше бик авыр, ләкин мактаулы.
2. Укытучы эше бик мактаулы, ләкин тиешле дәрәҗәдә бәяләнми.
3. Укытучы эше авыр түгел.

**10.** Бу сыйфатларның кайсылары укытучы һөнәренә туры килә? Алар белән берничә җөмлә төзегез.

Сабыр, тыйнак, надан, белемле, матур, сөйкемле, батыр, гадел, тырыш, усал, кешелекле, акыллы, җаваплы, аралашучан, юмарт, саран, хисчән, тыйнак, түземле, хәйләкәр, тәртипле, эзләнүчән, икейөзле, мактаулы, киң күңелле, олы җанлы, ярдәмчел.

**11.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәп языгыз. Партадашыгыз белән сөйләшергә өйрәнегез.

1. — ... ?
— Әйе, безнең укытучыбыз — бик сабыр, ярдәмчел кеше, ул безне мактый белә.
— Ни өчен шулай уйлыйсың?
— ... . Ә сезнең укытучыгыз нинди?
— ... .

2. — Сезнең гаиләдә укытучылар бармы?
— ... .
— Безнең гаиләдә дә укытучылар юк, ләкин туганнар арасында бар.
— ... ?
— Әнинең сеңлесе, абыйның хатыны — укытучылар.
— ... ?
— Әнинең сеңлесе математика укыта, ә абыйның хатыны — татар теле укытучысы.
— ... ?
— Алар икесе дә 24 нче мәктәптә эшлиләр.

3. — Син ничек уйлыйсың, укытучы булу җиңелме?
— Укытучы булу җиңел түгел.
— Ни өчен алай уйлыйсың?
— ... .
— Әгәр син укытучы булсаң, нинди фәнне сайлар идең?
— ... .

**12.** Убедите друга в том, что:

— нужно выбрать профессию учителя;
— нужно уважать труд учителя;
— учителем работают только те люди, которые очень любят детей.

**13.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Иярчен сәбәп җөмлә**

Сложноподчинённые предложения с придаточным причины

Придаточные причины содержат указания на причину того, о чём говорится в главном предложении, и отвечают на вопросы **«почему?» (ни өчен?)**, **«по какой причине?» (ни сәбәпле?)**, присоединяются к главному предложению при помощи союза **«чөнки»** и относительного слова **«шуңа күрә»**.

Например: Мин табиб булырга телим, чөнки табиб булу — бик дәрәҗәле һәм кирәкле эш. Әтием геолог булып эшли, шуңа күрә мин дә тау институтына укырга керергә әзерләнәм.

**14.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Укытучы белемле булырга тиеш, чөнки ... .
2. Укытучы таләпчән булырга тиеш, чөнки ... .

3. Укытучы гадел булырга тиеш, чөнки ... .
4. Укытучы заманча булырга тиеш, чөнки ... .
5. ..., шуңа күрә укытучы заманнан артта калмаска тиеш.
6. ..., шуңа күрә укытучы бик күп белергә тиеш.
7. ..., шуңа күрә укытучы булу җиңел түгел.

**15.** Яраткан укытучыгыз турында бер-берегезгә сөйләгез.

## 58–59 нчы дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

| Килешләр | |
|---|---|
| Баш килеш | кем? нәрсә? |
| Иялек килеше | кемнең? нәрсәнең? |
| Юнәлеш килеше | кемгә? нәрсәгә? кая? |
| Төшем килеше | кемне? нәрсәне? |
| Чыгыш килеше | кемнән? нәрсәдән? кайдан? |
| Урын-вакыт килеше | кемдә? нәрсәдә? кайда? |

**2.** Укытучылар арасында талантлы шәхесләр бик күп. Сарман районы Чураш авылыннан укытучы-шагыйрә Вәсимә Хәйруллинаның шигыре белән танышыгыз.

**Килешләр**

— Мин, баш килеш, — беренче,
«Кем?» һәм «Нәрсә?» соравым.
Җөмләдә дә баш кисәк —
Ия булып торамын.

— Ия белән бутамагыз,
Мин — иялек килеше.
«Кемнең? Нәрсәнең?» соравын
Алдым шуңа килешеп.



Аергыч, тәмамлык булам,
Кергәч җөмлә эченә.
Әйбернең иясен табып,
Тырышам бар көчемә.

— Кемгә? Нәрсәгә? Кая? — дип,
Юнәлешне күрсәтәм.
Юнәлеш килеше булгач,
Һәр тарафны күзәтәм.




— Төшем килеш исемем дә,
Төшендерәм һәркемне:
Яратырга, яратмаска
Беләм «Нәрсәне? Кемне?»

— Чыгыш килеш — чыгып киләм,
«Нәрсәдән?» чыгып барам.
Кайтам «Кайдан?», көләм «Кемнән?»
«Нәрсәдән» көч-дәрт алам?

— Ә мин бик тә төгәл килеш,
Беләм урын, вакытны.
«Кайда? Кайчан?» — диеп сорыйм,
Ләкин саклыйм тактны.

«Кемдә? Нәрсәдә?» соравын
Куярга да яратам.
Урын хәле, вакыт хәле,
Диләр миңа карата.

Менә шулай алты туган,
Алтыбыз да бик матур.
Грамматика илендә
Яшибез без бик тату.

В. Хәйруллина

**бутамагыз** — не путайте
**төшендерәм** — разъясняю
**дәрт** — задор, страсть

3. Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

[ба°ш], [ийә́], [бута́мағыс], [ты̆ ры̆ ша́м], [қа́°йа], [төшө́м], [йа°раты̆ рға́], [wa°қы̆т], [уры́н].

4. Шигырьдән файдаланып, таблицаны тутырыгыз.

| Килеш исеме | Сораулары | Җөмлә кисәге |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

5. **Казан, Интернет, фикер** сүзләрен килешләр белән төрләндерегез.

6. Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез, үзара сөйләшеп карагыз.

— Олег, татар телендә ничә килеш бар?

— ... .

— ... ?

— Юнәлеш килеше «кемгә?», «нәрсәгә?» «кая?» сорауларына җавап бирә.

— Ә «кайдан?» соравына нинди килеш җавап бирә?

— ... .

— Предметларның урынын нинди килеш белдерә?

— ... .

7. Сообщите другу о том, что вы:

— после уроков любите гулять с собакой;
— вечером встретитесь с писателями в библиотеке;
— у друзей возьмёте новые фильмы для просмотра;
— хотели бы сходить на фильм «Адмирал»;
— в свободное время любите слушать музыку;
— попросили у родителей купить спортивный велосипед.

8. Убедите друга:

— почитать в Интернете о востребованных профессиях;
— заранее готовиться к государственной итоговой аттестации;
— уважать учителей, родителей, старших.

9. Диалогларның төшеп калган репликаларын куегыз. Исемнәрне табыгыз, килешләрен билгеләгез.

1. — Сәлам, Вася. Кая барасың?
— ... .
— Фильм нәрсә турында?
— ... .
— Син ничек уйлыйсың, бу фильм тарихи материалларга баймы?
— ... . Әйдә бергә барыйк.
— Юк, минем акчам юк шул.
— ... .
— Рәхмәт, дустым. Бик шатланып барам.

2. — Сәлам, Оля. Кайдан кайтып киләсең?
— ... ?
— Мин шифаханәгә барган идем.
— Син шифаханәгә еш йөри башладың. Әллә эшкә урнаштыңмы?
— ... .
— Мин дә эшли аламмы?
— ... .
— Ярый, дустым, иртәгә бергә барырбыз.

10. «Киләчәк укытучысы» дигән темага төркемнәрдә фикер алышыгыз. Кечкенә инша языгыз.

## 60–62 нче дәресләр

1. Сүзләрне укыгыз, транскрипция билгеләре белән языгыз.

Абруй, сәләт, дәвалаучы, уңай нәтиҗә, юри, көзән җыера, күм-күк, мөһим, үртиләр, төргәк, чир.

2. Сүзләрнең тәрҗемәләрен табыгыз һәм җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| абруй — ... | чир — ... | мөһим — ... |
| сәләт — ... | юри — ... | дәвалаучы — ... |

3. Бирелгән сүзләргә антонимнар табыгыз һәм кушма җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| яхшы — ... | көчле — ... | юри — ... |
| игътибарлы — ... | салкын — ... | кайнар — ... |
| көн — ... | файда — ... | еш — ... |
| уңай — ... | акыллы — ... | зур — ... |

**4.** Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәреннән өзек укыгыз. Әсәрдә сүз нинди һөнәр кешеләре турында бара?

Профессор Әбүзәр Таһиров Казанда йөрәк авырулары буенча иң яхшы белгечләрнең берсе санала. Аңа күренер өчен, төрле шәһәрләрдән һәм авыллардан йөзләрчә кешеләр килә. Халык арасында аның абруе бик зур. Аның ягымлы, игътибарлы булуы һәм сәләте турында хәтта легендалар йөри.

Бүген профессорның консультация көне иде. Сәгатенә карап алды да:

— Башлыйк, — диде ул дәвалаучы врачка. — Маһирә ханым, сез нинди кыз турында әйткән идегез?

— Ул монда, Әбүзәр Гиреевич, көтеп тора. Унтугыз яшьтә, студентка.

— Йөрәк?

— Комбинированный порок. Моңа кадәр дә больницаларда яткан, ләкин дәвалау уңай нәтиҗә бирмәгән.

— Керсен.

Профессор, урыныннан торып, ишектән кергән кызга каршы китте.

— Рәхим итегез, менә монда утырыгыз, — диде ул, ишектән юри ерак куелган урындыкка күрсәтеп, үзе кызның ничек керүен, аяк атлавын, хәрәкәтләрен, йөзен күзәтте. Үзе дә, урындык алып, кыз янына утырды. — Исемегез ничек?

— Асия.

— Я, Асия, сөйләгез, нәрсә борчый сезне?

— Бераз авырдым әле менә, — диде Асия, аска карап. Чынында исә аның тормышы көннән-көн көчлерәк булган приступлардан тора иде.

Приступ башлангач, бөтен тәнен көзән җыера, арка, йөрәк авырта, һава җитми, кул-аяклар суына, йөзе ап-ак, иреннәре күм-күк була. Бернинди уколның, даруның файдасы тими.



Профессор Асиянең ничек авыруын аңлап алды. Ләкин нәтиҗә ясарга ашыкмады. Кайбер кешеләр, хәзерге заманда иң мөһиме — анализлау, диагноз куючы машиналар, диләр. Ләкин профессор Таһиров, нинди генә акыллы машина булмасын, ул бервакытта да врачның фикерен алмаштыра алмый, дип уйлый иде. Профессор бик гади генә сораулар бирде.

— Балачакта малайлар белән уйный идегезме, Асия?

— Әлбәттә.

— Кем дип үртиләр иде?

— Чеби Асия...

— Ә мороженое яратасызмы? — дип елмайды профессор.

— Аны кем яратмый?

— Ә тамак авыртмыймы?

— Авырта, әни кайнар сөт эчерә.

— Димәк, ангина белән еш авырыйсыз. Ә театрга еш йөрисезме?

— Театрга да йөрмәгәч...

— Әлбәттә, капрон оек киеп. Шулаймы? Кыш көне дә. Аяклар авыртамы?

— Анысына гына түзәр идем...

Профессор аның аяк, кул буыннарын карады да:

— Температура еш буламы? — дип сорады.

— Әни, гел янасың, пешәсең, ди.

Асия кесәсеннән зур төргәк кәгазь чыгарды.

— Мин, Асия, кәгазь дәваларга җыенмыйм, — диде профессор. — Ә менә үзегез, теләсәгез, күп нәрсә әйтә аласыз. Тереләм дигән кеше генә терелә бит. Әле борынгы заманда бер көнчыгыш врачы бер авыруга болай дигән: «Без өчәү: син, мин, чир. Әгәр синең белән икәү бер якта булсак, без чирне җиңәрбез». Аңладыгызмы?

Ул борчылган, курыккан, киләчәктә күңелсезлекләр генә көткән кызны тынычландыру юлларын эзли иде.

Г. Әпсәләмов

**белгеч** — специалист
**абруй** — авторитет
**юри** — нарочно
**борчый** — беспокоит
**хәрәкәт** — движение
**чынында исә** — на самом деле
**көзән җыера** — судороги сводят
**нәтиҗә** — результат



**5.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге өзекләрне табып укыгыз.

1. Профессор Әбүзәр Таһиров — яхшы белгеч.
2. Асиянең авыруы.
3. Көнчыгыш врачының әйткән сүзләре.

«Ак чәчәкләр» телесериалын карагыз

**6.** Җөмләләрне киңәйтеп укыгыз. Һәр яңа җөмләгә сорау куегыз.

1. Профессор Әбүзәр Таһиров санала. 2. Кешеләр килә. 3. Легендалар йөри.

**7.** Әсәрдән профессор Әбүзәр Таһировның кешеләргә игътибарлы, тәҗрибәле врач икәнен раслаган җөмләләрне табып укыгыз.

**8.** Профессор Таһировның Асия белән булган әңгәмәсен укыгыз, иптәшегез белән сөйләшергә өйрәнегез.

**9.** Сез бу җөмләләрнең эчтәлеген ничек аңлыйсыз?

— Терелəм дигән кеше генә терелә бит.

— Әгәр синең белән икәү бер якта булсак, чирне җиңәрбез.

**10.** Текстны тәрҗемә итегез, бер-берегезгә сөйләгез.

В понедельник Артур не пришёл в школу. Ночью у него поднялась температура, заболело горло. Его мама вызвала «скорую помощь». Врачи измерили температуру, увезли его в больницу. Там ему поставили диагноз: гнойная ангина.




Артур целую неделю пролежал в больнице. Врачи были очень внимательными и доброжелательными. Мальчика хорошо лечили, и он быстро поправился. Через неделю Артур выписался из больницы. Он всем рассказал о врачах, больнице, лечении.

**11.** Вы у врача. У вас болит голова (живот, рука, ноги, шея, горло, уши, глаза). Как вы об этом скажете?

**12.** Врач спрашивает, не болит ли у вас голова, выпили ли вы какое-либо лекарство. Как он об этом скажет?

**13.** Заболела ваша сестрёнка. Вы хотите узнать, есть ли у неё температура, нужен ли градусник, лекарство. Как вы спросите?

**14.** Сестрёнка принимает лекарство. Спросите, чем она будет запивать его: чаем или водой.

**15.** Вы в аптеке. Вам нужно купить лекарство от головной боли. Как вы спросите?

**16.** Допустим, у вас заболела бабушка. Предложите ей попить чай с мёдом, лечь и отдохнуть.

**17.** Табибларга нинди сыйфатлар хас булырга тиеш? Төркемнәрдә фикерләшегез, дәфтәрегезгә языгыз. Язганда кушма җөмләләр кулланыгыз.

**18.** «Безнең тормышта ак халатлы кешеләрнең роле» дигән темага кечкенә инша языгыз.

## 63–65 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Иярчен максат җөмлә**

Сложноподчинённые предложения с придаточными цели

Придаточные цели раскрывают цель того, о чём говорится в главном предложении, и отвечают на вопросы **«зачем?»**, **«для чего?»** **(ни өчен?)**, **«ради какой цели?»** **(нинди максат белән?)**, образуются при помощи глаголов повелительного наклонения 3-го лица единственного и множественного числа и послелога **«өчен»**.

Н а п р и м е р: Дөнья ямьле булсын өчен, әни кирәк.
Ашау тәмле булсын өчен, әни кирәк.

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез:

Уңыш күп булсын өчен, ... .
Җирдә икмәк булсын өчен, ... .
Игенче булу өчен, ... .
Игенче һөнәренә ихтирам булсын өчен, ... .
Игеннәр яхшы үссеннәр өчен, ... .
Балалар бәхетле булсыннар өчен, ... .

**3.** Сүзләрнең тәрҗемәләрен табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| кушамат | | лоб |
| маңгай | | совесть |
| тир | ? | порядок |
| намус | | прозвище |
| тәртип | | явление |
| күренеш | | пот |

**4.** Бирелгән сүзләргә тиешле кушымчалар өстәп, сыйфатлар ясап укыгыз. Сыйфатлар белән җөмләләр төзегез.

Үрнәк: эш — эшле — эшсез.

Рәхим, тәртип, намус, мәхәббәт, яңгыр, закон, көч, болыт, чик, урман, су.

**5.** Тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

сөйләшә-сөйләшә кайтып килә — ...
җырлый-җырлый эшли — ...
ачулана-ачулана китте — ...
укый-укый яза — ...
эшли-эшли әйтә — ...

**6.** Тәрҗемәсен языгыз.

выброшенный хлеб — ...
нарушители порядка — ...
неписаный закон — ...
бессонные ночи — ...
обычное явление — ...
гордость человека — ...
целый каравай хлеба — ...
обрывки газет — ...
великий труд — ...

**7.** Как скажете о том, что:

— на земле валяются обрывки газет, пластиковые бутылки, пустые консервные банки;
— на землю брошены куски хлеба;
— у хлебороба бессонные ночи;
— охрана природы — обязанность каждого;
— хлеб — великий труд и гордость человека?

**8.** Текстны укыгыз. Кем ул гражданин «Икс»?

## Хезмәткә — хөрмәт

Икмәк!

Бу сүз — Ана исеме белән янәшә торырлык олы сүз. Күпме шигырь, күпме роман язылган икмәк турында! Шулай да мин: «Без икмәкне ихтирам итә беләбезме?» — дип башларга телим.

Беркөнне без бер танышым белән Аккош күле яныннан сөйләшә-сөйләшә кайтып килә идек. Менә шушы гүзәл алан өстендә ертылып

ташланган газета кисәкләре, буш консерва савытлары, шешә ватыклары күреп аптыраштык. Ял көннәреннән соң безнең урманнарда, елга һәм күл буйларында бу инде гадәти күренешкә әйләнеп бара. Ә бу юлы без анда-монда ташланган икмәк телемнәрен дә күрдек. Хәтта бер агач төбендә бербөтен икмәк ята иде.

Бу икмәкне кем ташлаган? Ул рәхимсез кешенең исеме ничек? Мин аңа гражданин «Икс» дип кушамат бирдем. Юк, монда түзеп торырга ярамый.

Гражданин «Икс»!

Сиңа иң элек берничә сорау: икмәкнең кайда һәм ничек үскәнен күргәнең бармы? Икмәк нәрсә ул?

Менә шушы кырда трактор җир сөргән, орлык чәчкән. Бу җирләргә яңгыр гына яумаган, монда игенченең маңгай тирләре дә тамган. Игенче язын, көзен яңгыр астында калмаганмы? Монда йокысыз төннәр дә, авыр көннәр дә бар.

Бездә тәртип бозучыларга каршы законнар бар, ә менә синең белән нишләргә соң, гражданин «Икс»? Сиңа карата да яңа закон чыгарыргамы? Андый закон бар инде. Ул законның исеме — намус. Менә шул законны син оныткансың, гражданин «Икс».



Бу — беркая да язылмаган закон. Икмәккә — ихтирам, кешегә — мәхәббәт! Бу сүзләр йөрәктә яши. Шуңа күрә дә алар тормыш законы дип аталырга хаклы. Бу законны үтәү — һәркемнең бөек хезмәте дә, горурлыгы да. Син бу хакта оныткансың, гражданин «Икс».

Н. Дәүлидән

**янәшә** — рядом
**ихтирам** — уважение
**алан** — поляна
**маңгай тире тамган** — трудился в поте лица
**гадәти** — привычный
**кушамат** — прозвище
**аптыраштык** — растерялись

**9.** Бу җөмләләр текст эчтәлегенә туры киләме? Сез аларның эчтәлеген ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

1. Икмәк! Бу сүз — Ана исеме белән янәшә торырлык олы сүз.
2. Ял көннәреннән соң безнең урманнар, елга һәм күл буйлары чиста кала.

3. Бу икмәкне кем ташлаган? Ул рәхимсез кешенең исеме ничек? Юк, моңа түзеп торырга ярамый.

4. Игенче менә шушы кырда трактор белән җир сөргән, орлык чәчкән, язын, көзен яңгыр астында эшләгән.

5. Ул законның исеме — намус.

**10.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәп языгыз, сөйләшергә өйрәнегез.

— ... ?

— Игенче иген үстерә.

— ... ?

— Игенчеләр дип тракторчыларга, комбайнчыларга, авыл хуҗалыгы механизаторларына әйтәләр.

— Татарстанда игенчеләр нинди игеннәр үстерәләр?

— ... .

**11.** Игенче һөнәренең нинди авыр яклары бар? Шул турыда сөйләргә өйрәнегез.

**12.** «Икмәккә — ихтирам, кешегә — мәхәббәт! Бу сүзләр йөрәктә яши. Шуңа күрә дә алар тормыш законы дип аталырга хаклы» дигән фикерне ничек аңлыйсыз? Игенче һөнәренә ихтирам темасына төркемнәрдә фикерләшегез, кечкенә инша языгыз.

## 66–67 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз.

Йолдыз, очучы, космонавт, эссе, игенче, яңгыр, закон, мәхәббәт.

**2.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| асты | | бар |
| олы | | аз |
| буш | | җиңел |
| гүзәл | | тулы |
| авыр | ? | кече |
| яңа | | кечкенә |
| бөек | | иске |
| күп | | ямьсез |
| юк | | өсте |

**3.** Бирелгән җөмләләрдә иярчен җөмләләрне табыгыз, бәйләүче чараларны күрсәтегез, мәгънәсе һәм төзелеше ягыннан төрләрен билгеләгез.

1. Бакчадан саф һава керсен, шуның өчен тәрәзәләрне ачыгыз.
2. Игеннәр яхшы үссен дип, агроном тырышып эшләп йөри.
3. Уңыш күп булсын өчен, без бакчада көн саен эшлибез.

**4.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Зур уңыш алабыз дип, ... .
2. Игеннәр уңсын өчен, ... .
3. Җир дымлансын дип, ... .

**5.** Тәрҗемә итегез.

1. Утырткан агачлар исән калсын дип, күршем көн-төн тырышты.

2. Малайлар, яшелчәләр шиңә башламасын өчен, икенче көнне су сибәргә тотындылар.

3. Иген үстерүчеләр сәламәт булсын дип, аларга картлар дога кылдылар.

**6.** Шигырьне укыгыз. Ипи кемнәргә кирәк? Бер-берегезгә сөйләгез.

**Ипи кирәк!**

Һәркемгә ипи кирәк!
Һәм көн дә ипи кирәк!
Ипи космонавтка да,
Очучыга да кирәк.
Ипи сезгә дә кирәк,
Ипи безгә дә кирәк, —
Һәммәбезгә дә кирәк!
Ипи эшләргә кирәк,
Ипи яңа йолдызлар
Ачучыга да кирәк.
Ипи иген игүдән
Качучыга да кирәк.
Ипи эшләмичә тик
Ятучыга да кирәк!
Ипи кибеттә ипи
Сатучыга да кирәк.



Юллар сузарга кирәк.
Тайгаларда иң авыр
Юллар узарга кирәк.
Ипи безгә дә кирәк:
Үсеп җитәргә кирәк!
Шуңа да игенчене
Хөрмәт итәргә кирәк!

Р. Миңнуллин

**иген игү** — выращивать хлеб
**эшләмичә** — не работая

**7. Исегездә калдырыгыз!**

**Соң** бәйлеге — чыгыш килешен сораучы бәйлек: эштән соң — после работы; Мараттан соң — после Марата; миннән соң — после меня; яңгырдан соң — после дождя; бездән соң — после нас.

Яңгырдан соң табигать яшәреп китә.

**8.** Посоветуйте другу:

— не оставлять мусор в лесу, у реки;
— не играть с хлебом;
— беречь хлеб;
— уважать труд хлебороба;
— быть внимательным к чужому труду.

**9.** Посоветуйте братишке не бросать хлеб, беречь его.

**10.** Скажите о том, что:

— нужно уважать труд хлебороба;
— хлеб — основа жизни;
— выращивать хлеб — нелёгкая работа.

**11.** Сез мәктәптән кайтасыз. Юлда малайлар икмәк кисәге белән футбол уйныйлар. Сез бу малайларга нәрсә дип әйтер идегез?

# СӘЛАМӘТЛЕК — ЗУР БАЙЛЫК



## 68–70 нче дәресләр

1. Сәламәтлекне саклау кагыйдәләрен сөйләргә өйрәнегез.

**1. Чисталыкны сакла!**

Үзеңнең тәнеңне, киемеңне чиста тот. Кулны юарга, тешне чистартырга, душта сабын һәм мунчала белән юынырга, аяк киемен һәм өс киемен чистартырга, бүлмәне җилләтергә, өйне һәрвакыт җыештырып торырга, ишегалдын чиста тотарга. Сәламәт яшәү рәвеше чисталыктан башлана!

**2. Дөрес туклан!**

Сәламәт туклану — сәламәт яшәү рәвеше нигезләренең берсе.

Ризыкны төрлеләндер, яшелчә һәм җиләк-җимешне җитәрлек куллан, үз вакытында ашыкмыйча аша.

**3. Хезмәтне һәм ялны дөрес оештыр!**

Сәламәтлекне саклау өчен, хезмәтне ял белән чиратлаштырырга кирәк. Телевизор, видео, компьютер уеннары чаманы белгәндә генә яхшы. Алар белән артык мавыкма. Саф һавада йөр, уйна һәм китап укуны да онытма.

**4. Күбрәк хәрәкәтлән!**

Аз хәрәкәтләнү сәламәтлек өчен зарарлы. Иртән зарядка ясa. Саф һавада хәрәкәтле уеннарны күбрәк уйна. Физик хезмәт, физкультура белән шөгыльлән. Чаңгыда шуу, йөзү, спорт уеннарының сәламәтлек өчен файдасы зур.

**5. Начар гадәтләрдән саклан!**

Тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр һәм наркотиклар куллану — иң начар, зарарлы гадәтләр. Наркотиклар тарату — зур җинаять, аның өчен каты җәзага тарталар. Сәламәтлекне саклау өчен, бервакытта да тәмәке тартма, спиртлы эчемлекләрне авызыңа да алма, наркотикларга якын да килмә.

**6. Стрессы ситуацияләрдә тыныч бул!**

Сез теләгәнчә булмаган очракта башкалар гаепле булмаса да, алар белән ачуланышырга ашыкма. Авыр ситуацияләрдә тыныч кала белү һәм үзеңне контрольдә тоту осталыгы — тормышта бик кирәкле сыйфат.

**7. Гаджетларны (электрон җайланмаларны) дөрес куллан!**

Электрон җайланмаларны да дөрес куллана белергә кирәк. Социаль челтәрләрдә утыру, анда фотолар карау, лайклар кую, комментарийлар язуларның бөтенесен бергә санасаң, кешеләрнең көнгә ничә сәгате бушка уза, бәйлелеккә әрәм була. Спорт белән шөгыльләнү, интеллектны үстерү урынына телефондагы уенда яңа «баскыч»ка күтәрелү, шул уңышлар белән мактану сәламәтлекне бер дә арттырмый, киресенчә, зыян гына китерә.

**2.** Хатны укыгыз.



«Энекәшемне телефоннан аерып алып булмый. Мәктәптән кайткач, ашаса — ашый, ашамаса — юк, дәресләрен дә юньләп карамый, телефоныннан әле смс җибәреп, әле уен уйнап утыра. Җитмәсә әтидән яңа телефон сорап аптырата. Телефонын яшереп тә карадык, файдасыз. Бөтенләй чиргә сабышты».

Гөлназ

**3.** Сүзләрне һәм сүзтезмәләрне дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемәләрен табыгыз.

Энекәшемне, аерып алып булмый, юньләп карамый, сорап аптырата, яшереп тә карадык, чиргә сабышты, башка дөнья, бөтен булган акчасын, гаджетоманиядән интегә, андыйлар шактый, тикшеренүләр күрсәткәнчә, сөенеч китерүе, депрессиягә бирелү.

**4.** Җөмләләрнең баш һәм иярчен кисәкләрен, төрен билгеләгез.

1. Мәктәптән кайткач, ашаса — ашый, ашамаса — юк, дәресләрен дә юньләп карамый, телефоныннан әле смс җибәреп, әле уен уйнап утыра. 2. Телефонын яшереп тә карадык, файдасы булмады. 3. Гаджет — электрон уенчык дигән сүз, ә гаджетомания — шул уенчыктан башка тора алмау. 4. Бер яктан, яңа телефон яки MP3-плеерның сөенеч китерүе начар әйбер түгел, ә икенче яктан, ул гаджетларга бәйлелек симптомнары барлыкка килүгә сәбәп булырга мөмкин. 5. Төнгә әтисе телефонын алып сүндерә башлагач, йокысы туя башлады.

**5.** Сез Гөлназга нинди киңәш бирерсез? Төркемнәрдә фикерләшегез. Әйтергә теләгән фикерләрегезне дәфтәрегезгә языгыз, бер-берегезгә сөйләп карагыз.

**6.** Гөлназ хатына җавап язган Алия Галиева фикерләре белән танышыгыз.

Бу язманы энекәшең белән бергәләп укы, Гөлназ. Чиргә сабышты дөньяның дөрес тә, тормышын гел компьютер алдында гына уздыра торган, башка дөнья барлыгын белмәгән олы абыйлар да, бөтен булган акчасын һаман саен яңа ноутбук, коммуникатор, смартфон, телефон кебек әйберләргә тота торган егет-кызлар да — барысы да гаджетоманиядән интегә.

Гаджет — электрон уенчык дигән сүз, ә гаджетомания — шул уенчыктан башка тора алмау. Һәм андыйлар шактый икән. Россиянең 6 зур шәһәрендә үткәрелгән тикшеренүләр күрсәткәнчә, 18–36 яшьлекләрнең 85 проценты — кесә телефоныннан, яртысы CD- һәм МР3-плеерлардан башка яши алмый икән. Бер яктан, яңа телефон яки МР3-плеерның сөенеч китерүе начар әйбер түгел, ә икенче яктан, ул гаджетларга бәйлелек симптомнары барлыкка килүгә сәбәп булырга мөмкин.



Симптомнары менә нинди:

— уенчыктан аерыла алмау;

— һаман саен яңа уенчык аласы килү;

— аның белән бәйле чыгымнарны (смс, сөйләшүгә киткән акчалар) контрольдә тота алмау;

— торган саен күбрәк вакытны аның белән уздыру;

— уенчыгыңнан башка депрессиягә бирелү;

— дусларга, гаилә әгъзаларына игътибарның кимүе;

— ялганлау;

— укуда проблемалар килеп чыгу.

Гаджетларга бәйлелек нәрсәләргә китереп җиткерергә мөмкин соң?

Һаман саен төймәләргә басып утыру, кулның аерым мускулларына көч китереп, нервларын какшатырга, мониторга текәлеп карап утырудан күзләргә көч килергә, баш авырту, йокысызлык килеп чыгарга мөмкин.

Минем бер танышым да, мендәр астына яшерелгән телефоныннан төне буе смс алышып, сөйләшеп чыгып, иртәнге 4 тә генә йоклап китә дә беренче дәрескә көчкә тора. Төнгә этисе телефонын алып сүндерә башлагач, йокысы туя башлады.

Бу очракта ни эшләргә соң?

Беренчедән, яраткан уенчык белән көненә бер сәгатьтән артыграк «аралашмаска», ай саен яңа уенчык алу турында хыялланмаска! Компьютер яки телефон янына утырасы гына килеп тора һәм бу хисне берничек тә җиңеп булмый икән, аны өйдә калдырып, урамга чыгып

йөреп керергә, дусларны ешрак кунакка чакырырга. Кызыклы фильм да карарга мөмкин. Һичьюгы, уенчыгыңның инструкциясен тагын бер тапкыр укып, өйрәнеп чыгарга, бәлки, син аны тулысынча куллана белмисеңдер. Монысы аеруча мөһим, бәлки, син, киләчәктә техника белән бәйле һөнәр үзләштереп, хоббиеңны һөнәреңә әйләндерерсең?

Алия Галиева

**һаман саен** — постоянно
**ялганлау** — обманывать
**бәйлелек** — зависимость
**тулысынча** — полностью
**йокысы туя** — высыпается
**көч китереп** — нагружая

**7.** Сорауларга җавапны тексттан табып укыгыз.

1. Гаджетомания нинди авыру?
2. Гаджетларга бәйлелек симптомнары нинди?
3. Гаджетларга бәйлелекнең организмга зыяны нидән гыйбарәт?
4. Гаджетомания авырумы әллә хоббимы?

**8.** Тексттан гаджетларга бәйлелектән котылу юлларын табып, дәфтәрегезгә языгыз. Сез тагын нинди ысуллар тәкъдим итәр идегез?

**9.** Диалогларны укыгыз, дәвам итегез.

1. — Костя, кая барасың?
— Кибеткә барам, яңа телефон кирәк.
— Синең телефоның яхшы бит, югалттыңмы әллә?
— ... .

2) — Надя, синең сеңлең яки энең бармы?
— Энем бар, сеңлем юк.
— Ул ничәнче сыйныфта укый?
— Энем 3 нче сыйныфта укый.
— Ә аның кесә телефоны бармы?
— Әлбәттә.
— Син аңа телефон кирәк дип саныйсыңмы?
— ... .

**10.** Допустим, у вашего младшего брата появляется зависимость от компьютерных игр. Что бы вы ему посоветовали? Напишите в тетради.

## 71–72 нче дәресләр

**1.** Исем фигыльнең килешләр белән төрләнешен исегезгә төшерегез, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| Баш килеш | бар(-ма)-у | йөр(-мә)-ү |
| Иялек килеше | бар(-ма)-у-ның | йөр(-мә)-ү-нең |
| Юнәлеш килеше | бар(-ма)-у-га | йөр(-мә)-ү-гә |
| Төшем килеше | бар(-ма)-у-ны | йөр(-мә)-ү-не |
| Чыгыш килеше | бар(-ма)-у-дан | йөр(-мә)-ү-дән |
| Урын-вакыт килеше | бар(-ма)-у-да | йөр(-мә)-ү-дә |

**2.** Бирелгән исем фигыльләрнең тәрҗемәсен табыгыз, берничәсен килешләр белән төрләндерегез.

Күңел болгану, баш әйләнү, косу, йөрәк кагу, ярсыну, һуштан язу, тарту, уку, туу, үлү.

**3.** Сүзләрне тәрҗемә итегез, дөрес укырга өйрәнегез.

Гадәт [ғәдә́т], тәмәке [тәмәкә́], агулы [а°ғулы́], косу [қосу́], ярсыну [йа°рсы̆ну́], үпкә [үпкә́], очрак [очра́қ].

**4.** Җөмләләрне укыгыз, ия белән хәбәрне билгеләгез.

1. Иң киң таралган начар гадәтләрнең берсе — тәмәке тарту. 2. Никотин — бик агулы матдә. 3. Синиль кислотасы, сөрем газы, аммиак, формальдегид — тәмәке төтенендәге зарарлы матдәләр. 4. Хатын-кыз — булачак ана.

**5.** Текстны укыгыз.

### Тәмәке тартуның зарары

Иң киң таралган начар гадәтләрнең берсе — тәмәке тарту. Тәмәкедәге никотин — бик агулы матдә. Тарта башлаганда, күңел болгану, баш әйләнү, косу, йөрәк кагу, ярсыну һәм шуннан соң хәтта һуштан язу күзәтелә. Организм никотинга ияләшкәч, кеше тәмәкенең рәхәт ярсытуын гына сизә.



Тәмәке төтенендә бик зарарлы синиль кислотасы, сөрем газы, аммиак, формальдегид бар. Яман шеш китереп чыгара торган бензопирен аеруча зарарлы. Тәмәке тартучыларда үпкә ялкынсынуы, туберкулёз, бронхиаль астма авырулары бик еш очрый.

Тәмәке тартучы укучыларның хезмәт һәм ял режимы бозыла. Алар тәнәфестә башкалар белән ял итмиләр, дәрес бетүгә, тәмәке тартырга урын эзләп йөгерәләр һәм бөтен тәнәфесне шунда үткәрәләр. Тәмәке тарту яхшы укуга комачаулый, хәтерне начарайта.

Тикшерүчеләр әйтүенчә, тәмәке кеше гомерен 5–15 елга кыскарта. Бер сигарет гомерне 7 минутка киметә.

Кызганычка каршы, хатын-кыз да тәмәке тарта. Бу аеруча зарарлы. Ни өчен? Хатын-кыз — булачак ана. Тәмәке тарткан хатын-кызның баласы зәгыйфь яисә гарип булып туарга мөмкин. Халыкара статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, тартучы хатын-кызлар тудырган яшь балаларның үлү очрагы 40 процентка артыграк.

Вакытлы матбугаттан

**киң таралган** — широко распространённый
**ярсыну** — прийти в возбуждённое состояние
**һуштан язу** — потерять сознание
**сөрем газы** — здесь: угарный газ
**яман шеш** — раковая опухоль
**күңел болгану** — тошнота
**тәмәке тарту** — курение
**матдә** — вещество
**косу** — рвота
**йөрәк кагу** — сердцебиение
**ялкынсыну** — воспаление
**гарип** — инвалид, калека
**зәгыйфь** — слабый, хилый

**6.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз.

— тәмәке төтенендәге зарарлы матдәләр;
— тәмәке тартучыларда еш очрый торган авырулар;
— тәмәке тартуның укуга комачаулавы;
— хатын-кызлар өчен тәмәке тарту аеруча зыянлы.

**7.** Җөмләләрне укыгыз, сораулар куегыз.

1. Тарта башлаганда, баш әйләнә, йөрәк кага. 2. Тәмәке төтене бик зарарлы. 3. Тәмәке тартучы укучылар тәнәфестә башкалар белән ял итмиләр, дәрес бетүгә, тәмәке тартырга урын эзләп йөгерәләр.

**8.** Текстка карата план төзегез. Үзегез төзегән план нигезендә текстның эчтәлеген төркемнәрдә сөйләп карагыз.

**9.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез, сөйләшергә өйрәнегез.

— ... ?

— Әлбәттә, никотин сәламәтлек өчен зыянлы.

— Тәмәке тартучылар ни өчен төрле авырулар белән авырыйлар?

— ... .

— Бер сигарет тарту гомерне 7 минутка кимәтә.

**10.** Фикерләрне дәвам итегез.

1. Хатын-кыз — булачак ана, шуңа күрә ... .
2. Хатын-кыз тәмәке тартса, аның баласы ... .
3. Исерек кеше сигарет кабып йоклап китсә, ... .
4. Тәмәке тарту, аракы эчү сәбәпле, гаиләләрдә ... .

## 73–74 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәләрен табыгыз, дөрес укырга өйрәнегез.

Исерткеч эчемлекләр [исэрткэ́ч эчэмлэклә́р], шәраб [шәрә́п], тупас [тупа́с], аңгыра [а°ңғыра́], бозык [бозŏ́к], җинаять [җинәйә́т], эчкече [эчкэчә́], авыру [а°wру́], томалый [тŏмалы́й], намус [на°му́с], зарар [за°ра́р], аек [а°йы́к].

**2.** Текстны укыгыз.

### Аракы кешене нишләтә?

Шәраб, аракы, сыра эчү нәрсәгә китерә?

Суд язмаларыннан күренгәнчә, ун җинаятьнең тугызы исерек хәлдә эшләнә. Исерткеч эчемлекләр куллануның бер нәтиҗәсе бу.

Эчкечеләр төрле авырулар белән авырыйлар, һәм аларның күбесе шушы авырулардан үлеп тә китә. Исерткеч эчемлекләр куллануның икенче нәтиҗәсе әнә шундый.

Шәраб кешеләрнең акылын һәм намусын томалый; шәраб эчкән кеше тупасрак, аңгырарак, усалрак була бара.

Шәраб кешегә сәламәтлек тә, көч тә, күңеллелек тә бирми, бары тик зарар гына китерә.

...Әгәр әле син беркайчан да эчмәгән, аракы белән агуланмаган яшь кеше икәнсең, үзеңнең кадереңне бел! Шәраб күңелне күтәрә дигәнгә ышанма. Шәраб синең тормышыңны акылсыз һәм бозык күңел ачуга әйләндерә. Шулай булгач, нигә дип үзеңне шундый куркыныч астына куярга?

Вакытлы матбугаттан

**шәраб** — вино
**сыра** — пиво
**җинаять** — преступление
**томалый** — заглушает




**3.** Аракы эчү нинди нәтиҗәләргә китерә? Тексттан шул җөмләләрне табып укыгыз.

**4.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Ун җинаятьнең тугызы ... . 2. Эчкече кешеләр каты авырулар ... . 3. Шәраб кешеләрнең акылын ... . 4. Шәраб кешегә сәламәтлек тә, ... . 5. Шәраб кешенең тормышын ... . 6. Хатын-кыз аракы эчсә, ... . 7. Аракы эчкәч, кеше ... .

**5.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәгез. Сөйләшергә өйрәнегез.

— ... ?

— Шәраб кешегә бик начар тәэсир итә. Шәраб эчкән кеше усал, тупас, кызып китүчән була.

— Эчкече һәм җинаять эшләү бер-берсенә ничек бәйле?

— ... .

**6.** Текстны укыгыз. Текстка сораулар төзегез. Бер-берегезгә сөйләп карагыз.

«Сыра аракы түгел!» — дияргә ашыкма. Сыра алкоголизмы аракы алкоголизмына караганда да куркынычрак. Көн саен сыра эчүче егетләр киләчәктә гаилә кора алмаска, кызлар бәби таба алмаска мөмкин. Сыра күп эчкән кеше артык тазара, йөрәге авырта. Сыра эчү егетлек билгесе түгел.

**7.** Схемалар буенча диалог төзегез.

1. — тәкъдим итү
   — риза булмау
   — аңлату
   — сорау бирү
   — исбатлау
   — риза булу

2. — киңәш бирү
   — риза булмау, фикерне кире кагу
   — исбатлау
   — риза булу, килешү

Тема: Туган көндә исерткеч эчемлекләр эчү яки эчмәү.

**8.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме? Төркемнәрдә сөйләшегез.

— сырада алкоголь аз, шуңа күрә организмга зыяны юк;
— яхшы фильтрлы сигаретта никотин аз, шуңа күрә аны тарту зыянлы түгел;
— яшь организмга һәртөрле исерткеч эчемлек тә зыянлы;
— тәмәке тарткан кеше янында тору сәламәтлеккә зарарлы;
— тәмәке тартып, шәраб эчеп, кафеда утыру — заманча яшәү.

## 75–76 нчы дәресләр

**1.** **Исегезгә төшерегез!**

(минем) барасым (күрәсем) килә (килми) — я (не) хочу ехать (видеть)
(синең) барасың (күрәсең) килә (килми) — ты (не) хочешь ехать (видеть)
(аның) барасы (күрәсе) килә (килми) — он (не) хочет ехать (видеть)
(безнең) барасыбыз (күрәсебез) килә (килми) — мы (не) хотим ехать (видеть)
(сезнең) барасыгыз (күрәсегез) килә (килми) — вы (не) хотите ехать (видеть)
(аларның) барасы(лары) (күрәсе(ләре) килә (килми) — они (не) хотят ехать (видеть)

**2.** Җөмләләрне укыгыз, теләк белдерү формаларын атагыз.

1. Диманың зур бизнес белән шөгыльләнәсе килә. 2. Минем бик күп беләсем килә. 3. Безнең сыйныф белән ял итү базасына барасыбыз килә. 4. Аларның тәмле ризыклар татып карыйсылары килә. 5. Синең наркотиклар турында видеофильм карыйсың киләме?

**3.** Фигыльләргә тиешле кушымчаларны куеп укыгыз.

| | |
|---|---|
| минем белә... | килә (килми) |
| синең укый... | |
| аның сөйли... | |
| безнең күрә... | |
| сезнең бара... | |
| аларның яза... | |

**4.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

Тормыш, яшүсмер, мәҗбүри, ямьсезләнә, хәлсезләнә, зыян, начарлык.

**5.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| татып карый | ? | тянет |
| тарта | | соединяется |
| тоташа | | обманывается |
| калынайта | | утолщает |
| күнегә | | привыкает |
| алдана | | пробует |

**6.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| начар | ? | матур |
| югары | | чиста |
| зыян | | карт |
| ямьсез | | файда |
| пычрак | | яхшы |
| яшь | | түбән |

**7.** Текстны укыгыз.

### «Ак үлем»нән саклан!



Тормышта һәрвакыт шулай: белмәгән, күрмәгән нәрсәне татып карыйсы килә. Ул сине үзенә магнит кебек тарта. Менә наркотикларны алыйк.

Наркотиклар киң таралуның беренче сәбәбе — бизнес, ягъни наркотик сатып баю. Бу наркобизнес дип атала. Наркобизнес ул — кешелексезлек кәсебе. Моңа каршы көрәшү өчен, наркотиклар кулланучыларны киметү кирәк. Керем бетсә, товар сатылмаса, кәсепче баюның башка юлын эзләргә тиеш була.

Наркотик кулланучылар артуның башка сәбәпләре дә бар. Мәсәлән, кешегә мәҗбүри рәвештә наркотик кадау, эчертү, кешегә ияреп куллану һ.б. Инде бер күнеккәч, кеше аннан башка яши алмый башлый, чираттагы дозасын эзли.

Наркотик кулланучының йөзе, күзләре ямьсезләнә, үзе хәлсезләнә. Ул кеше үтерүгә, урлауга һәм тагын әллә нинди начарлыкларга барып җитәргә мөмкин.

Әгәр наркотик куллана башласаң, тиз арада табибка барырга кирәк. Никадәр иртәрәк барсаң, терелүгә ышаныч шуның кадәр күбрәк.

Вакытлы матбугаттан

**сәбәп** — причина
**кәсеп** — ремесло, промысел
**ямьсезләнә** — становятся некрасивыми
**хәлсезләнә** — обессиливает
**үтерү** — убийство
**терелү** — выздоровление

**8.** Тексттан бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз:

— наркотикларның таралу сәбәбе;
— наркотик кулланучыларның артуы;
— наркотик кулланган кешеләр турында;
— наркотиктан котылу юллары.

**9.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Наркотиклар киң таралуның сәбәбе — … .
2. Наркотикларга каршы көрәшү өчен, … .
3. Наркотик кулланучының … .
4. Наркотик куллана башласаң, … .
5. Наркотик сатучыларны белсәң, … .

**10.** Текст буенча план төзегез. Планга карап, текст эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

**11.** Диалогны дәвам итегез.

— Кичә «Перехват» тапшыруында безнең күрше подъездда яшәгән егетнең наркотиктан үлүен сөйләделәр.

— ... .

**12.** Что бы вы посоветовали однокласснику, у которого есть желание попробовать наркотики?

## 77–78 нче дәресләр

**1.** Сәламәт яшәү кагыйдәләрен искә төшерегез. Кеше стресслы ситуацияләрдә үзен ничек тотарга тиеш?

**2.** Диалогны укыгыз. Кызлар арасында татулык ни өчен бозылган? Аларның үзүзләрен тотышларына нинди киңәшләр бирерсез?

— Бүген Наташа белән Алсу бергә булмадылар, сөйләшмәделәр дә. Алар аерылгысыз дуслар иде бит!

— Әйе шул. Без аларның дуслыгына кызыгып карый идек.

— Ә нәрсә булган соң?

— Наташа кичә малайлар янында Алсуны кимсеткән. Бу күлмәгең белән син тутый кошка охшагансың дигән?

— Алсу да җавапсыз калмаган. Синең дә макияжың тутый кошныкы кебек дигән.

**аерылгысыз** — неразлучные
**тутый кош** — попугай
**кимсеткән** — унизила

**3.** Тәрҗемә итегез.

У всех нас разные характеры, разные желания и потребности, а также разные способы проявления эмоций. Чтобы ориентироваться во всём этом, нужны тактичность и сообразительность — особенно если мы надеемся добиться успеха в жизни. Именно здесь эмоциональный интеллект приобретает важное значение.

**4.** Текстны укыгыз. Тексттагы җөмләләр ярдәмендә эчтәлеккә план төзегез.

Үзара яхшы мөнәсәбәттә булу, бәхәсле мәсьәләләрне җиңел хәл итү өчен, кеше эмоциональ интеллектка ия булырга тиеш. Эмоциональ

интеллект — үз гамәлләреңне һәм хисләреңне контрольдә тота белү һәм бәхәсле ситуацияләрдән конфликтсыз чыга алу ул.

Эмоциональ интеллектлы шәхесләр нинди төп сыйфатларга ия? Алар, уйламыйча, импульсив карарлар кабул итми, бәхәсле ситуацияләрдә үз-үзләрен контрольдә тота, башкаларны тыңлый, кичерә беләләр. Нәтиҗәдә эмоциональ интеллектка ия кешеләр коллективта, гаиләдә яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыралар, эшләре уңышлы бара.

Эмоциональ интеллектны ничек яхшыртырга мөмкин?

Беренчедән, үз-үзеңне хөрмәт ит. Бу үз-үзеңне мактау дигән сүз түгел. Киресенчә, бу — үзеңнең начар сыйфатларыңны күрә белү, аларны үзгәртергә тырышу.

Төрле проблемалы ситуацияләрдә, бәхәсләрдә уйламыйча, барлык фактларны белмичә, ашыгыч нәтиҗә ясарга ярамый.

Иң кирәкле сыйфатларның берсе — тыйнак булу. Уртак хезмәттә үз өлешеңне генә күрсәтергә тырышу — матур гадәт түгел. Башкаларның да хезмәтен күрә, аларны да мактый, сөендерә белү мөһим.

Әгәр сез кемне дә булса рәнҗеткәнсез икән, гафу үтенергә кирәк. Күңелсез хәлне төзәтергә тырышыгыз. Бу очракта кешеләр, гадәттә, кичерергә һәм онытырга сәләтле.

Тормышта уңышка ирешү өчен акыл интеллекты мөһим, ә эмоциональ интеллект башка кешеләр белән яхшы аралашу һәм максатларыгызга ирешү өчен ачкыч булып тора.

**гамәлләр** — действия
**мөнәсәбәтләр** — отношения
**ирешәләр** — достигают
**бәхәсле мәсьәләләр** — спорные вопросы
**хисләр** — чувства
**кичерә** — прощает
**рәнҗетү** — обижать

**5.** Сорауларга җавап бирегез.

1) Эмоциональ интеллект нәрсә дигән сүз ул?
2) Эмоциональ интеллектка ия булу кешегә ничек тәэсир итә?
3) Эмоциональ интеллектлы шәхесләрнең нинди уңай сыйфатлары була?
4) Эмоциональ интеллектны ничек яхшыртырга мөмкин?

**6.** «Тормышта уңышка ирешү өчен, акыл интеллекты мөһим булса да, эмоциональ интеллект башка кешеләр белән яхшы аралашу һәм максатларыгызга ирешү өчен ачкыч булып тора» дигән җөмләне ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

**7.** «Сүзеңне әйткәнче, 40 тапкыр уйла», «Сүзең бер алтын булса, эндәшмәвең мең алтын» дигән мәкальләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне тормыштан мисаллар белән дәлилләп языгыз.

# БЕРКЕМ ДӘ, БЕРНӘРСӘ ДӘ ОНЫТЫЛМЫЙ



## 79–81 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемәләрне истә калдырыгыз.

**Бөек Ватан сугышы** — Великая Отечественная война
**Советлар Союзы Герое** — Герой Советского Союза
**участник войны** — сугышта катнашкан (кеше)
**«Үлемсез полк» хәрәкәтендә катнашу** — участие в движении «Бессмертный полк»

**батырлык** — подвиг
**Җиңү көне** — День Победы
**удостоен** — лаек була
**сугышчы** — воин
**дошман** — враг;
**чик** — граница;
**һөҗүм** — нападение, нашествие

**2.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес әйтергә өйрәнегез, тәрҗемәсен сүзлектән табыгыз.

Исеме, катнашкан, бирелә, сугышчан, очыш, кадәр, очучы.

**3.** Сүзләрнең логик парларын табыгыз.

Советлар Союзы
Бөек Ватан
Тукай
Прости
Рейхстаг

?

авылы
дивары
Герое
сугышы
районы

**4.** Саннарны сүзләр белән языгыз.

8, 11, 19, 93, 139, 1941, 782, 1945.

**5.** Бу мәгълүматларны дусларыгызга сөйләгез.



Татарстаннан беренче Советлар Союзы Герое — Кайманов Никита Фадеевич. Ул Түбән Кама районы Прости авылында туган.

Бөек Ватан сугышында катнашкан 93 очучы хатын-кызга Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Шуларның икесе — Татарстаннан. Алар — Ольга Санфирова һәм Мәгубә Сыртланова.



Мәгубә Сыртланова 782 сугышчан очыш ясый. Ул Берлинга кадәр барып җитә, Рейхстаг диварына «Мәгубә Сыртланова, очучы» дип язып калдыра.

Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар арасында татарлар дүртенче урында тора, беренче урында — руслар, икенче урында — украиннар, өченче урында — белоруслар.

Вакытлы матбугаттан

**6.** Тексттан бирелгән эчтәлеккә җөмләләрне табыгыз.

1. Никита Фадеевич Кайманов.
2. Бөек Ватан сугышында катнашкан очучы хатын-кызлар.
3. Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган милләтләр.

**7.** Ике раслауның кайсы дөрес?

1. Татарстаннан беренче Советлар Союзы Герое — Никита Кайманов.
Татарстаннан беренче Советлар Союзы Герое — Ольга Санфирова.

2. Татарстаннан Бөек Ватан сугышында катнашкан 2 очучы хатын-кыз Советлар Союзы Герое була.
Татарстаннан Бөек Ватан сугышында катнашкан 3 очучы хатын-кыз Советлар Союзы Герое була.

3. Мәгубә Сыртланова 782 сугышчан очыш ясый.
Мәгубә Сыртланова меңнән артык сугышчан очыш ясый.

4. Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар арасында татарлар дүртенче урында.
Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар арасында татарлар икенче урында.

**8.** Бөек Ватан сугышында катнашкан туганнарыгыз турында нәрсәләр сөйли аласыз?

**9.** Иптәшең Бөек Ватан сугышы белән кызыксына. Сезнең арада нинди сөйләшү булырга мөмкин? Терәк сүзләрне кулланып, диалог төзегез.

Терәк сүзләр: Бөек Ватан сугышы, фашистлар Германиясе, көтмәгәндә, Брест крепосте, Мәскәү янындагы сугыш, Берлинны алу, 1945 нче ел, 9 нчы май, Җиңү көне.

**10.** 2 нче күнегүдәге сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп языгыз.

**11.** Бөек Ватан сугышы турында Интернет аша үзегез туплаган мәгълүматны төркемнәрдә бер-берегезгә сөйләгез.

**12.** Сез беләсезме?

1945 нче елның 30 нчы апрелендә совет солдатлары рейхстаг өстенә Җиңү байрагы кадыйлар. Ул солдатларның берсе Гази Заһитов исемле татар кешесе була.



**13.** Как скажете о том, что:

— в 1941 году 22 июня начинается ВОВ;
— войну начинает фашистская Германия;
— война длится 5 лет;
— Советская армия победила фашистскую Германию;
— советские солдаты дошли до Берлина?

**14.** Спросите у друга:

— когда начинается ВОВ;
— кто начинает войну;
— сколько лет длится война;
— какая страна победила на войне.

Татарстан геройлары — плакатларда

**15.** Поговори с другом.

— 9 нчы Май — ул нинди бәйрәм?
— 9 нчы Май — Җиңү көне.
— Җиңү бәйрәмендә кемнәрне котлыйбыз?
— Җиңү бәйрәмендә сугышта катнашкан ветераннарны, тыл ветераннарын котлыйбыз.

**16.** Спросите у друга:

— смотрит ли он по телевизору Парад Победы;

— участвовал ли его прадед на войне;

— есть ли у них фотографии дедушек и бабушек, участвовавших на войне.

**17.** Спросите соседа по парте:

— кто был первым Героем Советского Союза из Татарстана;

— знает ли он о подвиге Магубы Сыртлановой.

## 82–84 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес әйтергә өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

**Шигырь, әсирлек, кайгы, куркыныч, үкенечле, мәгълүм, читлек, коткару, кәгазь, байтак, ялгыз.**

**2.** Сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

[иҗа́т], [туғры̆лы́қ], [әсирлә́к], [сәйәси́], [йәшэрә́н], [тотқы̆нлы́қ], [илчә̆лә́к], [көрәштө́ш], [мәйда́н], [һәлә́к булды́], [ға°за́п], [җаза́].

**3.** Тәрҗемәне табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| мәгънә | ? | обыскивает |
| куен дәфтәре | | записная книжка |
| тентү ясый | | сыщик |
| сер эзләүче | | смысл |

**4.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| элекке | ? | олы |
| күп | | якты |
| югалган | | шатлык |
| нәни | | кыска |
| кайгы | | карт |
| караңгы | | хәзерге |
| озын | | аз |
| яшь | | табылган |

**5.** Текстны укыгыз, әчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы бөтен дөньяга билгеле. Бөек Ватан сугышы башлану белән, сугышка бармый калу мөмкинлекләре булса да, ул үзе теләп фронтка китә. 1942 нче елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә әсирлеккә эләгә. Шагыйрьнең тоткынлык тормышы башлана.

Шагыйрь үлем җәзасы көткәндә дә, туган илгә тирән мәхәббәт белән сугарылган, фашистларга көчле нәфрәтен белдергән шигырьләр яза. Аларны үзе ясаган кечкенә дәфтәрләргә теркәп бара. Аның шигырьләре язылган бер дәфтәрне төрмәдә утырганда танышкан Бельгия партизаны Андре Тиммерманс 1947 нче елда аларны безнең илгә җибәрә.

**6.** **Исегезгә төшерегез!**

**Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше**

Спряжение глаголов условного наклонения по лицам и числам

| Зат | Берлек сан | | Күплек сан | |
|---|---|---|---|---|
| | **Калын вариант** | **Нечкә вариант** | **Калын вариант** | **Нечкә вариант** |
| 1 зат | бар-са-м | кил-сә-м | бар-са-к | кил-сә-к |
| 2 зат | бар-са-ң | кил-сә-ң | бар-са-гыз | кил-сә-гез |
| 3 зат | бар-са | кил-сә | бар-са-лар | кил-сә-ләр |

**7.** Җөмләләрне укыгыз, шарт фигыльләрне билгеләгез.

1. Җәлил, туган илен яратмаса, шундый шигырьләр иҗат итә алмас иде.

2. Туган илгә шигырьләре кайтмаса, Җәлилне хыянәтче дип атарлар иде.

3. Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Муса инде үлгән», — дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

М. Җәлил

**8.** Иярчен шарт җөмләләр өстәп языгыз.

1. ..., дошман тиз арада җиңеләчәк.
2. ..., ул китаплар алыр иде.
3. ..., мин немецча сөйләшер идем.
4. ..., минем язуларым белән кызыксыныр иде.
5. ..., дуслар киләчәк.

**9.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Если бы он хорошо знал немецкий язык, ему было бы легче.
2. Если ты этого не хочешь, мы не вернёмся домой.
3. Если бы приехал мой друг, он помог бы.
4. Если бы он не был жизнерадостным, не написал бы этот рассказ.

## 85–87 нче дәресләр

**1.** Шәйхи Маннурның «Муса» әсәреннән өзекне укыгыз. Өзектә кемнәрнең дуслыгы турында сүз бара?

### Әсирлектә туган дуслык

Төрмәдә бер ай узып та китте. Бу вакыт эчендә бик күп эш эшләнде. Муса Волхов фронтында чакта ук язылган, әсирлеккә төшкәч югалган шигырьләрен исенә төшерде һәм нәни кәгазьләргә яза барды. Шулай итеп, шактый гына күләмле бер куен дәфтәре барлыкка килде. Һәм шуның белән яңа бер кайгы туды: кая куярга? Дәфтәрне камерада саклау куркыныч иде, чөнки көтмәгәндә дошманның килеп керүе һәм кинәт тентү ясавы мөмкин.

Муса шушы мәсьәлә белән баш ватканда, камерага яңа бер кешене керттеләр. Ниндидер чандыр гәүдәле, уртача озын буйлы, кара чәчсакал баскан кеше иде. Үзе яшь күренә, утыз яшьләр чамасы. Ул Көньяк Германиядән булса кирәк, шул якларда бит кара немецлар. Арий каны булса да, җитен чәчле, зәңгәр күзле түгелләр. Русча беләмикән, сөйләшеп карарга кирәк... Хәер, үзе эндәшсен. «Сер эзләүче чыпчык» (сыщик) булса, озак түзеп тора алмас, андыйларның тизрәк максатка ирешәселәре килә ич.

Әмма биш-алты сәгать узып та китте, ә «чыпчык» сайрарга ашыкмады. Кичке ут алганнан соң, Муса үзе түзмәде, русча исем-фамилиясен сорады.

Кунак, аңламады булса кирәк, елмаеп кына куйды.

— Ви һайзен зи? — диде Муса немецча.

— Андре Тиммерманс, — дип җавап бирде егет, французчарак акцент белән. — Ә үзегезнең фамилиягез ничек була?

— Гумеров, — диде Муса.

— О, русиш? — дип сорады егет сокланган тавыш белән.

— Оф! Оф! Русиш! Әйе, рус кешесе дияргә була. Гумеров, — диде Муса.

Муса шулай да аңа артык игътибар бирмәскә булды. Ул кәгазьне тезенә куйган килеш яза башлады. Элекке шигырьләрен хәтерләргә кирәк иде аңа. Ул шулай байтак кына эшләп утырды.

— Нәрсә язасыз?— дип сорады егет.

— Сөйгән кызларга хат язам, — диде Муса бик гади генә итеп.

Егет кычкырып көлеп җибәрде.

— Сөйгән кызларга хат? Шәп! Нәкъ кызлар белән хатлар алыша торган җир инде бу! Шаян кеше икәнсез. Күптән көлгән юк иде, рәхмәт сезгә!

Алар әлеге ватык-җимерек немец телендә тагын сөйләшеп алдылар. Андре Бельгия кешесе икән, кырык икенче елны ук кулга алынган. Срогы байтак бар икән әле. Муса да үзенең кайчан кулга алынуын һәм татар икәнлеген әйтте. Әмма икесе дә нинди «гаеп» белән утыруларын сөйләмәделәр. Монысы инде һәркемнең үз сере иде.

**кайгы** — здесь: огорчение, забота
**тентү ясау** — обыскивать
**йөрәк сере** — сокровенная тайна
**мәгълүм булачак** — станет известно
**баш вату** — ломать голову
**чандыр** — сухощавый
**җитен чәчле** — светловолосый
**хәер** — впрочем
**максатка ирешәселәре килә** — хотят добиться цели
**кулга алынган** — здесь: взят в плен
**гаеп** — вина
**иҗат рәхәте** — наслаждение творчеством
**мәхрүм итте** — лишил
**сәяси тоткын** — политический заключённый

**2.** Түбәндәге иярчен җөмләләрне тәрҗемә итегез. Төрләрен билгеләгез.

1. Муса шушы мәсьәлә белән баш ватканда, камерага яңа бер кешене керттеләр. 2. Арий каны булса да, җитен чәчле, зәңгәр күзле түгелләр. 3. «Сер эзләүче чыпчык» (сыщик) булса, озак түзеп тора алмас, андыйларның тизрәк максатка ирешәселәре килә ич. 4. Әмма бишалты сәгать узып та китте, ә «чыпчык» сайрарга ашыкмады. 5. Кичке ут алганнан соң, Муса үзе түзмәде, русча исем-фамилиясен сорады.

**3.** Әсәрдән бирелгән эчтәлектәге өлешләрне табып укыгыз. Бер-берегезгә сөйләгез.

1. Яңа кергән әсирнең тышкы кыяфәте.
2. Аның сөйләшергә ашыкмавы.
3. Яңа кергән әсир «сер эзләүче чыпчык» түгел.
4. Егет русча белми.
5. Әсирнең туган җире.

**4.** Әсәрдә Андре Тиммермансны уңай яктан характерлаучы нинди юллар бар? Аларны дәфтәрегезгә языгыз.

**5.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне һәм сүзтезмәләрне куеп, җөмләләрне укыгыз.

1. Шагыйрь ... чакта ук язган ... искә төшерде, ... яза барды. 2. Шулай итеп, яңа ... барлыкка килде. 3. Яңа бер ... туды: ... кая куярга? 4. Дошманның килеп керүе һәм ... ясавы бар. 5. Камерага яңа бер ... керттеләр.

**6.** Өзектә Муса Җәлилнең кайсы чордагы тормышы сурәтләнә? Интернет аша материал туплап, бер-берегезгә сөйләгез.

**7.** Диалогны үзара сөйләшегез.

— Муса Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре ничек дип атала?

— «Моабит дәфтәрләре» дип атала. Ә син беләсеңме, туган илгә аның әсирлектә язган ике дәфтәре кайта.

— Берсен беләм. Аны 1947 нче елда Бельгия партизаны Андре Тиммерманс безнең илгә җибәрә. Муса Җәлилгә әсирлектә язган шигырьләре өчен Ленин премиясе бирелә.

— Ә Советлар Союзы Герое исеме Муса Җәлилгә кайчан бирелә?

— Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме 1956 нчы елда бирелә.

**8.** «Моабит дәфтәре»ннән алынган шигырьне укыгыз. Бу юллар аша шагыйрь нәрсә әйтергә теләгән?

Әкияттәге серле йомгак булып,
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда.

М. Җәлил

**9.** Өзектән файдаланып, Муса Җәлил белән Андре Тиммерманс турында диалог төзегез, иптәшегез белән сөйләшеп карагыз.

**10.** Өзектән Андре Тиммерманс турындагы өлешләрне табыгыз. Аның турында Интернет аша өстәмә мәгълүмат туплап, биографик белешмә язып карагыз.

## 88–91 нче дәресләр

**1.** Бирелгән саннарны дөрес укыгыз, тәртип саннарына әйләндереп, дәфтәрегезгә языгыз, җөмләләр төзегез.

3, 6, 8, 11, 16, 17, 21, 35, 86, 103, 862, 1943, 8971.

**2.** Бирелгән мәгълүматны укыгыз, бер-берегезгә сөйләгез.

Икенче бөтендөнья сугышында фашистлар гаебе белән һәлак булды:

| | |
|---|---|
| Совет кешеләре | 20 000 000 |
| Немецлар | 9 700 000 |
| Поляклар | 6 028 000 |
| Югославлар | 1 600 000 |
| Французлар | 520 000 |
| Итальяннар | 400 000 |
| Чехлар, словаклар | 364 000 |
| Американнар | 325 000 |
| Инглизләр | 320 000 |

**3.** Сүзләрне укыгыз, тәрҗемә итегез, транскрипция билгеләре белән языгыз.

Төрмә, балта, сызык, тугры, сафлары, өзелә, көрәш, үч, бөек, мөдир, гарип, җаваплы, ватан, яшерен, оешма, дан, чаткы, әсир, гаеп, тоткын, тоткынлык.

**4.** Диалогны укыгыз, үзара сөйләшегез.

— Айнур, синең җәлилчеләр турында ишеткәнең бармы?
— Мин алар турында бик күп укыдым. Алар — тоткынлыкка төшкән совет солдатлары.
— Аларның батырлыгы нәрсәдә?
— Алар, яшерен оешма төзеп, немецларга каршы көрәшәләр.

**5.** Татар халкының батыр уллары — җәлилчеләр турында укыгыз, тәрҗемә итегез. Кушма җөмләләрне табыгыз, төрен билгеләгез.

## Кемнәр соң ул — җәлилчеләр?

Җәлилчеләр — тоткынлыкка төшкән әсирләр — совет солдатлары һәм командирлары. Алар Муса Җәлил җитәкчелегендә, төрмәдә яшерен оешма төзеп, фашистларга каршы көрәш алып баралар. Шуның өстенә подпольедагы Германия эшчеләре һәм коммунистлары белән бәйләнеш тотуда да гаепләнәләр, шуңа күрә фашистлар аларга карата коточкыч җәза бирәләр: башлары палач балтасы астында өзелә.

...Хөкем карарын укыганда, бу батыр кешеләрнең бер генә мускулы да тартылмады, бары тик ачудан йөзләре генә караңгыланды. Муса Җәлил һәм аның иптәшләре гомерләренең соңгы көнен һәм сәгатьләрен үткәргән Берлиндагы Шпандау төрмәсендә тирән тынлык урнашты, чөнки һәрбер тоткын алар белән саубуллаша иде...

«Татарлар елмаеп, батырларча үлделәр», — дип сөйләде соңыннан Патер Юрытко.

Әсир итальян Раниеро Ланфредини сөйләгәннәрдән

**6.** 5 нче күнегүдә бирелгән җөмләләрне гади җөмләләргә әйләндерегез, билгесез үткән заманга куегыз, бер-берегезгә укып күрсәтегез.

**7.** Парларга бүленеп, тексттагы җөмләләргә сораулар куегыз һәм җавап бирегез.

**8.** Укыгыз, тәрҗемә итегез. Үз фикерегезне әйтегез.



Гайнан Кормаш

1944 нче елның 25 нче августында Моабит төрмәсендә палач балтасы астында башлары өзелгән батыр җәлилчеләр:

1. Гайнан Кормаш — мәктәп директоры, 1939 нчы елдан армия сафларында, ак финнар белән сугышта катнаша, Ватан сугышында радио эшен өйрәнә, махсус задание белән дошман тылына ташлана. 12 сәгать 06 минутта гомере өзелә.

2. Фоат Сәйфелмөлеков — икътисадчы-товаровед, 1940 нчы елдан армиядә, 1941 нче елда Фоат хезмәт иткән часть беренчеләрдән булып иң алгы сызыкка җибәрелә. 12 сәгать 09 минутта гомере өзелә.



Абдулла Алиш

3. Абдулла Алиш — балалар язучысы. Ватан сугышы башлангач, институттан армия сафларына алына.



Фоат Сәйфелмөлеков

«Килдем, көрәштем, киттем. Ватаныма тугры булып калдым. Их, ничек яшисе килә!» — дип яза ул соңгы хатында. 12 сәгать 12 минутта гомере өзелә.


Фоат Булатов

4. Фоат Булатов — Кырымда юл эшләре төзелешендә эшләгән вакытта сугышка китә, үч алу теләге белән яши. 12 сәгать 15 минутта гомере өзелә.


Муса Җәлил

5. Муса Җәлил — легендар шагыйрь.

«Тиздән сүнәр, сүнгән йолдыз кебек,
Соңгы яшәү көчем.
Үләм, ләкин бөек хаклык өчен,
Илем, халкым өчен!»

12 сәгать 18 минутта гомере өзелә.


Әхмәт Симаев


Гариф Шабаев

6. Гариф Шабаев — финанс наркоматында бүлек мөдире, сугышның беренче көненнән үз теләге белән сугышка китә. 12 сәгать 21 минутта гомере өзелә.

7. Әхмәт Симаев — газетада эшли, 1940 нчы елда РККА сафларына чакырыла. Ватан сугышында десантчы булып хезмәт итә. 12 сәгать 24 минутта гомере өзелә.


Абдулла Батталов


Зиннәт Хәсәнов

8. Абдулла Батталов — укытучы, аягы гарип булуга карамастан, сугыш башлану белән, армия сафларына алына. 12 сәгать 27 минутта гомере өзелә.

9. Зиннәт Хәсәнов — сатучы, 1940 нчы елдан рота командиры. 12 сәгать 30 минутта гомере өзелә.


Әхәт Атнашев


Сәлим Бохаров

10. Әхәт Атнашев — хәрби, пулемётчылар командиры, сугышның беренче көннәреннән үк алгы сафта. 12 сәгать 33 минутта гомере өзелә.

11. Сәлим Бохаров — дәүләт банкы секретаре, 1940 нчы елда армиягә алына. 12 сәгать 36 минутта гомере өзелә.

**9.** Диалогларга төшеп калган репликаларны куегыз, дәвам итегез.

1. — Дустым, син җәлилчеләр турында беләсеңме?
— Әйе, беләм.
— Алар кайсы төрмәдә яшерен оешма төзегәннәр?
— ... .
— ... ?
— Минемчә, ул оешмада 10 кеше булган.
— Алар кемнәр?
— ... .
— Чын батырлар икән!

2. — Аня, Бөек Ватан сугышында бик күп милләт кешеләре һәлак булган.
— Әйе, төрле милләт кешеләре булган.
— ...?
— Руслар, татарлар, немецлар, поляклар, чехлар, словаклар, инглизләр.
— Ә итальяннар, французлар булганмы?
— ... . Безнең илнең ничә кешесе һәлак булганын беләсеңме?
— ... .
— ... .

**10.** «Моабит дәфтәре»нең авторы турында сез нәрсәләр беләсез, шул турыда сыйныфташыгызга сөйләгез.

**11.** Спросите у друга:

— когда началась Великая Отечественная война;
— сколько советских людей погибло на фронтах Великой Отечественной войны;
— кто автор «Моабитской тетради»;
— сколько джалиловцев было казнено палачами 25 августа 1944 года;
— кем работал М. Джалиль до войны;
— кто такой А. Алиш.

**12.** Как скажете о том, что:

— ваш дедушка воевал на фронтах Великой Отечественной войны;
— в вашей школе есть Музей боевой славы;
— вы собирали экспонаты для Музея боевой славы;
— никто не забыт, ничто не забыто?

# 92–93 нче дәресләр

1. **Исегездә калдырыгыз!**

**Юклык алмашлыклары**
Отрицательные местоимения

Отрицательные местоимения (юклык алмашлыклары) образуются от вопросительных местоимений (сорау алмашлыклары) путём сложения их со словами **бер, һич:** кем — беркем, һичкем (кто — никто), нәрсә — бернәрсә, һичнәрсә (что — ничто), кайчан — беркайчан, һичкайчан (когда — никогда), кайда — беркайда, һичкайда (где — нигде).

Например: Батырлык беркайчан эзсез югалмый.
Синнән башка һичкемнән ярдәм көтә алмыйм.

2. Тәрҗемә итегез:

1. Сугыш беркемне дә аямый. 2. Батыр беркайчан авырлыкларга бирешми. 3. Күзгә бернәрсә дә күренми. 4. Кызга беркем дә 16 яшь бирми. 5. Батырларның үлеменә беркем дә ышанмый. 6. Брест крепостен беркем дә ташламый. 7. Җиңү көнен беркем беркайчан онытмый.

3. Җөмләләрне дәвам итегез, төрләрен билгеләгез.

1. Мин җәлилчеләр турында күп белми идем, шуңа күрә ... . 2. Безнең илебез сугышта җиңгән, чөнки ... . 3. ..., ләкин батырлар турында онытырга ярамый. 4. ..., әмма сугыш куркынычы бүген дә бар әле. 5. ... һәм мин аның белән горурланам. 6. Я Интернет челтәреннән эзлә, я ... . 7. Иң куркынычы шул: ... .

4. Предположим, что вам нужно выступить с сообщением перед учащимися начальных классов:

1. Какой разговор состоялся бы между вами и вашим учителем?
2. Какие наводящие вопросы вы бы задали учащимся?
3. Какое выступление вы подготовили бы для учащихся о Великой Отечественной войне?
4. Что бы вы сообщили им про джалиловцев?

**5.** Мәкальләрне тәрҗемә итегез, рус телендә эквивалентын табыгыз, җөмләнең баш кисәкләренең астына сызыгыз, төрен билгеләгез.

1. Бердәмлектә — көч. 2. Тырышкан табар, ташка кадак кагар. 3. Беләге юан берне егар, белеме юан меңне егар. 4. Әйткән сүз — аткан ук. 5. Теле барның иле бар.

**6.** Тәрҗемә итегез. Юклык формасындагы фигыльләрне табыгыз, зат-сан белән төрләндерегез. М. Җәлил А. Алишка язган шигырендә нәрсә әйтергә теләгән?

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер
Ил гомеренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең яктылыктан
Арта бары аның яктысы.

**7.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез.

1. — Настя, син җәлилчеләр турында беләсеңме?
— ... .
— Кара әле, ә ни өчен аларны «җәлилчеләр» дип атаганнар икән?
— ... .
— Алар төрмәдә дә фашистлар өчен куркыныч булдымы икән?
— ... .
— Әйе, мин дә шулай уйлыйм.

2. — Оля, синең Казанга экскурсиягә барганың бармы?
— ... .
— М. Җәлил һәйкәле янында да булдыгызмы?
— ... . Теләсәң, фотоларны сиңа да күрсәтәм.
— Бик горур кеше итеп сурәтләнгән. Ә скульптураның авторы кем икән, белмисеңме?
— ... .
— ... .
— Әйе шул, хәзер Интернет аша бар нәрсәне дә табып була.

**8.** Сообщи однокласснику о том, что:

— ты много знаешь о джалиловцах;
— в Казани есть памятник М. Джалилю;
— архитектором памятника М. Джалилю является Л. Г. Голубовский;
— памятник М. Джалилю создал скульптор В. Е. Цигаль;
— ты прочитал надпись на скульптуре;
— там написано: «Жизнь моя песней звенела в народе,
Смерть моя песней борьбы прозвучит»;
— памятник был установлен в 1966 году на площади 1 Мая около Спасской башни.

**9.** Спроси у друга:

— когда были казнены джалиловцы;
— сколько было джалиловцев;
— по какой причине были казнены пленные;
— за что М. Джалилю было присвоено имя Героя Советского Союза;
— кто доставил в страну «Моабитскую тетрадь»;
— был ли он знаком с Андре Тиммермансом.

**10.** Җөмләләрне язып бетерегез.

1. Мин Казанга барсам, ... . 2. Җәлилчеләр турында укыгач, ... . 3. Шагыйрь үзе үлсә дә, ... . 4. Шигырьләрне укыгач, мин шуны аңладым: ... . 5. Үзе үлде, ә ... . 6. Билгеле ки, ... .

**11.** Түбәндәге темаларга чыгышлар әзерләгез.

«Һәр гаиләдә — сугыш истәлеге».
«Муса Җәлил — герой шагыйрь».
«Бердәм булганда, без — җиңелмәс көч».

## 94 нче дәрес

**1.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, әйтергә өйрәнегез, дөрес тәрҗемәсен табыгыз.

Очучы, җаваплы, куркыныч, дошман, данлыклы, дәһшәтле, очышлар, булдыра ала, күзгә-күз, сугышчан юл, батырлык.

**2.** Сүзләрнең логик парларын табыгыз.

| | |
|---|---|
| очучы | кеше |
| куркыныч | солдат |
| җаваплы | юл |
| дәһшәтле | дошман |
| сугышчан | кызлар |
| батыр | сугыш |

**3.** Тамырдаш (однокоренные) сүзләрне билгеләгез.

Куркыныч, җавап, сугыш, очкан, сугышчылар, сугышчан, курыкты, җавапсыз, очучы.

**4.** Җөмләләрне укыгыз, сыйфат фигыльләрне билгеләгез.

1. Бу — беренче мәртәбә дошман өстенә очкан төн. 2. Ул — дошманны бик күп тапкыр бомбага тоткан самолёт. 3. Генерал каршында басып торучы кечкенә кызга карады. 4. Төнлә очкан самолётларга җиңел булмый.

**5.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез. Тәрҗемәдәге аерманы аңлатыгыз.

1. Полк Грозный шәһәре янында. Грозный шәһәре янындагы полк.
2. Кыз генерал каршында. Генерал каршындагы кыз.
3. Бруни шәһәре янында тәмамлый. Берлин шәһәре янындагы Бруни шәһәрендә тәмамлый.

**6.** Җөмләләрне укыгыз. Һәр яңа өстәлгән җөмләгә сорау куегыз, җөмлә кисәкләрен билгеләгез.

Юл тәмам була.
Сугышчан юл тәмам була.
Сугышчан юл Бруни шәһәрендә тәмам була.
Сугышчан юл Берлин шәһәре янындагы Бруни шәһәрендә тәмам була.
Мәгубә Сыртланованың сугышчан юлы Берлин шәһәре янындагы Бруни шәһәрендә тәмам була.

**7.** 1 нче күнегүдәге сүзләрнең тәрҗемәсен өйрәнеп килегез, бу сүзләр белән җөмләләр төзегез.

## 95–97 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне һәм сүзтезмәләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес әйтергә өйрәнегез, тәрҗемәсен сүзлектән табыгыз.

Хезмәт итә, җаваплы, куркыныч, данлыклы, сынап карый, төнлә, тәмәке уты, кыю, дошман, дәһшәтле, куркусыз, сугышчан, ераклыкта, тәмам була.

**2.** Үрнәк буенча дәвам итегез.

Үрнәк: зур — зуррак.

Авыр, куркыныч, җаваплы, данлыклы, кыю, дәһшәтле, күп, куркак, акыллы.

**3.** Ике баганадагы сүзләрдән сүзтезмәләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| дәһшәтле | | очучы |
| сугышчан | | урын |
| җаваплы | ? | очыш |
| төнге | | полк |
| данлыклы | | сугыш |
| кыю | | юл |

**4.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне һәм сүзтезмәләрне куеп, җөмләләрне язып бетерегез.

1. Ул санитар эскадрильяда ... . 2. Ул ... турында укый. 3. Ул вакытта самолётлар ... очалар. 4. Кызны Тамань полкына ... . 5. Дошманны Моздок янында ... тоталар. 6. Аларның сугышчан юлы Берлинда ... .

Сүзләр: төнлә, җибәрәләр, бомбага, хезмәт итә, тәмамлана, очучы хатын-кызлар.

**5.** Язучы Ләбибә Ихсанова Мәгубә Сыртланова турында «Лачын кыз» исемле хикәя язган. Шуннан китерелгән өзекне укыгыз. Мондый батырлар сездә нинди хисләр (чувства) уята?



Очучы Мәгубә Сыртланова санитар эскадрильяда хезмәт итә. Аның сугышның зуррак, җаваплырак, куркынычрак җирендә буласы килә. Шундый көннәрнең берсендә ул фронт газеталарыннан данлыклы Тамань полкының очучы хатын-кызлары турында укый. Үзен шул Тамань полкына җибәрүләрен сорап, генерал янына бара. Каршысында басып торган кечкенә генә яшь кызга генерал сынап карап тора.

— Булдыра алырсызмы соң? Анда эшләү бик кыен булыр. Самолётлар төнлә очалар бит. Очучылар машиналарын тәмәке утына карап кына утырталар, — ди аңа генерал.

Әмма кыз кыю җавап бирә:

— Беләм, иптәш генерал. Ләкин анда минем кебек үк кешеләр оча.

Генерал риза була. Мәгубә Сыртланованы Грозный шәһәре янындагы Кызыл Байраклы Тамань полкына җибәрәләр.

1942 нче елның 3 нче декабре — беренче тапкыр дошман өстенә очкан төн — аның хәтерендә бик нык саклана. Бу төнне Моздоктагы дошманны бомбага тотарга баралар алар. Дүрт тапкыр очарга туры килә. Күнекмәгән шартларда эшләү бик ардыра, баш авырта. Астан дошман зениткалары ата.

Куркусыз татар кызы Мәгубә Сыртланованың сугышчан юлында бик күп була мондый очышлар. Ул Кырымда да, Польшада да, Көнчыгыш

Пруссиядә дә, Берлин янында да дошманны утка тота. 782 төнге очыш, 782 тапкыр үлем белән күзгә-күз очраша ул.

Лачын кызның сугышчан юлы Берлиннан 80 километр ераклыкта Бруни шәһәре янында тәмамлана. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исемен алган Мәгубә Сыртланова сугышчан самолёты белән Мәскәүдә Җиңү парадында катнаша.

**кыю** — смелый; смело **утка тоту** — бомбардировать

**6.** Хикәядән бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз.

1. Мәгубә Сыртланованың хыялы (мечта).
2. Кызның генерал белән сөйләшүе.
3. Очучы кызның беренче сугышчан очышы.
4. Мәгубә Сыртланованың Җиңү парадында катнашуы.

**7.** Тексттан үткән заман сыйфат фигыльләрне табыгыз, үрнәк буенча үзгәртеп языгыз.

Үрнәк: эшләгән кеше — эшләүче бала — эшли торган апа — эшләр эш — эшләячәк эш — эшлисе эш.

**8.** Тексттан Мәгубә Сыртланованың тышкы кыяфәтен, характерын сурәтләгән җөмләләрне табып укыгыз.

**9.** Җөмләләрнең тәрҗемәсен табыгыз.

1. Таких вылетов у бесстрашной Магубы Сыртлановой было много. 2. Магуба Сыртланова служила в санитарной эскадрилье. 3. Она идёт к генералу с просьбой отправить её в Таманский полк. 4. Герой Советского Союза Магуба Сыртланова участвовала в Параде Победы в Москве.

**10.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Мәгубә Сыртланованың көрәшнең җаваплырак җирендә буласы килә, чөнки ... . 2. Аның очучы буласы килә, шуңа күрә ... . 3. Кыен буласын беләм, ләкин ... . 4. 1942 нче елның 3 нче декабре истә калды, чөнки ... . 5. Дүрт тапкыр ... . 6. Дошманны бомбага тотарга баралар, ә анда ... .

**11.** Өзекнең үзегезгә ошаган өлешен укыгыз. Эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**12.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Бу хикәядә нинди сугыш турында сүз бара? Ул кайчан булган?
2. Мәгубә Сыртланова ничә төнге очыш ясый?
3. Лачын кыз үлем белән ничә тапкыр күзгә-күз очраша?
4. Ләбибә Ихсанова ни өчен хикәясен «Лачын кыз» дип атаган?

**13.** «Лачын кыз» хикәясеннән өзекне сәнгатьле укырга өйрәнегез.

**14.** Мәгубә Сыртланованың батырлыгы турында сөйләргә әзерләнегез.

## 98 нче дәрес

**1.** Сүзләрне һәм сүзтезмәләрне тәрҗемә итегез, дөрес укырга өйрәнегез.

Каршы, күтәрергә, ату, җимерек нигез, калкулык, мәйдан, егылу, шуыша, чокыр, тәгәрәде, яшеренгән, хәл җыйды, ыргытты, котырынып, сирәгәйде, хәрәкәтсез, үкерә, явыз, тибә.

**2.** Сүзләрнең синоним парларын табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| явыз | ? | тәмамланган |
| куркыныч | | йорт |
| өй | | коточкыч |
| аварга | | егылырга |
| беткән | | усал |

**3.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| тоткарлый | ? | сомневается |
| икеләнә | | вздрагивание |
| тетрәү | | ползёт |
| шуыша | | задерживает |

**4.** Кушма җөмлә төрләрен атагыз, җөмләләрне тәрҗемә итегез.

1. Сугышчылар алга ыргылдылар, ләкин аларның да сафлары сирәгәя барды. 2. Немец пулемёты баш күтәрергә ирек бирми атса да, сугышчы аның кайдан атуын күреп алды. 3. Солдат чокырдан чыкты да тагын алга шуыша башлады, аны бөтен батальон күреп алды. 4. Амбразурага берничә адым калгач, сугышчы бик азга гына туктады.

5. Солдат бөтен көче белән амбразурага граната томырды, ләкин атуны туктата алмады. 6. Батальон тынып калды, чөнки сержантның теләге һәркемгә дә ачык иде.

**5.** Бирелгән гади җөмләләрдән кушма җөмләләр төзеп языгыз.

1. Немец пулемёты баш күтәрергә ирек бирмичә ата. Газинур аны күреп алды.
2. Икенче сугышчы һаман шуыша. Ул Газинурга караганда ераграк иде.
3. Амбразурадан көчле ут ыргылды. Кар өстенә яңадан яралылар ауды.
4. Сугышчылар мәйданга ташландылар. Газинур берничә адым йөгерергә өлгерде.
5. Мәйданда кулларына граната тоткан сугышчылар хәрәкәтсез яталар. Берсе һаман алга шуыша.

**6.** 2, 3 нче күнегүләрдәге фигыльләрне тиешле формаларга куеп, җөмләләрне язып бетерегез.

1. Солдат бөтен көче белән гранатаны амбразурага ... . 2. Һәр секунд безнең җиңүебезне ..., уннарча сугышчының гомерен алып китә. 3. Ике солдат, кулларына граната тотып, дзотка таба ... иде. 4. Ильченко кар өстенә ... . 5. Сугышчыларның йөрәкләре тагы да көчлерәк ... тотынды.

! **7.** Фразеологизмнарны исегездә калдырыгыз!

**ирек бирмәү** — не давать возможности

**яшен тизлеге белән** — с быстротой молнии

**алтын кеше** — золотой человек

## 99–102 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз, бер-берегезгә сөйләгез.

Бөек Ватан сугышы геройлары арасында Александр Матросов исеме сезгә билгеле. 1943 нче елда Псков өлкәсе Чернушка авылы янында барган сугышта ул үз күкрәге белән немец дзотының амбразурасын каплый. Шундый ук батырлыкны Бөек Ватан сугышы вакытында 400 гә якын совет солдаты кабатлый. Алар арасында татар егете, Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинның да исеме бар.

**2.** Язучы Г. Әпсәләмовның «Газинур» романыннан өзекне укыгыз.

### Батырлык

Немец пулемёты баш күтәрергә ирек бирмичә атса да, Газинур аның кайдан атуын күреп алды. Каршы якта җимерек өй нигезе күренә. Ә өй астында, таш подвалда — дзот.

— Әнә кайда яшеренгән, кабахәт! — дип уйлап алды Газинур. Бу безнекеләр өчен куркыныч пулемёт иде. Дзот калкулыкта, ә аста — тип-тигез мәйдан. Менә мәйданга урам ягыннан капитан Бушуевның ротасы килеп керде. Шунда ук Газинур алдан йөгереп килүче сугышчыларның егылуларын күрде. Берәү, икәү, өчәү...

Газинур, башын күтәреп, атып торган дошман пулемётына карады һәм дзотка таба шуыша башлады.

Менә ул сулга борылды, бомба чокырына тәгәрәде. Ләкин ара ерак иде, Газинур тирә-ягына каранды. Тагын ике солдат, кулларына граната тотып, дзотка таба шуыша иде. Менә берсенең каскасы очып китте. Сугышчы канлы башын күтәрде, карга капланды. Икенчесе һаман шуыша иде, ләкин ул Газинурга караганда да дзотка ераграк.

Газинур чокырдан чыкты да тагын алга шуыша башлады. Хәзер инде аны бөтен батальон күреп алды.

Фашист пулемёты үкерүдән туктамады. Газинур, шуыша-шуыша, дзотка якын ук килде. Бер секунд хәл җыеп торды. Аннары бераз күтәрелә төште, бөтен көче белән амбразурага граната ыргытты.

Пулемёт тынды. Сугышчылар, команда көтмичә үк, урыннарыннан сикереп тордылар, мәйданга ташландылар. Ләкин амбразурадан яңадан көчле ут ыргылды. Кар өстенә яңадан яралылар ауды.

Капитан Бушуев бар көченә:

— Ятыгыз! — дип кычкырды.

Сугышчылар икенче тапкыр инде ачык мәйданда кар өстенә ятарга мәҗбүр булдылар.

Сержант Газинур Гафиятуллин барысыннан алда снаряд чокырында иде. Газинур як-ягына каранды. Мәйданның төрле урыннарында кулларына граната тоткан сугышчылар хәрәкәтсез яталар. Тик берсе һаман алга шуыша. Аның әйләнә-тирәсендә пулялар аеруча сызгыра, кар оча. Менә ул бөтенләй туктады. Аннары башын күтәрде. Каскасы төшеп калган. Газинур аны танып алды: бу Ильченко иде.



Ильченко кар өстенә капланды. Газинурның йөрәге тагын да

көчлерәк тибәргә тотынды. «Шундый алтын кешене...» Ул уйлап бетермәде, кулы белән гранатасына үрелде. Бер генә гранатасы да калмаган! Автоматының да патроннары беткән. Нишләргә?! Газинур дошман пулемётына өзгәләрдәй булып карый.

— Юк, барыбер туктата алмассың, явыз! Барыбер муеныңны борам!

Ләкин буш кул белән ни эшли ала соң ул? Газинур кулын күкрәгенә күтәрде. Атылып чыгардай типкән йөрәге янында — гимнастёрка кесәсендә партбилеты һәм... Александр Матросовның рәсеме...

— Саша... — диде ул кинәт әкрен генә.

Газинур яткан җиреннән сикереп торды һәм дзотка таба йөгерә башлады.

Батальон тынып калды. Сержантның ни эшләргә теләве хәзер һәркемгә ачык иде. Ничәмә-ничә тапкыр үлем белән очрашкан сугышчылар таң калды, йөрәкләре тибүдән туктагандай булды. Аларның күз алдында гади бер солдат үлем белән үлемсезлек арасын үтә... Легендалар итеп сөйләрлек, җырларда җырларлык батырлык эшли иде.

Фашист пулемёты бертуктаусыз атуын дәвам итә. Һәр секунд безнең җиңүебезне тоткарлый, уннарча сугышчының гомерен алып китә.

Газинурның карары нык. Аның күңелендә курку да, тетрәү дә, икеләнү дә юк.

— Туган ил өчен! — дип кычкырды ул һәм үкереп торган фашист пулемёты авызына күкрәге белән капланды...

Батальон, дошманны сытып, алга омтылды.

**җимерек** — разрушенный
**нигез** — фундамент
**икеләнү** — сомнение
**кабахәт** — мерзавец, подлец
**калкулык** — холм, возвышенность
**чокыр** — яма, рытвина
**каранды** — огляделся (вокруг себя)
**ыргылды** — здесь: рванулся
**бөтен** — весь
**шуышырга** — ползать
**ату** — стрельба
**мәйдан** — площадь, плац
**сулга** — налево
**үкерү** — рёв
**үрелде** — потянулся

**3.** Бу сүзләрне дөрес әйтәсезме? Транскрипция билгеләре белән языгыз.

Ату, чокыр, таратылган, ераграк, егылуларын, яраланган, гомер, сугышчылар, йөрәк, хәрәкәтсез, үлемсезлек, сузылды.

**4.** План пунктларын әсәрнең эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Газинур куркыныч пулемётны юк итәргә тели.
2. Сержант Гафиятуллинның легендар батырлыгы.
3. Дошман пулемёты.
4. Сугышчылар көчле ут астында.

**5.** Бирелгән сүзтезмәләр кергән җөмләләрне табып укыгыз, яңа җөмләләр төзегез.

Җимерек өй, куркыныч пулемёт, капитан Бушуев, хәрәкәтсез яталар, алтын кеше, сикереп торды, үлем белән үлемсезлек, ак болытлар.

**6.** Сүзләрне дөрес язасызмы? Тексттан бу сүзләрне табып, үзегезне тикшерегез.

Ниг...з, бүг...н, йөгер...рг..., яшер...нг...н, күтәр...л..., м...йдан, г...үд..., гом...р, үлемсезл...к.

**7.** Тексттан фразеологизмнар кергән җөмләләрне табып укыгыз, тәрҗемә итегез. Үзегез яңа җөмләләр уйлагыз.

**8.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Сугышчылар, дзотның атуын туктату өчен, ... .
2. Пулемёт атудан туктагач, ... .
3. Сугышчы гранатаны дзотка атты, ләкин ... .
4. Җиңүне якынайту өчен, ... .
5. Сугышчылар сикереп тордылар, алга ташландылар, чөнки ... .

**9.** Хаталы җөмләләрне табыгыз.

1. Дзот тип-тигез мәйданга урнашкан иде.
2. Газинурның гранатасы да калмаган.
3. Газинурдан алда дзотка Ильченко килеп җитте.
4. Амбразурага килеп җиткәч, Газинур туктап калды.

**10.** Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзеп карагыз.

1. Якта, күренә, өй, җимерек, каршы, нигезе.
2. Газинур, адым, өлгерде, берничә, атларга.
3. Төрле, яталар, мәйданның, сугышчылар, хәрәкәтсез, урыннарында.
4. Аның, янында, атылып чыгардай, типкән, йөрәге, партбилеты, рәсеме, Александр Матросов, һәм.
5. Күктә, иде, биектә-биектә, аяз, бөдрә, болытлар, ак, йөзә.
6. Үкереп торган, Газинур, пулемёты, күкрәге, капланды, белән, фашист, авызына.

**11.** Нокталар урынына кирәкле фигыльләрне куеп языгыз.

1. Газинур пулемётның кайдан атуын ... .
2. Шунда ул сугышчыларның егылуын ... .

3. Аларның күз алдында гади бер солдат легендар батырлык ... .
4. Язгы аяз күктә бөдрә ак болытлар ... .
5. Газинур үкереп торган фашист пулемёты авызына күкрәге белән ... .

**12.** Текстка сораулар төзеп языгыз, ул сораулар ярдәмендә бер-берегез белән сөйләшегез.

**13.** Әсәрнең эчтәлеген кыскача сөйләргә өйрәнегез.

**14.** Тексттан Газинурның батырлыгын чагылдырган җөмләләрне табып укыгыз. Аларга сораулар куегыз.

**15.** Газинурны бу батырлыкка нәрсә этәрә? Гомеренең соңгы минутлары турындагы өлешне кабат укыгыз. Сөйләргә өйрәнегез.

**16.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Әсәрдәге вакыйгалар кайчан бара?
2. Пулемёт кайдан ата?
3. Ни өчен солдатларга дзотны юк итү авыр?
4. Газинур башта пулемётны нинди юл белән юк итәргә тели?
5. Башка солдатлар нинди фикердә була?
6. Ильченконың үлеме Газинурга ничек тәэсир итә?
7. Ни өчен Газинур дзотны күкрәге белән капларга мәҗбүр була?

**17.** Төркемнәрдә сөйләшегез. «Батыр егет — ил күрке» мәкален ничек аңлыйсыз? Батырлык турында тагын нинди мәкальләр беләсез?

**18.** Бөек Ватан сугышы турында рус язучыларының нинди әсәрләрен беләсез? Аларның төп геройлары кемнәр? Сөйләргә әзерләнегез.

**19.** Спросите у друга (подруги):

— знает ли он (она) героев Великой Отечественной войны;
— любит ли он (она) читать книги про подвиги;
— понравился ли ему (ей) отрывок из романа «Газинур».

Г. Гафиятуллин турында күбрәк белегез

# А

**абзар** — хлев
**аваз ияртемнәре** —
звукоподражательные слова
**авылдаш** — односельчанин
**авыр** — тяжёлый, трудный
**авыру** — больной; болезнь
**агу** — яд
**агуланырга** — отравиться, травиться
**агулы** — ядовитый
**агыз** — лей, пролей
**адым** — шаг
**аергыч** — определение
**аеруча** — особенно
**аерылып** тора — выделяется
**аерым** — отдельный
**азаплана** — мучается
**азат** — свободный
**аккош** — лебедь
**акрынлап** — медленно, тихонько
**аксыл** — беловатый, белёсый
**аксыл-көрән** — бежевый
**актар** — рой, вороши
**акыллы** — умный
**алайса** — если так
**алан** — поляна
**алдакчы** — обманщик, врун
**алдаша** — обманывает, врёт
**алка** — серьга
**алмаш** — смена
**алмашлык** — местоимение
**аннан** соң — после
**ант** — клятва
**аныклагыч** — поясняющее,
уточняющее слово
**аныклык** — ясность, конкретность
**аңгыра** — глупый
**аңла** — пойми
**аптыра** — растеряйся
**аптыраш** — растерянность
**аралаш** — общайся
**аралашу** — общение
**арасында** — среди, между
**аркылы** — через, поперёк
**артык** — слишком, более
**аръяк** — та сторона, заречье
**ары** — дальше, больше
**арый** — устаёт
**арыш** — рожь
**ас** — низ
**асыл** — драгоценный, благородный
**атаклы** — знаменитый
**атау җөмлә** — назывное предложение
**атказанган** — заслуженный
**атла** — шагай
**атна** — неделя
**аударырга** — повалить, опрокинуть
**ауна** — валяйся
**ачу** — гнев, зло
**ачы** — горький, кислый
**ачыш** — открытие
**ашык** — торопись
**ашык-пошык** — наспех, торопливо
**аяз** — ясный

# Ә

**әгәр** — если
**әгъза** — член
**әдәби** — литературный
**әдәбият** — литература
**әдәп** — вежливость, приличие
**әдип** — писатель, литератор
**әзер** — готовый
**әйбер** — вещь, предмет
**әйтем** — поговорка
**әкәмәт** — чудный
**әкиятче** — сказочник
**әкрен** — медленно; медленный
**әләкләшә** — ябедничает, жалуется
**әлбәттә** — конечно
**әллә** — или, либо
**әңгәмәдәш** — собеседник
**әрҗә** — ящик
**әсәр** — произведение
**әһәмият бирү** — обращать внимание
**әһәмиятле** — важный, существенный
**әшәке** — плохой

# Б

**бай** — богатый, богач
**бака** — лягушка
**балан** — калина
**балачак** — детство
**балкый** — сияет, светится

**барыбер** — всё равно
**барысы** — все, всего
**бастыр** — издай, печатай
**басым** — ударение
**баткак** — грязь, слякоть
**батырлык** — геройство
**башваткыч** — головоломка
**башка** — другой
**башкача** — по-другому
**башлангыч** — начальный
**башта** — сначала, сперва
**бәгърем** — милый мой (обращение)
**бәйлек** — послелог
**бәйлек** сүз — послеложное слово
**бәла** — беда, несчастье
**бәлки** — возможно, вероятно
**бәргәләнә** — мечется
**бәс** — иней, изморозь
**бәхәс** — спор
**бәхет** — счастье
**бәя** — цена
**бераз** — немного
**бервакыт** — однажды
**бергә**, бергәләп — вместе
**бердәнбер** — единственный
**беркем** — никто
**бернинди** — никакой
**берничә** — несколько
**берьюлы** — сразу, одновременно
**билгелә** — отметь
**билгеле** — известный
**биюче** — танцор
**бияләй** — варежки, рукавицы
**бозылырга** — портиться, повреждаться
**болга** — маши
**бораулаучы** — бурильщик
**боргалана-сыргалана** — крутится-вертится, извивается
**борчыла** — беспокоится, тревожится
**борыл** — повернись
**борынгы** — древний
**бөек** — великий
**Бөек Ватан сугышы** — Великая Отечественная война
**бөҗәк** — насекомое
**бөртек** — крупинка, зерно, капля
**бөтен** — целый, весь
**бөтенләй** — полностью
**бугай** — кажется, как будто
**буена** — вдоль, по
**буйлап, буенча** — по
**булыш** — помогай
**буразна** — борозда
**бурыч** — долг
**бута** — путай, мешай
**буталчык** — запутанный
**буш** — пусто
**буын** — поколение
**бүлдермә** — не прерывай
**бүлек** — глава
**бүрәнә** — бревно
**бүрек** — шапка
**бүтән** — другой

# В

**вазифа** — обязанность, долг
**вак** — мелко, мелкий
**вакыйга** — событие, происшествие
**вакыт** — время, пора, период, срок, **момент**
**васыять** — завещание
**ват** — разбей, сломай, расколи
**ватанпәрвәр** — патриот
**ватык** — разбитый, сломанный
**вәгъдә** — обещание, обет
**вәзир** — визирь, министр двора
**вөҗдан** — совесть

# Г

**гадәт** — привычка, навык, обычай, нрав
**гадел** — честный, справедливый
**гади** — простой
**гаеп** — вина
**гаҗәп** — удивительно
**гаҗәпләнә** — удивляйся
**газап** — мучение
**галәм** — вселенная
**галим** — учёный
**гарьләнергә** — обижаться, оскорбляться
**гаскәр** — войско
**гасыр** — век
**гауга** — раздор, шум, гам
**гашыйк** — влюблённый, любящий
**гәүдә** — туловище, тело

**гәүһәр** — жемчуг
**гомер** — жизнь
**гореф-гадәт** — обычай, традиция
**горур** — гордый
**горурлан** — гордись
**гөлҗимеш** — шиповник
**гөнаһ** — грех
**гөрләвек** — ручеёк
**гүзәл** — прекрасный
**гыйбрәт ал** — извлеки урок
**гыйлем** — знание, наука

# Д

**да, дә** — тоже, и
**дан** — слава
**данлыклы** — знаменитый, прославленный
**даһи** — гениальный
**дәва** — лекарство
**дәлилләү** — докажи
**дәрәҗә** — степень, звание
**дәррәү** — вместе, дружно
**дәрт** — страсть
**дәүләт** — государство
**дәһшәтле** — страшный, зловещий
**дерелди** — дрожит
**димәк** — следовательно, таким образом
**дин** — религия
**диңгез** — море
**дистә** — десяток
**дөмбәсли** — дубасит
**дөнья** — мир
**дым** — влага

# Е

**егет** — парень
**елан** — змея
**елга** — река
**елмай** — улыбайся
**ерак** — далеко
**ераклаша** — отдаляется
**ерта** — рвёт
**еш** — часто

# Ж

**җай** — удобный момент, возможность
**җан** — душа
**җәза** — наказание
**җәмгыять** — общество
**җәяүле** — пеший, пешеход
**җен** — чёрт
**җеназа** — отпевание, панихида
**җилкә** — плечо
**җимерелә** — разваливается
**җиңелчә** — слегка, налегке
**җирән** — рыжий
**җитәкче** — руководитель
**җитәрлек** — достаточный
**җитди** — серьёзный
**җитез** — ловкий, шустрый
**җитеш** — успевай
**җиһан** — вселенная
**җуйма** — не теряй
**җыентык** — сборник
**җый** — собирай, убирай

# З

**зарарлы** — вредный
**зарарлый** — вредит
**зарлан** — жалуйся
**затлы** — знатный; дорогой
**зиндан** — тюрьма
**зыян** — вред
**зыянлы** — вредный

# И

**игәргә** — выращивать
**игезәк** — близнец
**иген** — хлеб, хлеба
**игълан** — объявление
**игътибар** — внимание
**иҗат** — творчество
**иҗек** — слог
**иҗтимагый** — общественный
**изге** — святой, благочестивый
**икътисад** — экономика
**илт** — отнеси
**имгәтергә** — калечить, ушибить
**имеш** — будто бы, мол, дескать

**иминлек** — благополучие
**имтихан** — экзамен
**инеш** — источник, родник
**иң** — самый
**иңбаш** — плечо
**иптәш** — товарищ
**ирек** — свобода, воля
**иреш** — добейся, достигни
**иркәлә** — ласкай
**иркен** — просторно
**иртән** — утром
**исән** — живой, здоровый
**исәнләш** — здоровайся
**исәнлек** — здоровье, целость, невредимость
**исемлек** — список
**иске** — старый
**искечә** — по-старому
**искиткеч** — изумительный
**исни** — нюхает
**истә** калдыр — запомни
**ихтирам** — уважение
**ичмаса** — хотя бы
**ишек** — дверь
**ишек** төбе — у порога
**ишет** — услышь
**ия** — подлежащее
**ияләш** — привыкай
**иярүче** — подчинительный

# Й

**йодрык** — кулак
**йокла** — спи
**йокы** — сон
**йолдыз** — звезда
**йомшак** — мягко, мягкий
**йомыш** — дело, услуга
**йон** — шерсть
**йонлач** — мохнатый, волосатый
**йөгер** — беги
**йөз** I — лицо
**йөз** II — сто
**йөз** III — плыви
**йөзек** — перстень
**йөрәк** — сердце
**йөреш** — ход
**йөткер** — кашляй

# К

**кабатла** — повтори
**кабер** — могила
**кабилә** — племя
**кабырга** — ребро
**кагыйдә** — правило
**кадәр** — до
**кадер** — цена, достоинство, уважение
**казылма** — ископаемый
**кайбер** — некоторый
**кайвакыт** — иногда
**кайгы** — горе
**кайгырт** — заботься
**кайнаган** — кипячёный
**кайнар** — горячий
**кайсы** — который
**кайчак** — иногда
**кал** — останься
**калкыта** — приподнимает
**калтыра** — трясись
**калфак** — калфак (женский головной убор)
**калын** — густой; толстый
**калышырга** — отставать
**камыр** — тесто
**кан** — кровь
**канәгать** — довольный
**каплый** — укрывает, покрывает
**карак** — вор
**караңгы** — тёмный; тьма
**кардәш** — родственник
**карчыга** — ястреб
**карчык** — старуха
**каршы** — противоположный, напротив
**каурый** — перо
**каушый** — теряется, смущается
**кач** — прячься
**качкын** — беглец
**кәгазь** — бумага
**кәеф** — настроение
**кебек** — как
**кемдер** — кто-то
**кер** — бельё
**кереш** — введение
**кереш** сүз — вводное слово
**керпе** — ёж
**кечкенә** — маленький, небольшой
**кешелек** — человечество

**кибеп баручы** — засыхающий
**кигез** — одень
**киез** итек — валенки
**киләсе, киләчәк** — будущий
**килен** — невестка, сноха
**килеш** — падеж
**килешү** — соглашение, сговор
**кимерә** — грызёт
**кими** — уменьшается, убавляется
**кимчелек** — недостаток
**кинәт** — внезапно, вдруг
**киңәш** — совет
**киңәш** ит — советуй
**кире** — обратно
**киресенчә** — наоборот
**кис** — режь
**кисәкчә** — частица
**кисәтү** — предупреждение
**кит аннан** — не может быть; уйди оттуда
**кичә** — вчера; вечеринка
**кичереш** — переживание
**кичке** — вечерний
**кишер** — морковь
**коелып төште** — растерялся, рассыпался
**коймак** — блин
**койрык** — хвост
**комачаулый** — мешает, тормозит
**кондыз** — бобр
**корсак** — живот
**коры** — сухой
**коткару** — спасение
**котла** — поздравь
**коточкыч** — страшный
**кочаклый** — обнимает
**көй** — мелодия, мотив
**көйгән** — засохший
**көймә** — лодка
**көл** I — смейся
**көл** II — зола
**көнбатыш** — запад
**көндезге** — дневной
**көнкүреш** — быт; бытовой
**көнләшергә** — ревновать, завидовать
**көнозын** — целый день
**көнчыгыш** — восток
**көньяк** — юг
**көрәш** — борьба
**көтү** — стадо
**көчәй** — усиливайся
**куак** — куст
**куан** — радуйся
**куана** — радуется
**куаныч** — радость, восторг
**куе** — густо; густой
**кул арбасы** — тележка
**куллан** — используй
**култык** таягы — костыль
**кулъязма** — рукопись
**курка** — боится
**куркусыз** — бесстрашный
**куркыныч** — страшный
**куркыта** — пугает
**кушамат** — кличка, прозвище
**куыш** — дупло
**куышлы** — догонялки, салочки
**куярга** — положить
**күзлек** — очки
**күк** — небо; голубой
**күкрәк** — грудь
**күкрәк кесәсе** — нагрудный карман
**күл** — озеро
**күн** — кожа
**күнегү** — упражнение
**күнекмәгән** — непривычный
**күңел ач** — развлекайся
**күңелле** — весёлый, весело
**күпмилләтле** — многонациональный
**күптән** — давно
**күпчелек** — большинство
**күрә** — видит
**күргәзмә** — выставка
**күренекле** — видный
**күренеш** — явление
**күрешергә** — здороваться, встречаться
**күрше** — сосед
**күч** — пересядь, перейди
**күчер** — спиши; перемести
**кызган** — жалей
**кызганычка каршы** — к сожалению
**кызыксын** — интересуйся
**кыйбат** — дорого; дорогой
**кыйммәтле** — дорогой, дорогостоящий
**кыйна** — бей
**кылана** — кокетничает, изображает
**кыланучы** — кокетничающий
**кыланыш** — поступок, выходка
**кыргый** — дикий

**кырыс** — суровый, строгий, резкий
**кыстыр** — прищеми, вложи
**кычкыра** — кричит
**кычыткан** — крапива
**кыю** — смелый, отважный
**кыя** — скала
**кыяр-кыймас** — застенчиво
**кыяфәт** — внешний вид

# Л

**лаек була** — удостоен
**лаеклы** — заслуженный
**лалә** — тюльпан
**лачын** — сокол
**ләкин** — но

# М

**мажара** — приключение
**мажаралы** — приключенческий
**максат** — цель
**мактан** — хвались
**мактанчык** — хвастун
**мактаулы** — похвальный
**мал-мөлкәт** — состояние, богатство
**маңгай** — лоб
**матдә** — вещество, материя
**матурлык** — красота
**махсус** — специальный, особый
**мәгарә** — грот, пещера
**мәгълүмат** — информация
**мәгънә** — смысл
**мәдәни** — культурный
**мәдәният** — культура
**мәҗбүри** — обязательный
**мәйдан** — площадь
**мәкалә** — статья
**мәкаль** — пословица
**мәңге** — вечно; вечный
**мәртәбә** — раз
**мәртәбәле** — авторитетный
**мәрхәмәтле** — милосердный
**мәсьәлә** — задача
**мәхәббәт** — любовь
**мәчет** — мечеть
**мендәр** — подушка
**мескен** — несчастный, жалкий
**микән** — ли, то ли
**миләш** — рябина
**милли** — национальный
**мирас** — наследие
**могҗиза** — чудо
**моны** — это
**моң** — мелодия
**моңлы** — мелодичный
**мөгаен** — наверное, по-видимому
**мөгамәлә** — обращение, отношение
**мөмкин** — можно
**мөнәсәбәт** — отношение
**мөстәкыйль** — самостоятельный
**мөхәррир** — редактор
**мөһим** — важно; важный
**муенса** — бусы, ожерелье
**мул** — щедрый, изобильный
**мүк** — мох
**мыек** — усы

# Н

**надан** — необразованный, безграмотный
**намус** — честь, совесть
**начар** — плохо; плохой
**нәкъ** — именно, точь-в-точь
**нәни** — маленький
**нәсел** — род
**нәшер** итә — издаёт
**нәшрият** — издательство
**нигез** — основа; устои; отчий дом
**нигез салучы** — основоположник
**ниһаять** — наконец
**нур** — луч
**нур сип** — излучай
**ныгыт** — укрепи, закрепи

# О

**оекбаш** — носок, носки
**озак** — долго; долгий
**озат** — проводи
**олыгая** — стареет
**оныт** — забудь
**онытылмаслык** — незабываемый
**орлык** — семя, семена, зерно
**остаз** — наставник

**охшаш** — похож
**оч** — конец, кончик
**очраш** — встреться, встречайся
**очсыз** — дёшево; дешёвый
**очучы** — лётчик
**ошый** — нравится
**оя** — гнездо
**оял** — стыдись
**оялчан** — застенчивый, совестливый
**оят** — стыд

# Ө

**өелешергә** — сгрудиться, собраться в кучу
**өем** — куча
**өз** — рви
**өзгәлән** — разрывайся
**өзек** — отрывок
**өй** — складывай
**өлгер** — ловкий, проворный
**өлгерергә** — успевать, поспевать
**өлешчә** — частично
**өлкә** — область
**өлкән** — взрослый, старший
**өмет** — надежда
**өр-яңа** — совершенно новый
**өстәмә** — дополнительный
**өянке** — плакучая ива

# П

**патша** — царь
**пәрәмәч** — перемяч
**пәрдә** — занавес
**песнәк** — синица
**пешер** — вари, пеки
**почмак** — угол
**поши** — лось
**пөхтә** — опрятный, чистый
**пычрак** — грязный; грязь
**пыяла** — стекло

# Р

**расла** — подтверди, докажи
**рәис** — председатель
**рәнҗет** — обижай
**рәссам** — художник
**рәхәт** — приятно, хорошо
**риза** — согласен, согласна
**ризык** — пища
**рөхсәт** — разрешение
**рух** — дух, душа
**рухи** — духовный

# С

**сабыр** — терпеливый
**сагын** — скучай, тоскуй
**сагыну** — тоска
**сагыш** — тоска
**саен** — каждый; каждый раз, когда
**сайла** — выбирай
**сайланма** — избранное
**сайрый** — поёт, щебечет
**сакал** — борода
**сакла** — береги
**сакчы** — сторож, охранник
**санаулы** — считанный
**сансыз** — непослушный
**саңгырау** — глухой
**саран** — скупой
**саулык** — здоровье
**саф күңелле** — искренний, честный, чистосердечный
**сәбәп** — причина
**сәер** — странный
**сәламәт** — здоровый
**сәләт** — способность, талант
**сәүдә** — торговля
**сәхнә** — сцена
**сәяхәт** — путешествие
**себерке** — метла, веник
**селкенергә** — шевелиться, раскачиваться
**сер** — секрет
**сердәш** — закадычный друг
**сиз** — чувствуй
**сизгер** — чуткий
**сикер** — прыгай
**симез** — тучный, полный, жирный
**сип** — поливай
**сирәк** — редко
**соклан** — восхищайся
**сокландыргыч** — восхитительный; изумительно

**солы** — овёс
**соң** — поздно; после того
**соңга кал** — опоздай
**сөекле** — любимый
**сөен** — радуйся
**сөенеч** — радость
**сөй** — люби
**сөйкемле** — симпатичный, обаятельный
**сөйләш** — разговаривай, поговори
**сөю** — любовь
**сөяк** — кость
**сугышчан** — боевой
**сугышчы** — воин, боец
**суз** — тяни
**сукыр** — слепой
**сул** — левый
**сулган** — увядший
**сулыш алу** — вдохнуть
**сумала** — смола
**сурәтлә** — опиши, изобрази
**сусыл** — сочный, водянистый
**суырып ала** — выдёргивает
**сүзендә тор** — держи слово
**сүндер** — туши, выключи
**сыек** — жидкий
**сызгыр** — свистни
**сызларга** — ныть, болеть
**сыйпый** — гладит
**сыйфат** — имя прилагательное
**сыйфат фигыль** — причастие
**сылу** — красивый, стройный
**сына** — ломается
**сынау** — испытание, экзамен
**сынашу** — мериться силами

# Т

**таба** — сковорода
**табигый** — природный, естественный
**табын** — накрытый стол
**табынырга** — преклоняться, поклоняться
**табыш** — находка
**табышмак** — загадка
**тавыш** — голос
**таҗ** — корона
**тайгак** — скользкий
**тал** — ива
**талаучы** — грабитель
**талпына** — пытается, стремится
**тамаша** — представление
**тамчы** — капля
**тамыр** — корень
**тантаналы** — торжественный
**танылган** — известный
**таныш** — знакомый
**таң калдыр** — удиви
**тапкыр** — раз
**тапшыр** — передай
**тапшыру** — передача
**тар** — узкий
**таратучы** — распространитель
**тарихи** — исторический
**тартма** — коробка
**тартыл** — потянись
**тартылырга** — тянуться
**тары** — просо
**тасма** — лента
**татлы** — сладкий
**тату** — дружный
**таш** — камень
**ташлан** — бросайся
**таяк** — палка
**тәбәнәк** — низкий
**тәвәккәл** — решительный
**тәҗрибә** — опыт
**тәкәббер** — упрямый; высокомерный
**тәкъдим** — предложение
**тәкъдим ит** — сделай предложение
**тәмамла** — заканчивай
**тәмамлык** — дополнение
**тәмәке** — табак
**тәмәке тарту** — курение
**тән** — тело
**тәңкә** — монета
**тәрбияле** — воспитанный
**тәртипле** — дисциплинированный
**тәүге** — первый
**тәхет** — трон
**тәэсир** — влияние, воздействие
**тезмә фигыль** — составной глагол
**тезүче** — сочинительный
**теге** — тот
**тегермән** — мельница
**текә** — крутой

**теләэ** — желай
**теләгәнчә** — вволю, сколько угодно
**теләк** — желание
**телдән** — устно
**телем** — кусок
**теркәгеч** — союз
**терлек** — скот
**тешлә** — кусай
**тигез** — ровно
**тиздән** — скоро
**тик яту** — бездельничать
**тиле** — глупый
**тимәскә** — не трогать
**тимер юл** — железная дорога
**тиңдәш кисәкләр** — однородные члены
**тип** — пинай
**тирән** — глубокий
**тирес** — навоз
**тирлә** — потей
**токым** — порода
**тол калу** — овдоветь
**тор** — вставай
**тормыш** — жизнь
**торна** — журавль
**тот** — держи, лови
**тоташ** — сплошной
**төбәк** — край, область, регион
**төгәл** — точно; точный
**төзә** — целься
**төзүче** — строитель
**төн** — ночь
**төнбоек** — кувшинка, водяная лилия
**төнлә** — ночью
**төньяк** — север
**төп** — основа
**төпчек** — младший ребёнок
**төрен** — кутайся
**төркем** — группа
**төрмә** — тюрьма
**төтен** — дым
**төчкер** — чихай
**төш I** — сон
**төш II** — слезай
**ту** — родись
**тугры** — верный
**тузан** — пыль
**тузганак** — одуванчик
**тукма** — бей, колоти
**тукта** — остановись
**тукталыш** — остановка
**туктат** — останови
**тупас** — грубый, невежливый
**туры** — прямо; прямой
**туры** килә — подходит
**турында** — о, про
**туфрак** — почва
**түгәрәк** — круглый
**түлә** — плати
**түр** — передний угол, гостиная
**түрдән** уз — проходи
**тыйнак** — скромный
**тын** — спокойный, тихий
**тынычлык** — мир, спокойствие
**тыңла** — слушай
**тырыш** — старательный

# У

**уен** — игра
**уз** — проходи
**уйчан** — задумчивый
**ула** — вой
**умыртка сөяге** — позвоночник
**уң** — правый
**уңайлы** — удобный
**уңайлый** — поправляет
**уңган** — деловой, умелый
**уңдырышлы** — плодородный
**уңыш** — урожай
**урнаш** — устраивайся
**урта** — середина; средний
**уртак** — общий, совместный
**уртаклашырга** — поделиться
**уртаклык** — общность, взаимность
**уртача** — средний; средне
**усал** — злой
**ут** — огонь
**утыргыч** — сиденье
**уфылдый** — охает, вздыхает
**уч** — ладонь
**учак** — костёр
**уян** — проснись
**уят** — разбуди

# Ү

**үги** — неродной, чужой
**үз** — свой
**үзара** — взаимно, меж собой
**үзгәреш** — перемена
**үзгәрт** — измени
**үзе** — сам, само, сама
**үзенеке** — свой
**үзенчәлекле** — своеобразный
**үзләренчә** — по-своему, как сами желают
**үзлегеннән** — произвольно
**үкен** — раскаивайся
**үкенеч** — раскаивание
**үкенечле** — досадный; жалко
**үлем** — смерть
**үлергә** — умереть
**үпкәлә** — обижайся
**үрмәли** — ползает
**үрти** — дразнит
**үрчет** — разводи
**үс** — расти
**үт** — проходи
**үтерә** — убивает
**үткәр** — пропусти
**үткен** — острый; хваткий, бойкий

# Ф

**файда** — польза, выгода
**файдалан** — пользуйся, используй
**файдалы** — полезный
**файдалы казылмалар** — полезные ископаемые
**фән** — наука
**фәнни** — научный
**фәрман** — приказ, повеление, указ
**фикер** — мысль
**фил** — слон

# Х

**хак** — правда, истина, право
**хаклы** — прав; законный, справедливый
**халык** — народ
**хата** — ошибка
**хәбәр I** — весть, известие
**хәбәр II** — сказуемое
**Хәерле көн!** — Добрый день!
**Хәерле юл!** — Счастливого пути!
**хәзер** — сейчас, теперь, нынче
**хәзинә** — богатство, достояние
**хәл** — сила, мощь, бодрость
**хәл ит** — реши, уладь
**хәл фигыль** — деепричастие
**хәрәкәт** — движение
**хәрәкәтлән** — двигайся
**хәреф** — буква
**хәсрәт** — горе
**хәтле** — до, по
**хәтта** — даже, вплоть
**хезмәткәр** — сотрудник
**хикмәт** — чудо; мудрость; секрет
**хисапчы** — счетовод
**хуҗалык** — хозяйство
**хыял** — мечта

# Һ

**һава** — воздух
**һаман** — всё время, постоянно
**һәвәскәр** — любитель; самодеятельный
**һәйкәл** — памятник
**һәлакәт** — крушение, гибель, трагедия
**һәлак була** — погибает
**һәм** — и
**һәрбер** — каждый
**һәрвакыт** — всегда, постоянно
**һәркайсы** — каждый
**һәркем** — каждый (человек)
**һичшиксез** — без сомнения
**һөнәр** — профессия, ремесло

# Ч

**чабата** — лапти
**чагылдыра** — отражает
**чаклы** — до
**чакыр** — зови
**чалбар** — брюки
**чана** — сани
**чаңгы** — лыжи
**чат** — перекрёсток
**чая** — бойкий, отчаянный
**чаялык** — лихость; смелость

**чәүкә** — галка
**чәч** — волос
**чебен** — муха
**чик** — грань, граница
**чир** — болезнь
**чирәм** — трава
**чирек** — четверть
**чирли** — болеет
**чит** — чужой
**чит ил** — зарубежная страна
**читләш** — отдаляйся
**чишмә** — родник
**чөнки** — потому что
**Чулман** — Кама
**чүлмәк** — горшок
**чүп** — мусор
**чыгыш** — выступление
**чыда** — терпи
**чык** — выйди
**чыланырга** — мокнуть, намокнуть
**чын күңелдән** — от всей души
**чынлап** — в самом деле
**чынык** — закаляйся
**чыркылдый** — визжит
**чыршы** — ель

# Ш

**шагыйрь** — поэт
**шаккат** — удивляйся, поражайся
**шалтырат** — звони
**шарт** — условие
**шартлавык** — смолёвка
**шартнамә** — договор
**шат** — радостный
**шатлан** — радуйся
**шатлык** — радость
**шаулашу** — шуметь, галдеть
**шаян** — озорной, шаловливый
**шәп** — здорово, хорошо
**шәүлә** — тень
**шәфкатьле** — милосердный
**шелтә** — замечание, упрёк
**шик** — сомнение
**шиңгән** — увядший
**шифа** — целебность;
целебное свойство
**шома** — гладкий
**шу** — катайся
**шул** — тот
**шулаймыни** — неужели
**шулкадәр** — так, до такой степени
**шулпа** — бульон
**шунда** — там
**шуңа** күрә — поэтому, потому
**шуыш** — ползай

# Ы

**ылыс** — хвоя
**ымлык** — междометие
**ыңгыраш** — стони
**ыргыт** — бросай
**ышан** — верь, поверь
**ышанмыйча** — не веря
**ышанычлы** — верный, надёжный

# Э

**эз** — след
**эзәрлекләү** — преследование
**эзлә** — ищи
**эл** — повесь
**эләк** — ловись, попадись
**элгеч** — вешалка
**элек** — раньше
**элемтәче** — связной, связист
**энә** — иголка
**эндәш** — обращайся
**энҗе** — жемчужина
**эре** — крупный, большой
**эретергә** — плавить
**эссе** — жарко; жаркий
**эч** — живот
**эчке** — внутренний
**эшкуар** — предприниматель
**эшләпә** — шляпа
**эшлекле** — деловой
**эшмәкәр** — бизнесмен
**эшчән** — трудолюбивый

# Ю

**юан** — толстый, полный
**юатучы** — утешитель
**юаш** — тихий, скромный, кроткий
**югал** — исчезни

**югалт** — теряй
**югары** — верхний, высший
**югыйсә** — а то, иначе
**юеш** — мокрый, сырой, влажный
**юка** — тонкий
**юкка** — напрасно, зря
**юклык** — отсутствие, неимение
**юл** — дорога, путь
**юләр** — дурак, дурачок
**юлдаш** — спутник, попутчик
**юлчы** — путник, проезжий, странник
**юмарт** — щедрый, добрый
**юньле** — толковый, дельный, полезный
**юньсез** — бестолковый, плохой
**юри** — умышленно, нарочно
**ютәл** — кашель
**юын** — умывайся

# Я

**ябык** — худой; закрытый
**ябыш** — цепляйся, приклеивайся
**ябыштыр** — приклей
**ява** — идёт (дождь, снег)
**ягулык** — горючее
**ягымлы** — ласковый
**язма I** — письменный
**язма II** — не пиши
**язмыш** — судьба
**як** — сторона, край
**яки** — или
**якла** — защищай
**якташ** — земляк
**якын** — близко
**якынлаш** — приближайся
**якын-тирәдә** — поблизости
**яланаяк** — босиком
**ялангач** — голый
**ялганла** — лги, соври
**ялгыз** — одинокий
**ялгыш** I — ошибочный; ошибка
**ялгыш** II — ошибайся
**ял ит** — отдыхай
**ялкын** — пламя, огонь
**ялтыра** — блести
**ялына-ялына** — всячески упрашивая
**ямь** — прелесть
**ямьле** — красивый, уютный
**ян** — гори
**янәшә** — рядом
**яңа** — новый
**яңалык** — новость
**яңгыра** — греми, звучи
**яра** — рана
**ярты** — половина
**ярыйсы** — удовлетворительный, средний
**яса** — делай
**ятим** — сирота
**ятла** — выучи
**яттан** — наизусть
**яшен** — молния
**яшер** — прячь
**яшерен** — тайный
**яшьлек** — молодость
**яшьтән** — смолоду
**яшьтәш** — ровесник

# Эчтәлек

**ТАТАРСТАН ИКЪТИСАДЫ**

1–11 нче дәресләр ........ 4

**ТАТАРСТАН СӘНГАТЕ**

12–39 нчы дәресләр ........ 15

**ҺӨНӘР САЙЛАУ**

40–67 нче дәресләр ........ 49

**СӘЛАМӘТЛЕК — ЗУР БАЙЛЫК**

68–78 нче дәресләр ........ 86

**БЕРКЕМ ДӘ, БЕРНӘРСӘ ДӘ ОНЫТЫЛМЫЙ**

79–102 нче дәресләр ........ 99

Учебное издание

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Ибрагимова** Гульшат Ильсуровна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**9 класс**

Учебник для образовательных организаций
основного общего образования

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р.З. Хайдарова, Г.И. Ибрагимова, Г.М. Ахметзянова*
Руководитель проекта *А.Т. Низамеева*
Художественный редактор *С.В. Киатров*
Руководитель группы художников и верстальщиков *Д.И. Бариев*
Вёрстка *Е.Б. Шараповой*
Координатор проекта *А.М. Ганиев*
Технический руководитель *И.М. Низаметдинов*
Редакторы *Ф.Ш. Ахметзянова, Г.М. Ахметзянова, И.А. Закиев*
Художники *А.Е. Гаранина, П.К. Михайлова, А.Я. Смольская,*
*Н.К. Авдеева, Г.И. Гилазетдинова, Ж.А. Буланкова, А.А. Бронникова*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 10.08.2025.. Формат 84x108 $^{1}/_{16}$ . Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная».
Печать офсетная. Уч.-изд. л. 6. Тираж _____ экз. Заказ _______.

Издательство «Татармультфильм».
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2
**www.tatarmultfilm.ru**

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных
издательством «Татармультфильм» материалов в типографии

**Издательство «Татармультфильм»**
разрабатывает и выпускает:

— учебники,
— электронные учебники,
— мультимедийные пособия,
— методические пособия,
— рабочие тетради,
— художественно-анимационные издания,
— интерактивные приложения.

**www.tatarmultfilm.ru**

Дополнительные материалы по изучению татарского языка и литературы для классных и внеурочных занятий на сайте **www.balarf.ru (www.бала.рф).**


Иярчен
Придаточные
Иярчен ия җөмлә
Придаточное подлежащное
Иярчен хәбәр җөмлә
Придаточное сказуемное
Иярчен
Придаточное обс
Иярчен урын җөмлә
Придаточное места
Иярчен вакыт җөмлә
Придаточное времени
Иярчен рәвеш җөмлә
Придаточное образа действия
Иярчен күләм җөмлә
Придаточное меры и степени



жөмләләр
предложения
Иярчен тәмамлык жөмлә
Придаточное дополнительное
Иярчен аергыч жөмлә
Придаточное определительное
хәл жөмлә
тоятельственное
Иярчен сәбәп жөмлә
Придаточное причины
Иярчен максат жөмлә
Придаточное цели
Иярчен кире жөмлә
Придаточное обратное
Иярчен шарт жөмлә
Придаточное условия

ФГОС



ISBN 978-5-906508-07-2

ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»